# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2021 4 (32)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Нур-Солтан)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

**БУ САНДА**


## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Нуриева Ф.Ш., Фәхретдинова Г.Н.* Татар телендәге реклама текстларында сүз төркемнәренең кулланылыш үзенчәлекләре . . 7

*Гыйльмуллин Р.А., Хөсәинов А.Ф., Сөләйманов Җ.Ш.* «TurkMT-7» – рус һәм төрки телләр арасында машина тәрҗемәсе системалары комплексын төзү турында . . . . . . . . . . . . . . 15

*Абдуллина Ч.З., Сәгъдиева Ф.К.* Татар теленең гаилә мохитендә кулланылышы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Шәрипов Ә.М.* Габдерәхим Утыз Имәнинең дини-суфичыл трактатлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32

*Шәрипова А.С.* XX йөз башы татар драматургиясе һәм театр сәнгатендә мәдәни бәйләнешләр . . . . . . . . . . . . 43

*Шәмсутова А.А.* 1980–2000 еллар татар драматургиясендә милли каһарман типлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50

*Ганиева А.Ф.* Татар әдәбиятында милли асылны саклаучы ана образы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Дәүләтшин Г.М.* Казан ханлыгында фәнни белемнәр торышы . . 71

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Фазлетдинов И.К.* Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдә мифологик мотивлар . . . . . . . . . . 84

## МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Кильдеев М.В.* Төбәк югары уку йортларында социологик фәннәрне укытуның методик мәсьәләләре турында . . . . . . . . 98

*Галимҗанов Ә.Ф.* Төгәл фәннәрне татарча укыту турында. . . . 108

*Гыйлемшина А.Г.* Медицина университеты студентларының татар телендә коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру . . . . 112

## СӘНГАТЬ

*Әлмиева Н.Ю.* В.А. Мошковның Идел-Урал төбәге музыкаль тюркологиясенә керткән өлеше . . . . . . . . . . . . . 117

*Улемнова О.Л.* Д.Л. Нәүрузованың китап графикасы (советтан соңгы чор Татарстан сәнгатендә яңа тенденцияләр чагылышы) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135

*Губина Т.А.* Татарстан музейларындагы реставрация остаханәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141

## ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР

*Сибгатуллина Ә.Т.* Татар галимнәренең Әнкарадагы мирасы игътибар сорый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
«Халкым җылысын тоеп...»
*(Гаяз Исхакыйның соңгы көндәлек дәфтәрләреннән)* . . . . . . . 151

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Бәширова И.Б.* Диалектолог галимә Тәнзилә Хәсән кызы Хәйретдинованың фәнни эшчәнлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
*Феоктистова Н.В.* Татар микробиологы Р.Г. Сайманованың тууына 100 ел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Сабитова И.И.* О.Н. Галимованың «Татарча-русча-латинча аңлатмалы балык атамалары сүзлеге» (Казан: ТӘhСИ, 2019. 204 б.) турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
*Нигъмәтҗанова Л.Т.* Татарстанда физкультура-спорт хәрәкәтен өйрәнү чыганагы буларак «Татарстанга – 100 ел: рәсемле энциклопедик язмалар» китабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Нуриева Ф.Ш., Фахретдинова Г.Н.* Специфика употребления определенных частей речи в рекламе на татарском языке. . . . . 7
*Гильмуллин Р.А., Хусаинов А.Ф., Сулейманов Дж.Ш.,* «К созданию комплекса систем машинного перевода между русским и тюркскими языками «TurkMT-7» . . . . . . . . . . . 15
*Абдуллина Ч.З., Сагдеева Ф.К.* Использоване татарского языка в пространстве семьи. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Шарипов А.М.* Религиозные трактаты Габдрахима Утыз Имяни . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
*Шарипова А.С.* Культурные взаимосвязи в татарской драматургии и театральном искусстве начала XX века . . . . . . 43
*Шамсутова А.А.* Типы национального героя в татарской драматургии 1980–2000 гг. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
*Ганиева А.Ф.* Образ матери-хранительницы национальной идентичности в татарской литературе . . . . . . . . . . . . . . . . . 61

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Давлетшин Г.М.* Развитие науки в Казанском ханстве. . . . . . . 71

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Фазлутдинов И.К.* Мифологические мотивы в преданиях об историях сел татар Башкортостана . . . . . . . . . . . . . . . . 84

## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Кильдеев М.В.* Проблемы преподавания социологии в региональных высших учебных заведениях . . . . . . . . . . . 98
*Галимянов А.Ф.* О преподавании точных и естественных наук на татарском языке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
*Гилемшина А.Г.* Формирование коммуникативных компетенций у студентов медицинского вуза на татарском языке . . . . . . . . 112

## ИСКУССТВО

*Альмеева Н.Ю.* Вклад В.А. Мошкова в музыкальную тюркологию Волго-Уральского региона . . . . . . . . . . . . . . . . 117
*Улемнова О.Л.* Книжная графика Д.Л. Наврозовой как отражение новых тенденций в искусстве Татарстана постсоветского периода . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
*Губина Т.А.* Музейные реставрационные мастерские в музеях Татарстана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Сибгатуллина А.Т.* Наследие татарских ученых в Анкаре требует внимания . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Из последних дневников Гаяза Исхаки . . . . . . . . . . . . . . . . 151

## ПЕРСОНАЛИИ

*Баширова И.Б.* Научная деятельность диалектолога Т.Х. Хайрутдиновой . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
*Феоктистова Н.В.* К 100-летию со дня рождения татарского микробиолога Р.Г. Саймановой . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166

## НОВЫЕ КНИГИ

*Сабитова И.И.* О словаре О.Н. Галимовой «Татарча-русча-латинча аңлатмалы балык атамалары сүзлеге» (Казань: ИЯЛИ, 2019. 204 б.) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
*Нигъмятзянова Л.Т.* Книга «Татарстану – 100 лет: иллюстрированные энциклопедические записки» как источник изучения физкультурно-спортивного движения в Татарстане . . 175

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811´367.6

***Ф.Ш. Нуриева,***
***Г.Н. Фәхретдинова***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ РЕКЛАМА ТЕКСТЛАРЫНДА СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Анализ текстов рекламы на татарско языке на морфологическом уровне позволяет выделить специфику употребления определенных частей речи, которые помогают реализовать основные функции рекламы. В статье рассмотрены номинативные имена существительные, формы настоящего, прошедшего и будущего времени глаголов, выяснена их роль в реализации информативной функции рекламного текста. Определена роль личных местоимений в текстах рекламы в установке контакта с потребителем, прилагательных, повелительного и условного наклонения в реализации воздействующей и побуждающей функции рекламы.

**Ключевые слова:** реклама на татарском языке, части речи, имена собственные, глагол, местоимение, прилагательные.

The morphological analysis of Tatar advertising texts allows us to see the specific features in using certain parts of speech, which help to maintain the basic functions of advertising. The article discusses nominative nouns, the present, past and future tenses of verbs; it shows that these speech parts are used to convey information in advertising. The article determines that personal pronouns in advertising help to establish a contact with the consumer, and adjectives, imperative and conditional moods are used to influence attitudes, affect behavior and motivate customers to buy the product or use the service.

**Keywords:** Tatar advertising, speech parts, proper nouns, verbs, pronouns, adjectives.

Реклама базар мөнәсәбәтләренә корылган җәмгыятьтә сатып алучыга мәгълүмат бирү һәм йогынты ясауда иң нәтиҗәле чараларның берсе булып тора һәм товар җитештерүчеләр, сәнгать, мәдәният, хокук, медицина, көнкүреш өлкәләрендә хезмәт күрсәтүчеләр, эшмәкәрләр өчен зур мөмкинлекләр ача.

Көнбатыш илләрендә реклама исәп-хисапка нигезләнгән кампания буларак кабул ителә, ул билгеле бер үрнәктәге формулалар, сораштыру, рейтинг һәм мониторингка таянып оештырыла. Россиядә исә төп игътибар мәгълүмат тапшыру һәм тәэсир итү чарасы буларак сүзгә, махсус тел чараларына юнәлдерелә, алгы планга текст куела һәм ул гуманитар фәннәр кысасында өйрәнелә. Атаманың тамыры латинча *reclamare* сүзеннән, француз телендә *réclame* «кычкырып әйтәм» мәгънәсендә кулланыла. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә файдаланучы, кулланучы, сатып алучы, тамашачы һәм башкаларны тарту, аларның игътибарын җәлеп итү максаты белән үткәрелгән чара

буларак теркәлгән [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2018, б. 725], шулай ук берәр кеше яисә берәр нәрсә турында хәбәр-мәгълүмат бирә торган игълан, белдерү, плакат, афиша һ.б. мәгънәләре урын алган. Шуңа нигезләнеп, рекламаны игълан, плакат, афиша белән тәңгәлләштерергә мөмкин, ләкин, төп аерма булып, аның потенциаль сатып алучыга коры мәгълүмат бирүдән тыш, игътибарны җәлеп итү максаты алгы планга чыга.

Хәзерге чорда икътисади шартларга, бизнес үсешенә, товар җитештерүчеләрнең үз продукциясен башкалардан аеру ихтияҗына бәйле рәвештә татар телендәге рекламаның яңарышы күзәтелә. Әлеге күренеш, бигрәк тә мәгълүматны җиткерү ысулларында, кулланучыларның социаль үзенчәлекләренә, зәвыгына бәйле сыйфат үзгәрешендә, милли-мәдәни мирас, татар теленең бай мөмкинлекләрен файдалануда чагылыш таба. XX гасыр ахырында реклама саф икътисади күренеш булып кына калмыйча, сәясәткә, идеологиягә, әхлак-тәрбиягә дә караган катлаулы, үзенчәлекле бер иҗтимагый характердагы көчле коммуникация чарасына әверелде. Шуңа бәйле рәвештә татар телендә язылган реклама текстларын төрле юнәлешләрдә: тарихи яктан – үсеш-үзгәрешен, лингвистик аспектта – реклама текстларының тел үзенчәлекләрен, психологик аспектта кешегә тәэсир иткән факторларны фәнни нигездә өйрәнү ихтыяҗы туа. Татар тел белемендә бу өлкәдә иң беренче җитди тикшеренү И.М. Низамовның «Татар рекламы һәм матбугат» монографиясендә чагылыш таба [Низамов, 1997]. Татарча рекламага кагылышлы күзәтүләр һәм фикерләр, аеруча әлеге төр текстларны оештыру, махсус тел чараларын куллануга бәйле булганнары, А.А. Гафурова, Г.Н. Фәхретдинова хезмәтләрендә күрсәтелгән [Гафурова, 2012; Фахретдинова, 2019]. Тел белемендә чагыштырмача яңа булган юнәлешне төрле аспектларда өйрәнү реклама стиленә хас төп закончалыкларны, текст белән бәйле үзенчәлекләрне тулырак ачыкларга мөмкинлек бирә. Сату-алу, хезмәт күрсәтү сферасына караган информацияне төгәл һәм кызыксындырырлык итеп оештыруда тел чаралары төп рольне уйный. Шуны истә тотып, рекламаның лингвистик үзенчәлекләрен өйрәнү татар тел белемендә әһәмиятле юнәлеш булып тора, мәкаләдә төп игътибар сүз төркемнәрен куллану мәсьәләләренә юнәлтелә.

Реклама телен тикшерүче галимнәр әлеге төр текстларда аеруча күп кулланылган сүз төркемнәренә игътибар итә. Әйтик, Америка филологы Ф. Джеффкинс шундыйлардан тәэсир итү көченә ия булган фигыль төрләрен һәм сыйфатларны бүлеп чыгарса [Джеффкинс, 2002, с. 270], рус тел белгечләре Н. Кохтев һәм Д. Розенталь еш очраган сүз төркемнәренә конкрет мәгънәгә ия исемнәрне һәм боеруны белдерә торган фигыльләрне кертәләр [Розенталь, Кохтев, 1981, с. 57]. Рекламаның прагматик функциясен башкарган фигыль сүз төркеме Н.К. Дементьева хезмәтендә махсус өйрәнелгән [Дементьева, 2004]. Татар тел белгече И.М. Низамов шулай ук сүз төркемнәренең адресатка йогынты ясавына басым ясап, аерым тәэсир итү чарасы бу-

ларак, боерык фигыльләр һәм сыйфатларны аерып күрсәтә [Низамов, 1997]. Гәрчә татарча реклама текстларында барлык сүз төркемнәре һәм грамматик төрләр урын алса да, хезмәтебездә прагматик потенциалга ия булган, кулланучыга хәбәр итү яисә аның игътибарын җәлеп итү максатын күз алдында тотып кулланылган исем, сыйфат, алмашлык һәм фигыльләрнең кулланылышына тукталабыз.

Реклама текстларында төрле әйбер, күренеш атамалары урын алуга бәйле, сүз төркемнәре арасында бигрәк тә исемнәрнең еш кулланылуы күзәтелә. Мәгълүм булганча, теләсә нинди рекламаның төп бурычы – объектны аңа охшашлардан аерып күрсәтү, кулланучыларның аңында товар яисә хезмәтнең исемен ишетүгә үк уңай образ тудырырга тырышу. Компаниянең урнашу урыны турында хәбәр итү һәм аның атамасын истә калдыру, теге яисә бу чарада катнашучыларны санап чыгу һәм адресатларда кызыксыну уяту максатын күздә тотып, текстларда ялгызлык исемнәрнең түбәндәге төрләре аеруча актив кулланыла:

– кеше фамилияләре һәм исемнәре. Нигездә, алар танылган артистларның концертлары яисә иҗади кичәләре турында мәгълүмат җиткергән афиша-текстларда еш очрый, анда чакырылган артистлар санап үтелә: *Австралия халкының күпсанлы сораулары буенча «**Татар радиосы**»нда кичке шоу – «**Хәерле иртә, Австралия**»! **Айваз Садыров, Айсылу Лерон** һәм син! Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе кичке сәгать биштә.* (Татар радиосы, 2018, сентябрь). Ялгызлык исемнәрне куллану үзенчәлеген тикшерүче А.А. Гафурова татар фамилияләрендә *-ов*/*-ев* рус суффиксларның төшеп калуына игътибар итә (Шәмси Закир), бигрәк тә әлеге күренешне яшьләр арасында төрки традицияләргә кайту омтылышы белән бәйли [Гафурова, 2012, с. 76]. Без анализлаган материал да әлеге тенденцияне раслый;

– җитештерүче яисә хезмәт күрсәткән фирманың урнашу урыны турында конкрет мәгълүмат туплаган географик һәм административ-территориаль исемнәр. Бу төр атамалар арасында Казан, шәһәр урамнары, Татарстан һәм республика объектлары (Арча, Биләр, Идел) өстенлек итүен күзәтәбез, бу, үз чиратында, рекламага милли-мәдәни компонент һәм этник коннотация өсти: *Сайлыйбызмы **Казан** сувенирларын? Әйдә инде, күпме фотога төшеп була? Киттек сувенирлар сата торган җиргә! Аларны кибетләрдә табып була. Ә иң күбе – **Бауман** урамында* (Татар радиосы, 2007, июнь);

– сәүдә һәм хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнгән оешмаларның, массакүләм мәгълүмат чаралары исемнәре, бер яктан, җитештерүче фирма атамасын күрсәтсә, икенче яктан, аларны популярлаштырып, ныграк истә калуны көчәйтә: *«**Ил-Гөл**» кибете түбән бәяләрдән азык-төлек, яшелчә, җиләк-җимеш, көнкүреш химиясе тәкъдим итә* (Таң, 2018, 12 октябрь, № 74).

Рекламадагы товарны уңай яктан тасвирлап бирүдә сыйфатларның роле зур, сатып алучыга эмоциональ йогынты ясауда һәм

товарның уңай образын тудыруда аларның иң кирәкле сүз төркеме булуын барлык галимнәр дә ассызыклый. Тупланган материалга нигезләнеп, реклама текстларында объектка характеристика биргән сыйфатларны түбәндәге лексик-семантик төркемнәргә бүлеп карыйбыз:

– физик халәт һәм тышкы сыйфатны белдерүчеләр: *«Лагуна» кафесы бәйрәмегезне оештыра:* ***уңай, пөхтә*** *зал,* ***күңелле*** *музыка,* ***тәмле*** *ашлар* – («Яңа Гасыр» радиосы, 2010, апрель);

– объектның төсен белдерүче сыйфатлар: ***Җирән, ак, көрән, зәңгәрсу, кара*** *төстәге декоратив яшь тавыклар сатыла* (Кайбыч таңнары, 2018, 2 март, № 15);

– вакыт ягыннан билге белдерүчеләр: Х*атын-кызларга Россиянең иң яхшы фабрикаларында тегелгән* ***кышкы*** *һәм* ***язгы-көзге*** *пәлтәләр, шулай ук* ***язгы*** *плащлар һәм курткалар тәкъдим итә* (Безнең Чирмешән, 2014, 24 апрель, № 26);

– күләм, чама ягыннан билге белдерүчеләр: *«Гулливер» сәүдә үзәге!* ***Чиксез*** *сайлау мөмкинлеге!* (Татар радиосы, 2010, декабрь);

– акыл ягыннан билге белдерүчеләр: ***Югары белемле, аралашучан, инициативалы*** *сәүдә вәкиленә вакансия, 25–35 яшьләрдә* (Байрак, 2016, 20 февраль, № 13).

Реклама текстында товар турында тулы мәгълүмат бирүдә һәм экспрессивлык тудыруда төп роль уйнаган, төрле мөнәсәбәтләрне характерлый торган сыйфатларга өстенлек бирелә: *Үзе* ***кыю****, үзе* ***кызык****, үзе* ***арзан, төсле, 16 битле*** *нәрсә ул? Ул – «Безнең гәҗит» газетасы!* (Татар радиосы, 2010, май).

Еш кына товар яки хезмәтнең иң отышлы ягына басым ясау чарасы итеп сыйфат дәрәҗәләренә мөрәҗәгать итәләр, мәсәлән, чагыштыру дәрәҗәсе көндәш оешма җитештергән әйбердән өстенрәк торуны күрсәтү өчен кулланыла: *Искиткеч яңалык! «Коника-Минота» фотосалоннары белән фотога төшү тагын да* ***күңеллерәк,*** *тагын да* ***файдалырак,*** *тагын да* ***отышлырак*** (Татарстан яшьләре, 2010, 13 гыйнвар, № 2). Билгеле булганча, артыклык дәрәҗәсе гомумән билгенең яисә башка предметларның, шундый ук билгеләре белән чагыштырганда, иң югары интенсивлыгын белдерә, ә реклама телендә «башка предметлар» дигәндә, көндәшләрнең товар яисә хезмәтләре күз алдында тотыла. Шул рәвешле, артыклык дәрәҗәсе объектның иң яхшы сыйфатларын аерып, кулланучылар игътибарын нәкъ менә аларның тәкъдимнәренең отышлы булуына юнәлтә. Нигездә, *иң* кисәкчәсе популяр: *Татар эстрадасының «****Иң яхшы*** *дуэтлар» концерты!* ***Иң якты*** *йолдызлар сезгә үзләренең* ***иң матур*** *җырларын бүләк итәр!* (Татар радиосы, 2019, гыйнвар).

Товар яки хезмәтнең нинди билгесен белдерүләренә карап, текстта еш кулланылган сыйфатларның түбәндәге семантик төркемнәре аерып чыгарылды:

– предметны характерлый торган билгеләр: *кулай, отышлы, арзан, яңа, махсус, түбән;*

– товарның сыйфатын атаган билгеләр: *сыйфатлы, шәп, затлы, ышанычлы, ныклы, эксклюзив, уникаль, файдалы, оригиналь, яңа, кызыклы, уңайлы, кирәкле;*

– башкарыла торган хезмәтне характерлый торган билгеләр: *тәҗрибәле, профессиональ, намуслы;*

– тәм ягыннан сыйфатлаган билгеләр: *тәмле, татлы, хәләл, милли, натураль, чиста, искиткеч, файдалы, шифалы;*

– көчемсез милекне характерлый торган билгеләр: *иркен, якты, матур, яңа, зур, җылы.*

Реклама текстындагы алмашлыклар, Ю.С. Бернадская фикеренчә, объектның кемгә юнәлгәнен күрсәтү өчен файдаланыла, бигрәк тә беренче зат потенциаль кулланучыга мөрәҗәгать итү типик алым булып тора [Бернадская, 2009, с. 75 ]. Әлеге үзенчәлек татар телендәге реклама өчен дә хас. *Мин* һәм *без* зат алмашлыклары берничә субъектка ишарә итү, клиентта ышаныч уяту өчен файдаланылган: *Әй, җәмәгать! Һаман машина алмадыгызмени әле?! Ә* ***мин*** *алам! «Стан» автосалоныннан!* (Татар радиосы, 2016, ноябрь); *Теш дәвалау бүлмәсеннән елмаеп чыгасыгыз киләме? «Таланид». Сәламәт теш –* ***безнең*** *эш!* (Татар радиосы, 2018, февраль).

Сатучының кулланучыга мөрәҗәгате формасында бирелгән рекламада зат алмашлыклары товар яки хезмәт сыйфаты өчен шәхси җаваплылыкка ишарәли, ә бу потенциаль клиентта ышаныч уята һәм йогынтыны көчәйтә. Алмашлыклар шулай ук сөйләмдә катнашучылар арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдыра, әйтик, беренче зат реклама бирүчене атаса, икенче зат потенциаль сатып алучыны күрсәтә һәм сатучы белән клиент арасында ышанычлы атмосфера урнаштыруга хезмәт итә: *«КМБ Банк»та* ***без сезнең*** *бизнесның реаль мөмкинлекләрен күрәбез, һәм, аны үстерер өчен,* ***бездә*** *яхшы тәкъдим бар.* ***Сезнең*** *кече бизнес –* ***безнең*** *өчен зур эш* (Болгар радиосы, 2015, июнь).

Күплек сандагы икенче зат *сез* алмашлыгы текстларда ике мәгънәдә теркәлде. Ихтирам белдергәндә – икенче зат берлек сан урынына, бер төркем адресатка мөрәҗәгать иткәндә – тыңлаучы затларның күплеген белдергәндә файдаланыла: ***Сезнең*** *шәп концерт карап, рәхәтләнеп ял итәсегез киләме? Алайса Казанның иң матур Корстон концертлар залына «Көзге бал»га рәхим итегез! Монда* ***сезне*** *искиткеч тамаша көтә! Шәп матур зал, уникаль тавыш, кич буена* ***сезнең*** *өчен күп йолдызлар җырлаячак! Эксклюзив тамашага килми калмагыз* (Татар радиосы, 2018, октябрь).

Татарча реклама текстларында *син* алмашлыгының тик ике очракта кулланылуы билгеләнде:

– интимизация, сатучы үзенең продукциясе турындагы мәгълүматны якыннарына тәкъдим иткән кебек игътибарны җәлеп иткәндә, берлек сандагы икенче зат файдаланыла: *Тешләреңне дәваларга җай табалмый йөрсәң, бер уңайдан ультратавыш белән агартырмын дисәң, елмаеп каршы алырлар* ***сине*** *һәрчак монда, «Таланид»ка кил – «Казан» ял йортына* (Татар радиосы, 2018, август).

– яшьләр аудиториясенә мөрәҗәгать иткәндә, текстта *син* алмашлыгын куллану отышлы алым булып тора: ***Син** яшь! **Син** актив! Татар милләтенең киләчәген кайгыртасың! Димәк, **син** – иң алдынгы татар яшьләренең берсе! Әгәр дә **син** төшеп калганнардан түгел икәнсең, 26 апрель көнне Бауман урамына кил. «Үзебез» яңа буын хәрәкәте һәм «Яңа гасыр» радиосы «Мин татарча сөйләшәм» акциясен уздыра. Татарча белү **синең** зәвыклы, бик тә кәттә булуыңны аңлата. **Сине** Бауман урамында татарча рок, татарча рэп, уен бәйгеләре һәм бүләкләр көтә* («Яңа Гасыр» радиосы, 2010, апрель).

Реклама текстларында фигыль сүз төркемен куллану шулай ук үзенчәлекле. Билгеле булганча, фигыльләр – зат яки предметның эшен, хәрәкәтен, хәлен, торышын белдерүче сүз төркеме. Фигыль башка сүз төркемнәреннән мәгънә киңлеге, чынбарлыктагы объектларның хәрәкәтен, динамикасын белдерү мөмкинлегенә ия булуы белән аерылып тора. Галимнәр билгеләвенчә, рекламада төп фикер фигыль формалары ярдәмендә тапшырылса, истә калдыру бермә-бер арта икән. Мәсәлән, А.В. Николаева фигыльнең төп функциясен кулланучының эш-гамәлләрен тасвирлауда, товар яисә хезмәтнең мөмкинлекләрен ачуда һәм кулланучыга йогынтысын арттыруда күрә [Николаева, с. 176]. Татар телендәге реклама текстларында затланышлы фигыльләренең барлык төрләре дә урын алган.

Эш, хәл, хәрәкәтнең булу-булмавын хәбәр иткән хикәя фигыль реклама текстларында еш очрый. Аның күбрәк хәзерге заман формасы өстенлек итә, контекстларда кабатланып торган, даими, һәрвакыт булып тора торган мәгънәсендә кулланыла. Мисаллар: *Чаллы бройлеркошчылык фабрикасы хәләл тавык, казылык һәм иттән төрле тәм-томнар **тәкъдим итә**. «Чаллы бройлеры» җитештергән азык-төлек Ислам кануннарына нигезләнеп **эшләнә**. «Идел-хаҗ» фонды да безнең ризыкларны югары **бәяли**. Сез дә авыз итеп карагыз. Шалтыратыгыз һәм килегез!* («Яңа Гасыр» радиосы, 2010, декабрь). *Акташ заводы 42 ел буена кирпеч **җитештерә** һәм **сата**. Акташ кирпече – ул заман технологиясе, югары сыйфат һәм ышанычлылык, чыдамлылык билгесе. Кирпечне уңайлы вакытта **сатып алып була**. Әлмәт районы, Рус Акташ авылы (Татар радиосы, 2008, гыйнвар).*

Реклама бирүчеләр тәкъдим мәгънәсендә, гадәттә, булачак эшне катгыйлык төсмере белән белдерә торган *-ачак, -әчәк* кушымчалы киләчәк заман фигылен файдалана: *«Адонис» ширкәтенең яңа язгы-җәйге кием коллекциясенең классик костюмнары һәр имтиханда сезгә ышаныч, чыгарылыш кичәләрендә кабатланмас стиль **бүләк итәчәк.*** («Яңа Гасыр» радиосы, 2009, май).

Билгеле үткән заман хикәя фигыль эшнең үтәлергә тиешлеге бәхәссез икәнен, икеләнергә юл калдырмавын белдергән очракларда кулланылган. Мисаллар: *Хыялланырга түгел, ә хыялларга утырып йөрер **вакыт җитте!** «Автолайф» автосалонына зәвыклы һәм ышанычлы «Тойота Раф 4» автомобиле **кайтты**! «Автолайф» автосалоны* (Татар радиосы, 2011, сентябрь); *Күп **йөрдем**! Күпне **күр-***

***дем**! «Азино Авто» яхшырак! ВАЗ автомобильләре кредитка!* (Татар радиосы, 2009, март).

Реклама текстларында урын алган фигыльнең иң актив формасы – боерык фигыль. Мәгълүм булганча, рекламаның төп максаты – укучы, тыңлаучыны теге яисә бу товарны сатып алырга, яки билгеле бер хезмәт күрсәтү оешмасына мөрәҗәгать итәргә чакыру, өндәү. Шушы максатны күздә тотып, текстларда боерык фигыльләр киң кулланыла, боеруның төсмерләре эш кушучы белән эшне үтәүче арасындагы мөнәсәбәтләргә бәйле була. Реклама үрнәкләрендә хәбәр бирүче эш башкаручы белән тигез дәрәҗәдә кабул ителә, боеру киңәш төсмере белән җиткерелә: *Ком сәгате, ком сәгате, ага гомерләребез, «Кәеф ничек?» гәҗитенә язылмыйча **калмагыз,** язылмыйча **калмагыз!**»* (Татар радиосы, 2007, декабрь); *«Таланид» стоматология клиникасы. Тешләрне кристаллар белән бизәкләү. **Игътибар үзәгендә булыгыз! Шалтыратыгыз!** «Таланид» – елмаерга **оялмагыз!*** (Татар радиосы, 2008, декабрь); ***Кил**! **Кур**! Иске машинаңны яңага **алыштыр**! «Азино Авто»!* (Татар радиосы, 2009, май).

Икенче бер эшнең үтәлүе өчен кирәкле шарт мәгънәсен белдергән *-са, -сә* кушымчалы шарт фигыль реклама текстларында да үзенең төп функциясен саклый: *Вакыт җил кебек исә дә үтеп китә. Менә Яңа ел да килеп җитәр. «Шәһри Казан»га **язылмый калсак**, киләсе елдан ул фатирыбызга килүдән туктар. «Шәһри Казанга» язылыйк, җәмәгать!* (Шәһри Казан, 2007, 5 декабрь, № 140); *Тышкы кыяфәтегезне үзгәртергә **теләсәгез,** «Имидж» салон-кибетенә чакырыбыз* (Таң, 2009, 5 октябрь, № 72).

Реклама текстларында шартны белдерү өчен башка фигыльләр дә килә ала. Аеруча, хәзерге заман хикәя фигыль *икән* кисәкчәсе белән еш кулланыла: *Йорт салырга теләп **мәшәкатьләнеп йөрисез икән,** Байлар Сабасының сәүдә йорты искиткеч мөмкинлек бирә. Төзелеш материалларын өегезгә китерү шарты белән сатып ала аласыз* («Яңа Гасыр» радиосы, 2009, май); *Әгәр сезнең машинагыз куркыныч булачагын алдан сизеп, сезгә **хәбәр итә икән**, яисә үзеннән үзе автопилотка **күчә икән**, алга таба әлеге рекламаны тыңлап тормасагыз да була. Ә калганнарга «Промышленная Страховая Компания» автогражданлык җаваплылыгын страховкалау турында искә төшерә* (Яңа Гасыр» радиосы, 2009, сентябрь).

Затланышсыз фигыльләрдән реклама текстларында эшкә өндәү, чакыру кебек модаль мәгънәләрне белдергән, процессны динамикада күрсәткән инфинитив фигыль формалары еш очрый. Мисаллар: ***Бүләк эзләп йөрисезме бәйрәм белән котларга?!** «Безнең Мирас» – затлы бүләк туганнарга, дусларга. «Безнең Мирас» журналы белән бергә булыгыз!* (Болгар радиосы, 2018, май); *Ишеттегезме? «Музыкаль десант» MP3 форматта! Инде сатуда! Мин киттем **сатып алырга**! Мин дә!* (Татар радиосы, 2008, октябрь).

Текстларда урын алган сүз төркемнәрен анализлаудан күренгәнчә, кулланучыларның, сатып алучыларның игътибарын җәлеп итү

максатында морфологик чараларның зур әһәмияткә ия булулары, контекстта аларның билгеле бер стилистик төсмерләре барлыкка килүе билгеләнде. Рекламаның информацион функциясе ялгызлык исемнәр, хәзерге, үткән һәм киләчәк заман хикәя фигыль формалары, инфинитив ярдәмендә тормышка ашырыла. Алар ярдәмендә кулланучыга өстәмә информация бирелә, товар яки хезмәтнең үзенчәлекләре турында хәбәр ителә. Текстларда зат алмашлыклары адресат белән элемтә урнаштыра, реклама бирүченең позициясен билгели, әлеге мөнәсәбәт дустанә «син» яисә формаль «сез» алмашлыгы ярдәмендә барлыкка килә. Сыйфат, шарт һәм боерык фигыльләр адресатларның игътибарын җәлеп итү максаты белән файдаланыла.

**Әдәбият**

*Гафурова А.А.* Специфика функционирования ономастической лексики в татарских и англоязычных рекламных текстах. Казань: Казан. (Приволжский) *фед. ун-т, 2012. 246 с.*

*Бернадская Ю.С.* Текст в рекламе: учеб. пособие для студентов. М.: Юнити, 2003. 288 с.

*Дементьева Е.Ю.* Глагол в рекламном тексте. Воронеж: Воронеж. гос. ун-т. Воронеж, 2004. 161 с.

*Джефкинс Ф.* Реклама. М.: ЮНИТИ-ДАНА, 2002. 543 с.

*Кохтев Н.Н.* Реклама: искусство слова. М.: Изд-во МГУ, 1997. 96 с.

*Низамов И.М.* Татар рекламы һәм матбугат. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1997. 110 б.

*Николаева А.В.* Особенности функционирования «пустых» глаголов в рекламных текстах (на материале английской рекламы). Lingua mobilis. 2010. № 1 (20). С. 175–180.

*Розенталь Д.Э., Кохтев Н.Н.* Язык рекламных текстов. М.: Высшая школа, 1981. 125 с.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 6 томда. 4 т. Казан: ТӘһСИ, 2018. 760 б.

Фахретдинова Г.Н. Язык татарской рекламы. Казань: Казан. (Приволжский) фед. ун-т, 2019. 259 с.

*Fakhretdinova G.N., Guadagnolo G.D.* The language of Tatar adverting: influence of cultural values // Tatarica. 2019. No 1(12). P. 7–15.

*Мәкалә «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Нуриева Фәнүзә Шәкүр кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университетның татар тел белеме кафедрасы профессоры*

***Фәхретдинова Гөлназ Нурхамәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан милли тикшеренү технологик университетының профессиональ коммуникациядә чит телләр кафедрасы доценты*

УДК 81´322.4

***Р.А. Гыйльмуллин,***
***А.Ф. Хөсәинов,***
***Җ.Ш. Сөләйманов***

# «TURKMT-7» – РУС ҺӘМ ТӨРКИ ТЕЛЛӘР АРАСЫНДА МАШИНА ТӘРҖЕМӘСЕ СИСТЕМАЛАРЫ КОМПЛЕКСЫН ТӨЗҮ ТУРЫНДА

В этой статье описываюся основные этапы работы над проектом TurkMT-7. Идея проекта «TurkMT-7» заключается в создании корпусов данных и нейросетевых машинных переводчиков для русско-тюркских языковых пар с ограниченными ресурсами. Достижение этой цели планируется за счет применения гибридного подхода к созданию многоязычного параллельного корпуса между русским и тюркским языками, использования различных подходов переноса знаний с одной языковой пары на другую, применения методов искусственного увеличения объема обучающих данных, а также разработка специализированных методов унификации параллельных данных на разных языках, основанная на агглютинативной природе выбранных тюркских языков (структурно-функциональная модель тюркской морфемы).

**Ключевые слова:** нейресетовой машинный перевод, многоязычные данные, тюркские языки.

The idea of the «TurkMT-7» project is to create datasets and neural machine translation systems for a set of Russian-Turkic low-resource language pairs. It's planned to achieve this goals through an hybrid approach to creating a multilingual parallel corpus between Russian and Turkic languages, studying the applicability and effectiveness of neural network learning methods (transfer learning, multi-task learning, back-translation, dual learning) in the context of the selected language pairs, as well as the development of specialized methods for unification of parallel data in different languages, based on the agglutinative nature of the selected Turkic languages (structural and functional model of the Turkic morpheme). In this article we describe the main stages of work on this project.

**Keywords:** neural machine translation, multilingual datasets, Turkic languages.

Автоматик рәвештә тәрҗемә системаларын төзү юнәлеше соңгы елларда бигрәк тә тиз үсеш алды. Аның төп сәбәпләренең берсе – машиналы өйрәтүнең заманча ысулларын уңышлы куллану нәтиҗәсе. Әмма модельләрне өйрәтү өчен мәгълүмат җитмәгән очракта, нейрочелтәр технологияләрен дөньядагы иң танылган инглиз-алман, инглиз-кытай һ.б. парлар өчен куллангандагы кебек яхшы нәтиҗәләргә ирешү мөмкин түгел.

Аз ресурслы телләр өчен (татар теле дә бу исемлектә) аерым алынган кайбер мәсьәләләр өчен булган технологияләрне адаптацияләү һәм камилләштерү эшләре аеруча актуаль булып тора. Болар арасында «белем күчерү» (transfer learning, zero-shot learning) һәм өйрәтү

мәгълүматын ясалма рәвештә арттыру (мәсәлән, back-translation, dual learning) технологияләрен куллану аеруча уңышлы нәтиҗәләргә китерде. Әмма аз ресурслы төрки телләр төркеме булып саналган телләр өчен машина ярдәмендә күптелле (рус теленнән төрки телләргә һәм киресенчә) тәрҗемә системасын төзү турында тикшеренүләр моңарчы үткәрелмәде.

Әлеге проект җиде төрки телдән рус теленә һәм киресенчә рус теленнән җиде төрки телгә тәрҗемә итү системасын төзү өчен методик һәм программа чараларын эшләүгә юнәлтелә. Проект кысаларында куелган мәсьәләләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт: өйрәтүче параллель мәгълүмат корпусларын туплау; төрки морфема функциональ моделе нигезендә тупланган параллель корпусларны унификацияләү методын эшләү; шулай ук белемнәрне күчерү һәм мәгълүмат күләмен ясалма рәвештә арттыру ысулларын кулланып, күптелле машина тәрҗемәчесен өйрәтү программа чараларын төзү. Болар ярдәмендә өйрәтүче мәгълүматларның аз булу проблемасын хәл итү планлаштырыла. Бу беренче тапкыр кырымтатар-рус тел парына тәрҗемә итү системасын төзергә ярдәм итәчәк. Моннан тыш, машина тәрҗемә системасы тагын алты тел пары өчен эшләячәк (татарча-русча, башкортча-русча, чувашча-русча, казакъча-русча, кыргызча-русча һәм үзбәкчә-русча). Әлеге тикшеренү күбесенчә Россия Федерациясе һәм БДБ илләре территориясендә яшәүче 57,93 млн кеше [Eberhard, David M., Gary F. Simons, and Charles D. Fennig, 2020] өчен файдалы булырга мөмкин.

Тикшеренү нәтиҗәләре машина тәрҗемәсенең сыйфатына күптөрле параметрларның (кардәш булган телләр буенча файдаланылган корпуслар күләме, ясалма рәвештә тупланган параллель мәгълүматларның кулланылышы, нейрочелтәр архитектурасын өйрәтү һәм сайлау ысулларын куллану) йогынты ясый торган дәрәҗәсе турында мәгълүмат бирәчәк.

Мәкаләнең 1 нче бүлегендә әлеге өлкәдәге тикшеренүләргә күзәтү тәкъдим ителде, 2 нче бүлек әлеге проект буенча эш планын үз эченә алды.

Соңгы елларда машина тәрҗемәсе системаларын төзүдә кулланыла торган ысуллар, технологияләр җитди үзгәрешләр кичерә. Дөньядагы иң зур кулланышлы телләр өчен дә, аз ресурслы телләр өчен дә машина тәрҗемәсе мәсьәләләрен чишү юнәлешендә тигез күләмдә шактый зур эшләр башкарыла. Аерым телләр өчен булган мәгълүмат күләме һәм сыйфатына карап, билгеле бер алгоритмнар җыелмасын һәм тәрҗемә ысулларын кулланырга мөмкин.

Машина тәрҗемәсенә караган мәсьәлә sequence-to-sequence *(бер элементлар эзлеклелеген икенче элементлар эзлеклелегенә күчерү моделе)* дип аталган [Sutskever, I, 2014] модель ярдәмендә чишелә, мәсәлән, код-лау һәм код-ачу архитектурасы (encoder/decodecoder архитектурасы) элементларын үз эченә алган рекуррент һәм төргәк нейрочелтәрләр. Иң яхшы сыйфатны күрсәткән модельләр шулай ук

«игътибар механизмын» (attention, self-attention – рекурент нейрочелтәрләрдә куллана торган ысул) үз эченә ала.

Өйрәтү процессын тизләтү һәм тәрҗемәче системаларның сыйфатын яхшырту максатыннан төзелгән нейрочелтәрләрнең төрле архитектуралары бар: рекуррент нейрочелтәрләр [Bahdanau, D., Cho, K., Bengio, Y., 2015], төргәк нейрочелтәрләр [Gehring, J., Auli, M., Grangier, D., Yarats, D., Dauphin, N.Y., 2017], Transformer һәм Evolved Transformer [Vaswani, A., 2017] (өйрәтү тизлеген арттыру өчен «игътибар механизмын» кулланучы модельләр). «Игътибар механизмы» да яңартылды: multi-hop attention, self-attention һәм multi-head attention (граф нейрочелтәрләрендә үзконтроль механизмнар) [Gehring, J., Auli, M., Grangier, D., Yarats, D., Yann N Dauphin, 2017; Paulus, R., Xiong, C., Socher, R., 2018; Johnson, M., 2017] вариантлары тәкъдим ителде.

Машина тәрҗемәсе системасын төзү технологиясен сайлау беренче чиратта өйрәтүче мәгълүматларның булуына һәм аларның күләменә бик нык бәйле. Чыганак һәм тәрҗемә телләре өчен зур күләмле бертелле корпусларның булуы машина тәрҗемәчеләрен төзү өчен unsupervised *(«укытучысыз өйрәнү»)* дип аталган алымны кулланырга мөмкинлек бирә. Әлеге алымның төп идеясе – ике тел өчен дә сүз/фразалардан торган бердәм векторлы киңлекне төзүдән гыйбарәт. Хәзерге вакытта әлеге алымның статистик [Artetxe, M., 2018], нейрочелтәр [Mikel Artetxe, Gorka Labaka, Eneko Agirre, Kyunghyun Cho, 2018] һәм гибридлы алымнар нигезендә гамәлгә ашыру вариантлары бар.

Тәрҗемә сыйфатын яхшырту өчен өйрәтүне өлешчә укытучы катнашында башкарганда бертелле корпуслардан файдалануның төрле вариантлары тәкъдим ителде: semi-supervised («өлешчә өйрәнү») [Munteanu, D.S., 2004].

Бертелле мәгълүматларны куллануның тагын бер ысулы – ул код-ачу (decoder) [Caglar, G., 2015] өчен җавап бирә торган системаның бер өлешен тел моделе белән тулыландыру. Әлеге алым IBM-ның элекке хезмәтләрендә [Brown, P.F., 1990] күрсәтелгән. Соңрак бастырылган хезмәтләрдә тәрҗемә теле өчен кулланылган өстәмә тел моделе статистика нигезендә төзелгән системалар өчен тәрҗемәнең табигыйлыгын һәм төгәллеген яхшыртырга мөмкинлек бирә, дип күрсәтелгән иде. Алга таба әлеге стратегия нейрочелтәрләр нигезендә [He, W., 2016] төзелгән тәрҗемә системалары өчен дә кулланылды. Кулланудан тыш кодны ачу вакытында, нейрочелтәрле телләр һәм тәрҗемә модельләре [Caglar, G., 2017] яшерен халәтен берләштерү исәбенә эчке дәрәҗәдә уңышлы интеграцияләнергә мөмкин. Моннан тыш, нейрочелтәр архитектурасы күпмәсьәләле өйрәнү (multi-task learning) һәм параметрларны уртак өйрәнү (parameter sharing) [Domhan, T., 2017] ысулларын кулланырга мөмкинлек бирә.

Әлеге хезмәтләрдә [Cheng, Y., 2016] авторлар бертелле мәгълүматларны автомат рәвештә кодлаштыру өчен ярдәмче мәсьәләне

өстәргә тәкъдим итәләр. Бу ысул чыганак җөмләләр эзлеклелеге нигезендә ике якка да тәрҗемә итүне тәэмин итә.

Аз ресурслы телләр өчен тәрҗемә сыйфаты синтетик мәгълүматлар хисабына яхшырырга мөмкин [Currey, A., 2017]. Анда чыганак теле җөмләләре тәрҗемә теле җөмләләренең гади күчермәсе буларак төзелә.

Өйрәтү мәгълүматларын автомат рәвештә эффектив арттыру ысулы (data-augmentation) да мәгълүм [Sennrich, R., 2015]. Ул back-translation *(кирегә тәрҗемә)* (текст буенча алга таба КТ) дип атала: чыгарылыш теленнән чыганак теленә тәрҗемә итеп, яңа тәрҗемәләрне чыганак тел җөмләләре белән катнаштырып, өйрәтүче мәгълүматлар күләмен арттыру өчен кулланыла торган ысул. Шул исәптән параллель корпус күләме дә арттырыла. Соңыннан шушы корпус машина тәрҗемәсен өйрәтү өчен файдаланыла.

Куллану ягыннан КТ гади, чөнки ул машина тәрҗемәсен өйрәтү алгоритмнарына үзгәреш кертүне таләп итми. Аз ресурслы телләр өчен өйрәтүче мәгълүматлар күләмен арттыру мәсьәләсеннән башка, машина тәрҗемәсен аерым предмет өлкәсенә яраклаштыру өчен шулай ук бертелле корпуслар да эшкә җигелә [Bertoldi, N., Federico, M., 2009]. Соңгы елларда дөнья күргән хезмәтләрдә [Sennrich, R., 2016; Lample, G., 2018] КТ ысулын яхшырту өчен синтетик парларны «нур буенча эзләү» (beam search) яки «комсыз эзләү» (greedy search) ысуллары ярдәмендә яңа җөмләләр генерацияләүдән баш тартырга тәкъдим ителде. Әйтеп кителгән алгоритмнар апостериор максимумны *(maximum a posteriori)* (текст буенча алга таба АМ) эзләргә, ягъни җөмләне модель нигезендә иң зур ихтималлык белән табарга мөмкинлек бирә. Әмма АМ ны куллану тәрҗемәләр аскорпусы төрлелегенең кимрәк булуына китерергә мөмкин, чөнки күпмәсьәләлек очракларында алгоритм һәрвакыт иң ихтимал вариантны сайлаячак [Ott, M., 2018]. Альтернатива буларак, аерым авторлар «очраклы сайлау» (random sampling) ысулын кулланырга тәкъдим итәләр [Imamura, K., 2018]. Әлеге ысул генерацияләнгән җөмләләр парының лексик төрлелеген сакларга мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта сирәк булган тәрҗемә вариантларын төшереп калдыру өчен, өстәмә кагыйдәләр кулланырга мөмкин [Graves, A., 2013]. Моннан тыш, һәр җөмлә өчен чыганак җөмләләренең берничә вариантын да генерацияләп була. Мөһим үзгәреш [Vu Cong Duy Hoang, Philipp Koehn, Gholamreza Haffari, Trevor Cohn, 2018] хезмәтендә бар: авторлар, финал системаларының сыйфатын яхшырту өчен, өйрәтүче корпусның синтетик өлешен итератив рәвештә өйрәтергә/өстәргә тәкъдим итте.

Аерым фәнни хезмәтләрдә ике тел өчен бертелле корпуслар булган очракта, тәрҗемәләрнең сыйфатын ничек яхшыртып булуы күрсәтелгән [Cheng, Y., 2016]. Ике корпусны берьюлы куллану ВТ алымыннан «икеләтә өйрәтү» (dual learning) ысулына күчәргә мөмкинлек бирә. Бу очракта өйрәтү бер үк вакытта тәрҗемәнең ике юнәлешендә

дә бара, ике юнәлештә дә өйрәтүче корпус күләмен һәм синтетик җөмләләр өлешен акрынлап арттыру өчен, ВТ алымы кулланыла.

Byte-pair encoding *(байтлар парын кодлаштыру)* (текст буенча алга таба БПК) [Gade, F., 1994] алымы аеруча игътибарга лаек. Ул төп элемент буларак бер сүздән кимрәк булган элементларга нигезләнгән машина тәрҗемәсе мәсьәләсе өчен кулланыла. БПК [Sennrich, R., 2016] нигезендә сегментацияләүне куллану ачык сүзлек ярдәмендә тәрҗемә итү мәсьәләсен чишәргә мөмкинлек бирә (система теләсә нинди сүзләрне тәрҗемә итә ала, шул исәптән, өйрәтүче корпусларда булмаганнарын да). БПК алымы баштан ук мәгълүматны кысу алгоритмы буларак төзелгән, ләкин сүзләрне сегментка бүлү өчен түбәндәгечә җайлаштырылган: өйрәтүче сүзлекнең һәр сүзе сүз азагының махсус символы белән тәмамлана торган символлар тезмәсе булып тора; барлык символлар элементлар сүзлегенә өстәлә; символларның иң еш очраган парлары билгеләнә, табылган тезмәләр элементлар сүзлегенә өстәлә һәм корпуска берләшә. Процедура бирелгән берләшү операцияләр саны үтәлгәнчә кабатлана.

## Проектны гамәлгә ашыру планы һәм әлеге этап нәтиҗәләре

Рус теле һәм төрки телләр төркеме өчен өйрәтүче параллель мәгълүматларны туплау мәсьәләсен үз эченә алган төрле ысуллар җыелмасы ярдәмендә чишәргә тәкъдим ителә. Шул исәптән: йомгаклау корпусын ике телле Интернет-чыганаклардан тулыландыру (яңалыклар порталы, ирекле лицензияле электрон китапханәләр һәм башкалар), проектта сайланган телләр өчен тәрҗемә ителгән китап басмаларын цифрлаштыру, параллель мәгълүматларның инде төзелгән чыганакларын берләштерү. Әлеге мәсьәләне хәл итү өчен, төрле эшләр башкару сорала: мәгълүматлар чыганакларын билгеләү буенча эксперт эше; анализ өчен кирәкле булган ысулларны гамәлгә ашыру, шул исәптән документлар буенча тигезләү алгоритмнарын төзү, җөмләләр буенча тигезләү, эвристик кагыйдәләр җыелмасы нигезендә фильтрлау, шулай ук булган яхшы сыйфатлы аскорпуслар нигезендә параллель пар җөмләләр фильтрациясенең интеллектуаль модельләрен куллану.

Машина тәрҗемәсе моделен төзүнең төп мәсьәләсе нейрочелтәрләр алымы нигезендә башкарылачак. Башлангыч этапта Transformer нейрочелтәре архитектурасын куллану планлаштырыла. Аның төп үзенчәлеге – «игътибар механизмын» куллануда (multi-head attention) һәм төргәкле һәм рекуррент катламнарның булмавында.

Проектта игълан ителгән тел парларының күбесе өчен (казакъ-рус, татар-рус парларыннан тыш) күрсәтелгән алымны модельләр өйрәтү өчен уңышлы куллану мөмкин түгел иде. Күптелле тәрҗемәчене төзүгә юнәлтелгән комплекслы алым бу проблеманы түбәндәгеләр ярдәмендә хәл итәчәк:

• белемнәрне бер тел парыннан икенчесенә күчерүнең төрле алымнарын куллану (мәсәлән, ресурслар белән тулырак тәэмин

ителгән тел пар/парларына өйрәтелгән fine-tuning нейрочелтәрләре; чыганак тел өчен нейрочелтәр архитектурасын «сүзләр катламы» (word embedding) ысулы нигезендә төзү һәм аны бердәм күптелле нейрочелтәрне өйрәтү өчен куллану);

• проектта игълан ителгән барлык телләр өчен сүз өлешләрен гомуми формага китерү буенча эш башкару (мәсәлән, барлык телләр өчен гомуми byte-pair encoding-элементлар);

• өйрәтү мәгълүматын ясалма рәвештә арттыру ысулларын куллану (back-translation) (бертелле корпусларны тәрҗемә итү нигезендә параллель мәгълүматлар күләмен арттыру өчен, тәрҗемәченең арадаш версияләрен куллану) һәм ысулларны, лексик яктан баерак тәрҗемә булсын өчен, «нур буенча эзләү» (beam search) ысулы урынына «очраклы сайлау» (random sampling) ысулын кулланып, модификация эшләрен башкару;

• төрле тел парлары өчен җыелган параллель корпусларны унификацияләү ысулларын эшләү, бу бер тел пары өчен төзелгән зуррак күләмдәге корпусларны башка парлар өчен тәрҗемә моделен өйрәткәндә тулырак файдаланырга мөмкинлек бирәчәк. Төрки морфеманың структур-функциональ моделен [32] төрле төрки телләрдә аффикслар тарафыннан башкарыла торган грамматик рольләрнең үзара бәйләнеше турындагы мәгълүматны өйрәтүче мәгълүматларда куллану максатыннан тәкъдим ителә. Әлеге мәгълүмат корпус әзерлегенең башлангыч этабында төрле телдәге морфемалар өчен бердәм элементлар формалаштырырга мөмкинлек бирәчәк.

Шулай итеп, тәрҗемә моделен өйрәтүгә һәм өйрәтүче мәгълүматларны әзерләүгә кагылышлы эшләрнең төп этаплары бер үк вакытта машиналы өйрәтү һәм кагыйдәләргә нигезләнгән (төрки морфеманың структур-функциональ моделендәге телләр өчен мәгълүматлар базасы) алымнарга таяна.

Йомгаклау этабында кулланылган алымнарны, җайлауларны, нейрочелтәр гиперпараметрларының кыйммәтен һәм кулланылган өйрәтүче мәгълүматларның күләмен ачыклау максатыннан машина тәрҗемәсе системаларының төрле вариантлары өчен тест үткәреләчәк.

Бу мәкаләдә без әле башланып киткән җиде пар тел өчен машина тәрҗемә системасы комплексына караган «TurkMT-7» исемле проектны тәкъдим иттек. Аны гамәлгә ашыруның төп үзенчәлеге – машиналы өйрәтү буенча заманча технологияләр һәм төрки телләр үзенчәлекләренә нигезләнгән алымнар ярдәмендә башкаруда.

## Әдәбият

*Eberhard, David M., Gary F. Simons, and Charles D.* Fennig (eds.). 2020. Ethnologue: Languages of the World. Twenty-third edition. Dallas, Texas: SIL International. Online version: http://www.ethnologue.com.

*Sutskever, I.* Sequence to sequence learning with neural networks [Text] / Ilya Sutskever, Oriol Vinyals, and Quoc V.Le. // Advances in Neural Information Processing Systems. 2014. P. 3104–3112.

*Bahdanau, D., Cho, K., Bengio, Y.* Neural machine translation by jointly learning to align and translate [Text] / Dzmitry Bahdanau, Kyunghyun Cho, and Yoshua Bengio // International Conference on Learning Representations (ICLR). 2015.

*Gehring, J., Auli, M., Grangier, D., Yarats, D., Dauphin, N.Y.* Convolutional sequence to sequence learning [Text] / Jonas Gehring, Michael Auli, David Grangier, Denis Yarats, and Yann N Dauphin // International Conference of Machine Learning (ICML). 2017.

*Vaswani, A.* Attention is all you need [Text] / Ashish Vaswani, Noam Shazeer, Niki Parmar, Jakob Uszkoreit, Llion Jones, Aidan N. Gomez, Lukasz Kaiser, and Illia Polosukhin // Conference on Advances in Neural Information Processing Systems (NIPS). 2017.

*Gehring, J., Auli, M., Grangier, D., Yarats, D., Yann N Dauphin.* Convolutional sequence to sequence learning [Text] / Jonas Gehring, Michael Auli, David Grangier, Denis Yarats, and Yann N Dauphin // International Conference of Machine Learning (ICML). 2017.

*Paulus, R., Xiong, C., Socher, R.* A deep reinforced model for abstractive summarization [Text] / Romain Paulus, Caiming Xiong, and Richard Socher // International Conference on Learning Representations (ICLR). 2018.

*Johnson, M.* Google's Multilingual Neural Machine Translation System: Enabling Zero-Shot Translation [Text] / Melvin Johnson, Mike Schuster, Quoc V. Le, Maxim Krikun, Yonghui Wu, Zhifeng Chen, Nikhil Thorat, Fernanda B. Viegas, Martin Wattenberg, Gregory S. Corrado, Macduff Hughes, Jeffrey Dean // Transactions of the Association for Computational Linguistics, Vol. 5. 2017. P. 339–351.

*Artetxe, M.* Unsupervised Statistical Machine Translation [Text] / Mikel Artetxe, Gorka Labaka, Eneko Agirre // Proceedings of the 2018 Conference on Empirical Methods in Natural Language Processing. 2018. P. 3632–3642.

*Artetxe, M.* Unsupervised Neural Machine Translation [Text] / Mikel Artetxe, Gorka Labaka, Eneko Agirre, Kyunghyun Cho // Proceedings of the 2018 Conference on Empirical Methods in Natural Language Processing. 2018. P. 3632–3640.

*Lample, G.* Phrase-Based & Neural Unsupervised Machine Translation [Text] / Guillaume Lample, Myle Ott, Alexis Conneau, Ludovic Denoyer, Marc'Aurelio Ranzato // Proceedings of the 2018 Conference on Empirical Methods in Natural Language Processing. 2018.

*Munteanu, D.S.* Improved machine translation performance via parallel sentence extraction from comparable corpora [Text] / D.S. Munteanu, A. Fraser, and D. Marcu // ACL. 2004.

*Caglar, G.* On using monolingual corpora in neural machine translation [Text] / Caglar Gulcehre, Orhan Firat, Kelvin Xu, Kyunghyun Cho, Loic Barrault, Huei-Chi Lin, Fethi Bougares, Holger Schwenk, and Yoshua Bengio // arXiv preprint arXiv:1503.03535. 2015.

*Brown, P.F.* A statistical approach to machine translation [Text] / Peter F. Brown, John Cocke, Stephen Della Pietra, Vincent J. Della Pietra, Frederick Jelinek, John D. Lafferty, Robert L. Mercer, and Paul S. Roossin // Computational Linguistics, 16. 1990. P. 79–85.

*Koehn, Ph.* Statistical phrase-based translation [Text] / Philipp Koehn, Franz Josef Och, and Daniel Marcu // Conference of the North American Chapter of the Association for Computational Linguistics (NAACL). 2003.

*He, W.* Improved neural machine translation with smt features [Text] / Wei He, Zhongjun He, Hua Wu, and Haifeng Wang // Conference of the Association for the Advancement of Artificial Intelligence (AAAI). 2016. P. 151–157.

*Caglar, G.* On integrating a language model into neural machine translation [Text] / Caglar Gulcehre, Orhan Firat, Kelvin Xu, Kyunghyun Cho, and Yoshua Bengio // Computer Speech & Language, 45. 2017. P. 137–148.

*Domhan, T.* Using targetside monolingual data for neural machine translation through multi-task learning [Text] / Tobias Domhan, Felix Hieber // Conference on Empirical Methods in Natural Language Processing (EMNLP). 2017.

*Cheng, Y.* Semi-supervised learning for neural machine translation [Text] / Y. Cheng, W. Xu, Z. He, W. He, H. Wu, M. Sun, and Y. Liu // arXiv:1606.04596. 2016.

*Currey, A.* Copied Monolingual Data Improves Low-Resource Neural Machine Translation [Text] / Anna Currey, Antonio Valerio Miceli Barone, and Kenneth Heafield // Proc. of WMT. 2017.

*Sennrich, R.* Improving neural machine translation models with monolingual data [Text] / Rico Sennrich, Barry Haddow, and Alexandra Birch // arXiv preprint arXiv:1511.06709. 2015.

*Bertoldi, N., Federico, M.* Domain adaptation for statistical machine translation with monolingual resources [Text] / Nicola Bertoldi and Marcello Federico // Workshop on Statistical Machine Translation (WMT). 2009.

*Sennrich, R.* Improving neural machine translation models with monolingual data [Text] / Rico Sennrich, Barry Haddow, and Alexandra Birch // Conference of the Association for Computational Linguistics (ACL). 2016.

Lample, G. Unsupervised machine translation using monolingual corpora only [Text] /Guillaume Lample, Alexis Conneau, Ludovic Denoyer, and Marc'Aurelio Ranzato // International Conference on Learning Representations (ICLR). 2018.

Ott, M. Analyzing uncertainty in neural machine translation [Text] / Myle Ott, Michael Auli, David Grangier, and Marc'Aurelio Ranzato // Proceedings of the 35th International Conference on Machine Learning. Vol. 80. 2018. P. 3956–3965.

Imamura, K. Enhancement of encoder and attention using target monolingual corpora in neural machine translation [Text] / Kenji Imamura, Atsushi Fujita, and Eiichiro Sumita // Proceedings of the 2nd Workshop on Neural Machine Translation and Generation. 2018. P. 55–63.

Graves, A. Generating sequences with recurrent neural networks [Text] / Alex Graves // arXiv, 1308.0850. 2013.

Vu Cong Duy Hoang, Philipp Koehn, Gholamreza Haffari, Trevor Cohn. Iterative backtranslation for neural machine translation [Text] / Vu Cong Duy Hoang, Philipp Koehn, Gholamreza Haffari, and Trevor Cohn // Proceedings of the 2nd Workshop on Neural Machine Translation and Generation. 2018. P. 18–24.

Cheng, Y. Semisupervised learning for neural machine translation [Text] / Yong Cheng, Wei Xu, Zhongjun He, Wei He, Hua Wu, Maosong Sun, and Yang Liu // Conference of the Association for Computational Linguistics (ACL). 2016.

Gade, F. A New Algorithm for Data Compression [Text] / Philip Gage // C Users J., 12(2):23–38, February.1994.

Sennrich, R. Neural Machine Translation of Rare Words with Subword Units [Text] / Rico Sennrich, Barry Haddow, and Alexandra Birch // Proceedings of the 54th Annual Meeting of the Association for Computational Linguistics (ACL 2016). Berlin, Germany. 2016.]

*Сулейманов Д.Ш., Гатиатуллин А.Р., Альменова А.Б., Баширов А.М.* Многофункциональная модель тюркской морфемы как база данных для лингвопроцессоров // Филология и культура. 2016. № 2 (44). С. 143–151.

*Сөләйманов Җ.Ш., А.Р. Гатиатуллин, Гыйльмуллин Р.А., Хөсәенов А.Ф.* Татар теле һәм яңа инфокоммуникацион технологияләр // Фәнни Татарстан. 2020. № 2. Б. 92б.

*Khusainov A., Suleymanov D., Gilmullin R.* The Influence of Different Methods on the Quality of the Russian-Tatar Neural Machine Translation. In: Kuznetsov S.O., Panov A.I., Yakovlev K.S. (eds) Artificial Intelligence. RCAI 2020. Lecture Notes in Computer Science, vol 12412. Springer, Cham. 2020. P. 251–261.

***Гыйльмуллин Ренат Абрек улы,***
*физика-математика фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Гамәли семиотика институты директоры*

***Хөсәенов Айдар Фаил улы,***
*техник фәннәр кандидаты, ТР ФА Гамәли семиотика*
*институты директор урынбасары*

***Сөләйманов Җәүдәт Шәукәт улы,***
*техник фәннәр докторы, ТР ФА Гамәли семиотика институты*
*фәнни җитәкчесе – баш фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***Ч.З. Абдуллина,***
***Ф.К. Сәгъдиева***

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ГАИЛӘ МОХИТЕНДӘ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

Знание и незнание языка тесно связано с образом жизни семьи и семейной культуры. В межнациональной семье большую роль играет язык как средство понимания и общения. Одной из сторон поликультурного воспитания в национально-смешанной семье является двуязычие. В этой статье рассматриваются вопросы, касающиеся относительно использования татарского языка в пространстве семьи. Результатами анализа проведенного исследования стали ответы на вопросы, которые возникли в процессе научно-исследовательской работы и обобщения, позволяющие сделать определенные выводы о применении татарского языка в сфере семьи.

**Ключевые слова:** татарский язык, родной язык, применение татарского языка в сфере семьи, язык общения в межнациональной семье, двуязычие, многоязычие.

Knowledge and non-knowledge of the language is closely related to the lifestyle of the family and family culture. In an interethnic family, language plays an important role as a means of understanding and communication. One of the sides of multicultural education in a nationally mixed family is bilingualism. This article discusses issues related to the use of the Tatar language in the family space. The results of the analysis of the conducted research were answers to questions that arose in the process of research work and generalizations, which allow making certain conclusions about the use of the Tatar language in family.

**Keywords:** Tatar language, native language, the use of the Tatar language in family, the language of communication in an interethnic family, bilingualism, multilingualism.

Гаилә ике кешенең ирекле рәвештә бер-берсе белән килешеп яшәү, уртак тормыш алып бару теләге белән мәхәббәт нигезендә корыла. Димәк, бу кешеләрнең тормышка карашларында, киләчәккә планнарында, рухи кыйммәтләргә мөнәсәбәтләрендә дә ниндидер уртаклык бар дип аңларга кирәк. Нәтиҗәдә, алардан соң дәвам итәчәк буын да шул карашларга нигезләнгән тәрбияне, мөнәсәбәтләр үрнәген кабул итә. Болар киләчәктә этник планда бара торган үзгәрешләрнең асылында чагылыш табарга тиеш була.

Кеше аңлы рәвештә «мин кем?» дигән сорауга җавап бирә алу дәрәҗәсенә ирешкәнче үк милли тәрбия ала, тел үзләштерә. Рухи кыйммәтләр, шул исәптән тел дә, кешегә генетик яктан салынмый, алар шәхес тәрбияләнгән мохит һәм максатчан тәрбия нәтиҗәсе буларак формалаша. Бала ике-өч яшендә сөйләшә башлый. Галимнәр күрсәтүенчә, сүзләрне үзләштерү гади лексик берәмлекләрне өйрәнүгә генә кайтып калмый, ә сүзләр белән бергә алар аша чагыла торган

рухи кыйммәтләр дә кабул ителә. Аралашу теле белән бәйле рәвештә аның дөньяны кабул итүе дә формалаша.

Гаилә тәрбиясенең беренчел булуын кире кагу мөмкин түгел. Ул сүз ярдәмендә тәрбия бирүгә генә кайтып калмый, сабыйның күреп өйрәнүе, гаиләдә башкалар кылганны кабатлавы аша тирәнрәк урнаша. Әгәр пөхтәлекне шәхси үрнәк белән күрсәтмичә, күп тапкырлар «пөхтәлек тиеш» дип кабатлауның нәтиҗәсез икәнен яхшы аңласак, гаиләдә туган телдә сөйләшмичә генә, бу бала нишләп туган телне белми, белергә дә теләми дип гаҗәпләнергә дә туры килмәс. Сабый туганыннан алып нинди телне ишетеп үсә, сөйләшүгә туган ихтыяҗын да шул телдә канәгатьләндерәчәк. Аның авызыннан чыккан тәүге авазлар, интонация һәм артикуляция дә шул телнең калыбына көйләнә.

«Туган тел барыннан да бигрәк гаиләдә саклана. Балага ана кеше биргәнне мәктәп тә, дәүләт тә бирә алмый. Без бит телебезне юкка гына «ана теле» димибез. Гаилә гомер-гомергә телне, мәдәниятне, димәк, барча милли кыйммәтләрне саклауга хезмәт иткән. Шуңа күрә без гаилә мөнәсәбәтләренә аеруча игътибарлы булырга тиеш» [Шәймиев, 1999, с. 57].

Гаиләдә нинди телнең туган тел буларак кабул ителүе, баланың теле нинди телдә ачылу һәм, гомумән, киләчәктә аның үзен кайсы милләт вәкиле итеп тануы мәсьәләсен хәл итү катнаш гаиләләрдә катлаулырак төс ала. Татарстанда катнаш никахларда руслар белән татарлар арасындагы никахлар өстенлек итә. Аларны икегә бүлеп карау кабул ителгән: рус – татар (ире рус, хатыны татар) һәм татар – рус (ире татар, хатыны рус) катнаш никахлар. Шулай ук татар – мари, татар – удмурт, рус – мордва катнаш никахлары еш очрый. Статистик мәгълүматларга караганда, рус милләтендәге хатын-кызларның катнаш никахка керүләре күбрәк теркәлгән. Катнаш никахларның сан ягыннан үзгәрешен һәм бүгенге хәлен билгеләү өчен, тулы картинаны күзалдына китерү кирәк. Моның өчен бераз тарихка күз салып алыйк. Инкыйлабка кадәр, ислам кануннары өстенлек иткәндә, катнаш никахлар сирәк очраган. Руслар һәм татарлар арасындагы катнаш никахларның дәрәҗәсен түбәндәге саннар да күрсәтә. Татарстандагы барлык катнаш никахлар санының чагыштырмасын караганда, руслар һәм татарлар арасындагы катнаш никахлар 1940 елда – 30,0%, 1960 елда – 44,7%, 1980 елда 65,4% тәшкил иткән [Столярова, 2004, с. 83].

Катнаш никахларның барлык никахлар саны белән чагыштырганда, 1940 елдан башлап 1980 елга кадәр бу күрсәткеч бары тик үсә генә бара. Ә инде 1985 елда – 20,2%, 1992 елда 23,4% тәшкил итә.

2020 елның 16 гыйнварында ТР Министрлар Кабинеты ЗАГС идарәсе башлыгы Гөлшат Нигъмәтуллинаның «Татар-информ»-га биргән мәгълүматларына караганда, Татарстанда яңа корылган һәр бишенче гаилә катнаш булып, шуларның 5% ы – чит ил гражданнары белән. Шул ук саннарга карасак, катнаш нигездә корылган

гаиләләр санының арта баруын күрәбез. Әйтик, 2015 елда ул барлык яшь гаиләләрнең 18% ын тәшкил итсә, 2020 елда 20% булган. 90 нчы елларда никахларның милли-дини традицияләргә нигезләнүе, дини ышанулары төрле булган милләт вәкилләре арасындагы никахлар санының беркадәр азаюына да китерә.

Ислам динендә башка диндәге кеше белән гаилә кору бөтенләй хупланмый. Бу бигрәк тә хатын-кызларга кагыла. Әгәр ир кеше никахланса, башта ул хатын-кызны ислам диненә күчерергә тиеш була.

Әмма катнаш никахлар бүгенге көндә кире кага алмаслык хакыйкать булып тора. Төрле халыкларның гасырлар дәвамында янәшә яшәве дә, хезмәт өлкәсендә, дөньяга карашларда, эшчәнлек төренә бәйле аралашуда якынлык туу да, миграция нәтиҗәсе дә, мәдәниятләр арасында чикләрнең тарая баруы да катнаш никахларның артуына этәрә. Аларның күпчелеге төрле милләт вәкилләре янәшә яшәгән урыннарга, зур шәһәрләргә һәм милли яктан чуар район һәм авыл җирлекләренә туры килә. Катнаш никахлар саны ягыннан шәһәр һәм авыл һәрвакыт аерылып торган. В.А. Рубцов үткәргән тикшеренүләр нәтиҗәсе буенча бүгенге көндә авылларда татар – рус катнаш никахлары, аларның гомуми саныннан 63% тәшкил итә [Рубцов, 2020, с. 55].

Татарстан Республикасында гаиләләрдә телләрне куллану, традицион рәвештә аны буыннан-буынга тапшыру ничек башкарыла? Әлеге мәсьәләнең асылын аңлатырга ярдәм итә торган берничә факторны күрсәтеп китү зарур. Иң элек, бу гаиләнең милли яктан нинди булуына һәм кайда яшәвенә дә карый. Шәһәр җирендә яшәгән татар гаиләләренең татар телен куллануы авылдагы татар гаиләләренекеннән шактый аерыла.

З.А. Исхакова үткәргән тикшеренүләрнең нәтиҗәләренә караганда, шәһәрдә яшәүче татарларның 36,1% ы – гаиләдә татар телендә, 24,3% ы – рус телендә, 31,7% татар һәм рус телләрендә бердәй аралаша. Русларның 97,1% ы гаиләдә рус телендә сөйләшә, 1,2% ы ике телне дә яхшы белә, 0,6% ы гаиләдә аралашу теле итеп татар телен сайлаган [Исхакова, 2001, с. 58–59].

Без үткәргән тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча, шәһәрдә яшәүче татарларның 35,9% ы гаиләдә татар телендә, 25,2% ы рус телендә, 30,1% ы татар һәм рус телләрендә бердәй аралаша, 8,8% ы – сорауны җавапсыз калдырды. Русларның 96,9% ы рус телендә сөйләшә, 1,3% ы татар һәм рус телләрендә, 0,4% ы һәм башка бер телдә аралаша, 1,4% ы – сорауны җавапсыз калдырды.

Без уздырган тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча, Татарстанның авылларында татарларның 89,8% ы – гаиләдә татарча, 3,0% ы – рус телендә, 4,8% ы – татар һәм рус телләрендә аралаша. Авылларда яшәүче русларның 81,8% ы гаиләдә рус телендә, 12,1% ы ике телдә дә бертигез дәрәҗәдә аралаша, 0,6% рус һәм башка бер телне куллана.

Шәһәрдә яшәүче икетелле татар гаиләләренең 30,7% ы мәктәпкәчә яшьтәге балалары белән, 24,8% ы мәктәп яшендәге балалары

белән татар телендә аралаша. Ә балаларның 21,5% ы үзара татар телендә аралаша [Исхакова, 2001, с. 59].

Әлеге күрсәткечләрдән түбәндәге нәтиҗә чыга: Татарстанда яшәүче татарларның 62,7% ы – гаиләдә татарча, 17,5% ы – татар һәм рус телләрендә, 14,5% ы рус телендә аралаша. Рус милләтеннән булганнарның 90,8% ы – гаиләдә рус телендә, 6,4% ы – рус һәм татар телләрендә, 0,9% ы рус телендә һәм башка бер телдә аралаша.

Татар гаиләләрендә рус телендә аралашуның сәбәпләре дә төрле.

Беренче сәбәп – совет чорында рус телендә белем алган һәм гомумән көнкүрештә дә, хезмәттә дә рус телендә генә аралашкан буынның һәм аларның балаларының татар телен начар белүе. Икенче сәбәп – авылдан шәһәргә килеп урнашкан һәм рус телен тиешле дәрәҗәдә белмәү нәтиҗәсендә авырлык кичереп, үз балаларына бары рус телен өйрәтүне генә максат иткән гаиләләрдә тәрбияләнеп, татар телен белмәүчеләр бүгенге көндә бары рус телендә генә аралашырга мәҗбүр.

Зур шәһәрләрдә татар телен саклап калу өчен, аны гаилә мохитендә куллану беренче шарт булып тора. Монда милли традицияләрне һәм телне саклап калуның зарурлыгын, тел кешенең рухи асылын тәшкил итүен аңлау кирәк. Авылларда татар теле гаилә мохитеннән тыш та киң кулланыла, барлык иҗтимагый функцияләрне дә үз өстенә ала.

Гаиләдә ата-ананың тел нормаларына игътибарлы булуы баланың киләчәктә ничек аралашуына төп өлге булып тора. Алга таба ул тормышта, һәр очракка туры китереп, шушы өлгене файдалана һәм аның аралашуында ул гадәти, кулланылышка кергән әзер калып буларак кулланыла. Шәһәр җирлегендәге татар гаиләләрендә дә татар теле белән рус телен катнаштырып куллану күренеше аеруча киң таралган.

Гаиләдә балага тел ягыннан дөрес тәрбия бирелгәндә генә ул туган телен дә, аралашу, белем алу өчен кирәк булган телне дә үзләштерү һәм дөрес куллану һәм аралаша алу культурасына ия була.

Телне саклауда өлкән буынның милли гореф-гадәтләргә игътибар бирүе дә зур роль уйный. Хәзерге вакытта буыннар арасындагы мөнәсәбәтләр югалып бара. Моның үз сәбәпләре бар. Беренчедән, иҗтимагый тормышта зур тизлек белән барган үзгәрешләр ике буын арасында дөньяга карашларның кискен аерылуына китерде. Икенчедән, шәһәр шартларында ике-өч бүлмәле фатирлар (бу күпчелек гаиләләрнең яшәү шарты) ике гаиләнең анда сыешып яшәү мөмкинлеген күпкә киметә. Шул сәбәпле яшь гаиләләр өлкәннәрдән аерым яши. Өлкәннәр бала тәрбияләүдә тиешенчә катнаша алмый. Аларның күбесе эшли, яки балалары шәһәрдә яшәү сәбәпле, ара ераклыгы да аралашу мөмкинлеген киметә. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, балаларның якынча 36,2% ы гына дәү әни һәм дәү әтиләре белән бергә яши. 30,2% ы җәйге каникулларын алар белән бергә үткәрә. 38,2% ы айга ике тапкырдан күбрәк күрешә, ә 25% бала дәү әти һәм дәү әнине бик сирәк күрә.

Мәктәп яшендәгеләр арасында сорашу барышында гаиләдә милли традицияләрнең сакланырга тиешлеген балаларның 79,1% ы уңай

бәяли, шуларның 48,2% ы әлеге гореф-гадәтләрне беләм, дип белдерә, ә 38,4% ы беләм һәм саклыйм, дип җавап бирә. Ләкин гореф-гадәтләр, милли үзенчәлекләр дигәндә, дини һәм халык бәйрәмнәре генә күздә тотыла. Ә гаилә традицияләре, аның үзенә генә хас йола бәйрәмнәре телгә алынмый диярлек. Килен токмачы, бәби ашы, исем кушу, өмә кебек бәйрәмнәр инде сирәк искә алына. Туйларның һәм башка бәйрәмнәрнең ресторанда, никахларның, исем кушу кебек йолаларның мәчетләрдә уздырылуы кумәкләшеп-ярдәмләшеп эшләүне дә, бу йолаларның үзенә генә хас булган тәртибен һәм лексик мөмкинлекләрен дә ярлыландыра.

Гаиләдә кече яшьтә нинди телгә өстенлек бирелсә, алга таба да кеше шул телдә аралашуын дәвам итә, икенче телгә аралашу ситуациясе таләп иткәндә генә күчә.

Нәтиҗә шундый: тел никадәр кечкенәдән өйрәнелсә, аны куллану мөмкинлеге дә шулкадәр зуррак. Монда тагын бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк: бала мәктәпкәчә яшьтә үк рус телен үзләштергән икән, димәк, гаиләдә рус телендә аралашу булган, яки баланың бу телдә сөйләшүе хупланган, аңа өстенлек бирелгән, дип нәтиҗә ясарга тиеш булабыз.

Мәсьәләне кайсы яктан гына карасак та, баланың туган телен белүе, яки башка бер телгә өстенлек бирүе, киләчәктә аралашуны нинди телдә дәвам итәчәге тулысынча гаиләдә кайсы телгә өстенлек бирелү белән турыдан-туры бәйле.

Катнаш никахларның бала теле формалашуга тәэсире шулай ук бик үзенчәлекле. Алда әйтеп үтелгәнчә, гаилә бала өчен шәхси үрнәк булып тора. Ул өлкәннәрдән күргән һәр нәрсәне кабатлау ярдәмендә тормыш тәҗрибәсе туплый. Аралашуга булган ихтыяҗын әзер сөйләм калыплары белән баета. Димәк, гаиләнең нинди телдә аралашуы гына түгел, ә ничек сөйләшүе дә зур әһәмияткә ия. Психологик тикшеренүләр шуны раслый: бала өлкәннәр телен өйрәнүне әнисе телен кабатлаудан башлый. Бу ана һәм баланың якынлыгы, ана кешенең эмоциональрәк, бала кабул итү өчен җиңелрәк, балаларча сөйләшүе, аның баланың тормышны аңлау югарылыгыннан торып әңгәмә алып баруы белән бәйле. Аналар игътибарлы, аңлаучан әңгәмәдәш, сөйләмне бала теләгән юнәлештә җиңел дәвам итә алалар; аралашу боеру, таләп итү тонында булмый.

Бу уңайдан мәсьәләнең икенче ягы ачыклана, катнаш никахларда, әни кеше татар милләтеннән булган очракта да, гаиләдә аралашу (һәм ананың бала белән аралашуы да) күбесенчә рус телендә алып барыла. Димәк, бала рус телен беренчел тел, туган тел буларак үзләштерә.

Галим Дж. Глисон хезмәтләрендә баланың социальләшүендә әти кешенең роле зур булу ассызыклана. Ул – аны катлаулырак дөнья белән таныштыручы, таләпчән, аның сөйләмендә бала өчен таныш булмаган һәм телнең катлаулы грамматик конструкцияләре дә күбрәк очрый. Әтисенең нинди телдә аралашуы, абруе да баланың теленә зур йогынты ясый.

Татарстандагы татар-рус катнаш гаиләләрендә (әти татар булган гаилә) аралашу рус телендә бара. Димәк, баланың татар телен өйрәнү мөмкинлеге юкка чыга. Иң беренче сәбәп – татарларның икенче тел буларак рус телен камил белүләре һәм рус телендә аралашуның алар өчен авырлык тудырмавы, ә никахтагы башка милләт кешесенең татар телен белмәве.

Бу бигрәк тә телләр арасында якынлык һәм туганлык булмаган (рус телле) рус – татар һәм татар – рус катнаш никахларына карый.

Нәтиҗәдә татар телендә сөйләшүче яшь буынның һәм үзен татар милләте вәкиле дип санаучыларның саны кими.

З.А. Исхакова Татарстандагы катнаш никахларның теле рус теле дип күрсәтә [Исхакова, 2001, с. 33].

Катнаш никахларның Татарстандагы демографик үсеш өлкәсенә йогынтысын өйрәнү мондый нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Әйтик, республикада 1990 елда катнаш никахтан туган балалар саны –20,5%, 1998 елда – 26,4%, 2002 елда 33,5% тәшкил иткән. 2010 елдан башлап республикада туган балаларның өчтән бере катнаш гаиләгә туры килә һәм бу никахларның зур күпчелеге руслар һәм татарлар арасында.

Катнаш никахтагы ата-аналар арасындагы сорашулар шуны күрсәтә: мәктәп яшендәге балаларның 50,1% ы гына әти-әнисенең милли-мәдәни традицияләре белән кызыксына. 38,6% ы бу кызыксынуның мәктәп программасына һәм андагы чараларга мөнәсәбәтле килеп туганлыгын күрсәтә. 5,3% ы әнисенең милли традицияләренә якынлык күрсәтә аның теленә өстенлек бирә, сәбәбен дәү әни һәм дәү әти белән аралашудан дип таный, 2,4% ы әтисе ягындагы милли традицияләрне якын итә, сәбәбе – гаиләдә шуларга өстенлек бирелү. Әти-әниләрнең 14,5% ы балаларының милли традицияләргә битарафлык күрсәтүен таный, 3,6% ы балаларының өченче халыкның милли-мәдәни традицияләренә кызыксыну күрсәтүен билгели. Яшь буынның катнаш никах мәсьәләсенә карашы төрлечә. Бу шулай ук тәрбиядән тора. Милләтне милләт буларак саклауда гаилә тәрбиясе гаять зур роль уйный. Әмма белем һәм тәрбия бирү системасы булган мәгарифнең йогынтысы да гаять зур. Моны балалар арасында уздырылган сораштыру нәтиҗәләре үк күрсәтеп тора. Мәсәлән, катнаш никахка Казандагы татар гимназиясе укучыларының 56% ы тискәре мөнәсәбәттә булса, рус гимназиясендә укучыларның 13% ы гына аны хупламый һәм 85% ы никахта милли аерымлык бернинди дә роль уйнамый дип саный. Әгәр бу гимназиядә укучы балаларның 40% ын татарлар тәшкил итүен исәпкә алсак, мәсьәләнең җитдилеге бик ачык.

Е.П. Бусыгин җитәкчелегендә Казан федераль университеты галимнәре «Этнические культурно-бытовые процессы в Среднем Поволжье» дип аталган фәнни тикшеренү үткәрде. Аның нәтиҗәләрендә Татарстанның суверенлык алуының республикадагы этник үзгәрешләргә зур йогынты ясаганлыгы чагыла. Бу уңайдан катнаш никахтагы милләт вәкилләренең һәркайсы үзенең кайсы этник төркемгә

каравын төгәл билгели. Татарстанда яшәүчеләрнең күпчелеге татар һәм рус милләтләренә хас төп билгеләрне алар арасындагы аермалы якларны, янәшә яшәү җирлегендә туган гомумилекне аңлы рәвештә кабул итә. Катнаш никахтан туган балаларның милләте әти линиясе буенча билгеләнә һәм шул телгә өстенлек тә бирелә, дигән фикер үткәрелә. Әмма күзәтүләр шуны күрсәтә, катнаш никахта туган баланың милләте гаиләдә килешү буенча, яки баланың әтисе яки әнисенең гаиләдәге таләбеннән чыгып билгеләнә. Бу милли аң югарылыгы белән бәяләнә. Катнаш никахтагы татар ирләре белән чагыштырганда, гарәп, төрек, азәрбәйҗан, грузин милләтеннән булган әтиләр балаларының үз милләте вәкиле буларак теркәлүенә зуррак игътибар бирә.

Катнаш гаиләләрдә никахны тәшкил иткән ике якның да телен, мәдәниятен тигез күрү, иң элек гаиләдә бер-береңә һәм өлкән буынга булган хөрмәтнең чагылышы булып тора.

Баланың нинди телгә өстенлек бирүе гаиләдә әти һәм әни кешенең абруе, аларның гаилә тормышыннан канәгатьлеге белән дә бәйле.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: республикабызда яшәүче гаиләләрдә татарларның 63% ы – тулысынча ана телендә, 14,5% ы бары рус телендә аралаша. Русларның 90,8% ы рус телендә сөйләшә. Катнаш никахтан туган балалар барлык баларның 30% ын тәшкил итә, әлеге санга бары рус телендә генә аралашучы татар гаиләләренең балаларын да өстәгәндә (алар 14,5%), туган балаларның яртысы диярлек гаиләдә үк бары рус телен генә үзләштерәчәк.

Үсеп килүче буынның 60% тан артыгының никахта милли аерымлыкларга битарафлык белдерүен исәпкә алганда, киләчәктә телгә карата мөнәсәбәтнең уңай якка үзгәрүе көтелми.

Туган тел һәм ана теле төшенчәләре – бердәй мәгънәле сүзләр. Ана кеше үзенең милләтен һәм ана буларак үз милләте алдындагы бурычын дөрес аңлаган заман өчен бу урында аңлатма кертү кирәк тә булмас иде. Ә ана үз баласы белән үз милләте телендә аралашмаган бер чорда туган телнең халкың теле булуы һәм аның сайлап алына торган тел түгел, ә милли мирас икәнлеген аңлату таләп ителә. Ана теле әни кеше сөйләшкән тел һәм туган тел буларак кабул ителә башлады. Иҗтимагый үсеш дәверендә төрле тайпылышлар күзәтелә. Бу тышкы гариплекләргә генә түгел, ә рухи тайпылышларга да кагыла. Кемдер динен, ә кемдер милләтен, телен алыштырырга тели. Тик шуны дөрес аңлау кирәк: әти-әнине сайлап алу мөмкинлеге булмаган кебек, милләтне һәм туган телне дә сайлап алып яки алыштырып булмый, аны югалтырга гына мөмкин.

Әлбәттә, тел һәм милли яшәеш канунарын саклау гаилә тәрбиясенә нигезләнә. Гаиләдә милли мохит, аралашу теленең сафлыгы, бу кыйммәтләргә карата хөрмәт булганда гына яшь буында да телгә, гореф-гадәтләргә уңай караш формалаша. Гаилә – җәмгыятьнең, үзе яшәгән дәүләтнең бер өлеше, ул аннан аерылгысыз. Бу очракта матди, рухи бәйләнешләрне кире кагу мөмкин түгел. Әмма гаиләнең дәүләт эчендәге, үзенә бер кагылгысыз, кечкенә дәүләт икәнлеген дә

онытмаска кирәк. Аның үзенең язылмаган кануннары, тәртипләре, мөнәсәбәтләре бар. Нинди дингә өстенлек бирүне, нинди телдә аралашуны, нинди тапшырулар карау, нинди китаплар укуны, кемнәрне үрнәк итеп кую яки нинди кыйммәтләргә өстенлек биреп, җәмгыятьтәге яшәеш кануннарының кайсысына тәнкыйть күзлегеннән карауны гаилә бары үзе хәл итә. Әгәр ул үзенең шул бурычын үтәмичә, яшь буынны тәрбияләүдән читләшә, аны җәмгыять иркенә калдыра икән, милли асылы нык булган шәхес урынына вакытлыча хакимлек итүче төркемнең ихтыярсыз иярчененә әверелгән буын формалаша. Ул җәмгыять өчен дә артык зур файда китерә алмый.

Алда әйтелгәнчә, гаилә тәрбиясен башка бернәрсә дә алыштыра алмый, әмма аңа юнәлеш бирүдә, мөмкинлекләр тудыруда, гаиләдән килгән традицияләрне дәвамлы итүдә дәүләтнең роле зур. Гаиләдә туган телендә сөйләшкән баланың мөмкинлекләрен үстерү һәм аны полилингваль шартларда белем алырга әзерләүне мәктәпкәчә белем бирү оешмалары дөрес юнәлештә дәвам итәргә тиеш. Үз туган телендә аралашкан сабый балалар бакчасына йөри башлап ике-өч ай үтүгә рус теленә күчеп беткән очракта, гаилә тәрбиясе нәтиҗәлелеген югалта.

Республикада иң элек гаиләнең дәвамы булган милли тәрбия бирүче һәм күптеллелек шартларына яраклашкан шәхес тәрбияләүче мәктәпкәчә белем бирү оешмалары һәм бу оешмаларның эшен дәвам итүче мәктәпләр булганда гына татар телен һәм башка туган телләрне киләчәк буынга тапшыру мөмкин булачак.

**Әдәбият**

*Исхакова З.А.* Двуязычие в городах Татарстана (80–90-е годы). Казань: Фикер, 2001. 192 с.

*Рубцов В.А.* Межнациональные браки и их влияние на этнодемографические процессы (на примере Республики Татарстан) // Геополитика и экогеодинамика регионов. Т. 6 (16). Вып. 3. 2020. С. 51–57.

*Столярова Г.Р.* Феномен межэтнического взаимодействия: опыт постсоветского Татарстана. Казань, 2004. 425 с.

*Шәймиев М. Ш.* Татарстан Республикасы Президентының II Бөтендөнья татар конгрессына котлау сүзе // Языковая политика в Республике Татарстан: Документы материалы (80–90-е годы) / Татарстан республикасында тел сәясәте: Документлар һәм материаллар (80–90 нчы еллар). Казан: Мәгариф, 1999. 341 б.

*Мәкалә «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасының 3.19 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Абдуллина Чулпан Зөфәр кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты*

***Сәгъдиева Фәүзия Кәбир кызы,***
*филолоия фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми тел белеме бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре,*

УДК 821.512145/82-312.2

*Ә.М. Шәрипов*

# ГАБДЕРӘХИМ УТЫЗ ИМӘНИНЕҢ ДИНИ-СУФИЧЫЛ ТРАКТАТЛАРЫ

Статья посвящена раскрытию содержания научных трактатов (рукописей) известного татарского поэта и мыслителя XVIII–XIX веков Габдрахима Утыз Имяни на религиозные темы, написанных на арабском языке. Основываясь на переводы текстов этих трактатов на русский язык, осуществленных Р.К. Адыгамовым, в статье излагаются основные положения данных рукописей, указывается на их значение для современной жизни татарского народа.

**Ключевые слова**: ученый, творчество, рукопись, трактат, перевод, арабский язык, стихотворение, религия.

The article is devoted to the disclosure of the content of scientific treatises of the famous Tatar poet and thinker of the 18th–19th centuries Gabdrakhim Utyz Imyani on religious topics, written in Arabic. Based on the translations of the texts of these treatises into Russian made by R.K. Adygamov the article outlines the main provisions of these treatises, indicates their importance for the modern life of the Tatar people.

**Keywords:** scientist, creation, manuscript, treatise, translation, Arabic language, poem, religion.

Габдерәхим Утыз Имәни (1754–1834) үз чорының күренекле шагыйре генә түгел, ә танылган дин галиме дә булган. Аның гыйльми һәм әдәби иҗаты чама белән 1774 еллардан башлана һәм үзенең вафатына кадәр дәвам итә. Алтмыш елга якын сузылган иҗат дәверендә ул, бүгенге мәгълүматлар буенча, йөздән артык хезмәт язып калдырган. Аның иҗатын, биографиясе белән бәйләп, шартлы рәвештә өч чорга бүлеп өйрәнергә мөмкин: 1) башлангыч чор иҗаты (1774–1788); 2) Урта Азиядә яшәгән еллар иҗаты (1788–1798); 3) туган илдә иҗат иткән чор (1798–1834).

Габдерәхимнең гыйльми һәм тәрҗемә эшчәнлеге шактый иртә башлана. Мәдрәсәләрдә гарәп-фарсы телләрен, Коръәнне, тәфсирләрне, шәригать хөкемнәрен тирәнтен өйрәнү аны әкренләп фән дөньясына алып керә. Беренче чиратта ул ислам дөньясында халыкара фән теле булып саналган гарәп телен һәм классик поэзия теле булып исәпләнгән фарсыны бик яхшылап өйрәнә, хәтта шул телләрдә гыйльми хезмәтләр дә яза башлый.

Габдерәхим Утыз Имәнинең гыйльми эшчәнлеге, нигездә, өч юнәлештә алып барылган: 1) үзе өйрәнә торган гарәпчә, фарсыча китаплардагы авыр аңлаешлы сүзләргә сүзлекләр төзү, терминнарны аңлату; күренекле китапларга шәрех-комментарийлар язу; 2) гарәпчә һәм фарсыча фәнни хезмәтләрне тәрҗемә итү, ислам диненең гамәли һәм теоретик мәсьәләләре хакында гарәп-фарсы телләрендә гыйль-

ми трактатлар язу; 3) китаплар күчерү, күренекле әсәрләрнең дөрес, фәнни текстларын булдыру, ягъни текстология өлкәсендәге эшчәнлек.

Зирәклеге, үткен зиһене белән ул яшьтән үк үз сабакташлары арасында «укымый белә торган шәкерт» булып танылган, бераздан хәтта яшьтәшләренә дә хәлфәлек итә башлаган. Укыган саен, аның аңында ислам диненең яңа сәхифәләре, фикерләвенең яңа тирәнлекләре, яңа офыклары ачыла барган. «Белем алырга комсыз» бу шәкертне, әлбәттә, бераздан авылдагы зур булмаган мәдрәсә, андагы гыйлем дөньясы, аралашу сферасы гына канәгатьләндерә алмый башлый. Һәм ул күрше авыл мәдрәсәләренә китеп белем ала, яңа мөгаллимнәр белән аралаша. Аның 1782 елда Кизләү (хәзерге Аксубай районы Иске Кыязлы) авылында яшәгәнлеге һәм шул елда ук Урта Азия галиме Гали бине Хисамеддин Һиндинең Корьән аятьләре турында китабындагы авыр аңлаешлы сүзләрне аңлатып, гарәпчә сүзлек төзегәнлеге билгеле. Бу турыда әдип үз кулы белән язып калдырган.

Фәндә Утыз Имәнинең гыйльми эшчәнлегенең башлангыч чорын күзалларга ярдәм итә торган бер язма сакланып калган. Әдипнең үзе язган бу документта болай диелә: «Язылды: беренче – «Шәрхе «Сөбател-гаҗизин», икенче – «Шәрхе «Морадел-гарифин», өченче – «Төхфәтел-әхбаб фи тәҗвиде кәляме раббел-мәҗид», дүртенче – «Гыйльме тәҗвид әт-төрки», бишенче – «Лөгате «Җамигъ эр-ромуз», алтынчы – «Төхфәт әл-гораба», җиденче – «Рисаләтел-әсма»... Габдерәхим бине Госман Болгари кулы белән 1210 елда (милади белән 1795 елга туры килә), шәүвәл аеның ахырында тәмам булды». Моннан күренгәнчә, Утыз Имәни 1795 елга кадәр үзе иҗат иткән җиде әсәрне атый, шуларның бишесе – гыйльми хезмәтләр. Ләкин әлеге исемлек өзелеп калган. Шуннан чыгып, ул монда үзенең барлык әсәрләрен дә искә алмагандыр дип уйларга мөмкин.

Исемлектән күренгәнчә, Габдерәхим әле яшь чагында ук Урта Азия әдибе Суфи Аллаһиярның ислам дине нигезләрен аңлаткан китапларын өйрәнгән. Ризаэддин Фәхреддин Утыз Имәнинең Суфи Аллаһиярны үзенең остазы итеп санаганлыгын әйтә. Ул Суфи Аллаһиярның ике атаклы китабына гарәп телендә шәрех-аңлатма язган: беренчесе – борынгы төрки телдәге «Сөбател-гаҗизин» («Аллаһка ялваруда ныклык»), икенчесе – фарсы телендәге «Морадел-гарифин» («Укымышлыларның максаты»); шуның белән төрки телдә язылган хезмәтләрнең гарәп телле киң аудиториядә таралуына да үзеннән билгеле бер өлеш керткән. Утыз Имәни язган бу китаплар үз чорында шактый популяр булган: алар кулдан-кулга күчеп йөргән. Мәсәлән, бүгенге көндә беренче шәрех китабының барлыгы җиде күчермәсе (иң әүвәлгесе 1782 елда язылган), ә икенче шәрех китабының алты күчермәсе (иң әүвәлгесе 1811 елга карый) билгеле. Әмма бу кулъязмаларның берсе дә Габдерәхимнең үз кулы белән язылмаган, ә Гадерәхим кулъязмасыннан башка кешеләр күчергән нөсхәләр; димәк, әдип ул шәрехләрне аларда куелган даталардан алдарак язган булып чыга. Биредә шуңа да игътибар итәргә кирәк: бу шәрех-

аңлатмаларны язганда, Габдерәхимнең Аллаһы Тәгалә тарафыннан салынган шагыйрьлек куәсе һәрдаим җилкендереп торган, ахрысы: ул һәр ике шәрехне язып тәмамлагач, укучыларга адреслап, үзенең шигъри мөрәҗәгатьләрен дә өстәгән. Беренче шәрех китабы азагына «Улды ахыр бу кәлям...» дип башланган 16 юллы шигырен, икенче шәрех китабы азагына «Бәйте Аллаһйар бәкдин...» дип башлана торган 18 юллы шигырен язып куйган. Шулай итеп, яшь вакыттан ук аның гыйльми эшчәнлеге һәм шигъри иҗатының бер-берсенә үрелеп, янәшә баруын күрәбез. Бу бергәлек аның бөтен иҗатын колачлый.

Утыз Имәнинең фәнни-иҗади мирасында аның дини-теоретик һәм дини-гамәли трактатлары зур урын алып тора. Ул гарәп телендә барлыгы тугыз трактат язып калдырган. Бу хезмәтләрне соңгы елларда гарәп теле белгече, галим Рамил Әдһәмов өйрәнде. 2005 елда ул рус телендә «Габдрахим Утыз-Имяни» дигән монография дә бастырып чыгарды. Ә 2007 елда Утыз Имәнинең 9 дини трактатын русчага тәрҗемә итеп, аларга фәнни аңлатмалар язып, текстларын бастырды. Бу китапта Утыз Имәнинең шәригать хөкемнәре һәм суфичылык турында язылган «Рисаләи дәбәгъгать» («Тире иләү рисаләсе»), «Җәваһирел-бәян» («Сүзләрнең җәүһәрләре»), «Инказел-халикин» («Һәлакәткә очраучыларны коткару»), «Рисаләи иршадия» («Туры юлга кертү рисаләсе»), «Рисаләи шәфәкыя» («Шәфәкъ рисаләсе»), «Сәйф әс-сарим» («Үткен кылыч»), «Төхфәтел-әхбаб фи тәҗвид кәлам әр-Рабб» («Раббе китабын дөрес уку турында дусларга бүләк»), «Зәмме шөрби чәй» («Чәй эчү белән мавыгуны шелтәләү»), «Рисаләи мөһиммә» («Мөһим мәсьәләләр рисаләсе») исемле фәлсәфи трактатлары җентекләп анализлана[1]. Шулай итеп, күренекле мәгърифәтче, шагыйрь һәм ислам галиме Утыз Имәнинең күпкырлы иҗат мирасы бүгенге укучыга шактый тулы килеп җитте.

Югарыда саналган трактатларның кайберләрен Габдерәхим Урта Азиядә яшәгәндә (1788–1798) иҗат иткән. Анда ул күп вакытын галимнәр белән аралашып, китапханәләрдә гыйлем эстәп үткәргән. Мәшһүр китаплар укыган, аларга шәрехләр язган, татар теленә тәрҗемә иткән, гарәп һәм фарсы телләрендә дин мәсьәләләренә караган трактатлар иҗат иткән, сүзлекләр төзегән, китаплар күчергән. Бу турыда ул Урта Азиядән кайткач язылган «Гавариф эз-заман» («Замана укымышлылары») поэмасының «Фасыл дәр бәйани сәр гөзәшт» («Баштан үткән хәлләрне сөйләүче бүлек») дигән беренче бүлегендә болай ди (бу өзек юлга-юл тәрҗемәдә бирелә):

*Булдым олы затлар җыелган урыннарда,*
*Аларның яннарында тыңлап утырдым.*
*Тирән диңгезгә чумып, энҗеләр алдым,*
*Гамәл кылу өчен күңелемә салдым.*
*Мәгариф бакчасыннан җимешләр җыйдым,*
*Мәсьәләләрнең игътибарга лаегын эзләдем.*

---

[1] Бу мәкаләне язганда Рамил Әдһәмовның әлеге монографиясеннән файдаландык.

*Аларны сайлап алып тараттым,*
*Бу эштә күп уңышларга ирештем.*
*Гыйлем белән шөгыльләнүдән нурым артты,*
*Наданлык тузаны-пычрагы беркадәр бетте.*

Урта Азиядә Габдерәхим иң элек дин һәм гыйлем өлкәсендә үзенең кумиры дип санаган атаклы галим Әбү Хәмид Мөхәммәд бине Мөхәммәд әл-Газалиның «Ихйа әл-голүм әд-дин» («Дин гыйлемен тергезү») хезмәтен җентекләп өйрәнгән, 212 битле шул китапны күчергән, анда очраган авыр аңлаешлы сүз-тәгъбирләрнең алфавит тәртибендәге 55 битлек гарәпчә-фарсыча сүзлеген төзегән. Үлмәс Беляева бу турыда: «Утыз Имәни бу кулъязмасын Бохарадагы Муса углы Габдулла әл-Болгари дигән бер сәүдәгәргә бүләк иткән. Ул сәүдәгәр турында Утыз Имәни болай ди: «Сәүдәгәрләр – алар усал төлкеләр, ләкин бу сәүдәгәр бөтен фәннәр белән кызыксынучы, гыйлемгә хөрмәт белән караучы, китапларның кадерен белүче иде. Шуңа күрә бу китабымны аңар бүләк итеп бирдем», – дип яза [Беляева, б. 153–154]. Әл-Газалиның «Ихйа әл-голүм» китабы белән бергә сүзлек тә күчерелгән. Габдерәхимнең үз кулы белән язылган бердәнбер нөсхәсе Казан Федераль университеты Фәнни китапханәсендә саклана (447 г. кулъязмасы, 351б–406б б.)

Урта Азия галиме Шәмсетдин Мөхәммәд әл-Хорасаниның (аны әл-Каһстани дип тә йөртәләр) «Җамигъ эр-ромуз» («Символлар җыентыгы») хезмәтенә карата да Габдерәхим шул ук эшне башкарган. 371 битле бу китапны ул башта күчереп язган, аннан андагы авыр аңлаешлы сүзләрнең 25 биттән торган гарәпчә-фарсыча сүзлеген төзегән (сүзләр монда да алфавит тәртибендә китерелгән), аерым сүзләрнең мәгънәләре татарча да аңлатылган. Хезмәтенең башында ул үзенең тумышы белән Болгар иленнән булуы, Бохарада торуы хакында әйтеп китә. Сүзлектән соң «Җамигъ эр-ромуз»да телгә алынган галим һәм укымышлылар исемлеге (барлыгы 277 исем), алар хакында кыскача мәгълүматлар китерелә. Иң ахырда «Җамигъ эр-ромуз»ны язганда Шәмсетдин әл-Хорасани файдаланган китаплар исемлеге (барлыгы 295 китап) теркәлә. Хезмәтнең 1793 елда язылганлыгы турында да мәгълүмат бар. Утыз Имәнинең бу сүзлеге еш кына «Җамигъ эр-ромуз» хезмәте белән бергә күчерелгән. Сүзлек 1882 елда Казанда «Халь әл-лөгать һәза китабе мөшкилят «Җамигъ эр-ромуз» ли-Шәмсетдин Мөхәммәд әл-Каһстани» («Шәмсетдин Мөхәммәд әл-Каһстаниның «Җамигъ эр-ромуз» китабындагы сүзләрнең мәгънәви хәле») исеме белән басылып та чыккан.

Утыз Имәнинең әлеге сүзлеге үз чорында шактый популяр булган. Аның барлыгы унбер күчермәсе билгеле: аларның бишесе – Санкт-Петербургта (Көнчыгышны өйрәнү институты китапханәсендә), дүртесе – Казан Федераль университеты Фәнни китапханәсендә, берсе –Татарстан Милли Музее архивында һәм берсе Үзбәкстан Республикасы Фәннәр академиясе китапханәсенең кулъязмалар бүлегендә саклана. Габдерәхимнең үз кулы белән язылган нөсхәдәге

өстәлгән бер биттә аның укучыларга мөрәҗәгать итеп язылган «Бәет ли-мөәллиф» («Автор шигыре») дигән 14 юллы фарсыча шигыре дә бар.

Утыз Имәни күренекле фарсы шагыйре Җәлалетдин Руминың (1207–1272) иҗаты белән җитди кызыксынган. Аның бөтен Шәрык дөньясында атаклы «Мәснәви шәриф» («Хөрмәтле мәснәвиләр») поэмасын гарәп дөньясында да танытырга омтылып, андагы авыр аңлаешлы сүзләргә фарсыча-гарәпчә сүзлек (119 б.) төзеп, аңлатмалар язган. Гаҗәеп тирән белемнәр таләп иткән бу эшне ул уңышлы башкарып чыккан һәм шуның белән дөньякүләм әһәмияткә ия иҗатны пропагандалауга үзенең өлешен керткән. «Мохтасар ләтаиф әл-лөгать лил-мәснәви» («Мәснәвиләр телендәге нечкәлекләрне кыскача аңлату») исемле бу кульязма Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсендә саклана. Моннан тыш Утыз Имәни Җәлалетдин Руминың «Былбыл вә гөл» поэмасын фарсычадан татарчага тәрҗемәләгән. Ахырда үзенең 30 юллык «Тәсәррыф әйләйүбән сәгъи җидди...» («Нык тырышлык сарыф иттем мин...») дип башлана торган шигырен дә теркәп куйган. Ул анда болай ди (өзек юлга-юл тәрҗемәдә китерелә):

*Нык тырышлык сарыф иттем мин,*
*Язып алдым бу «Гыйшкы Руми» китабын.*
*Тәмам иттем Хода ярдәме белән,*
*Бу Гариб Болгари кулы белән.*
*Ул күп нәрсәләр белән чагыштырылды,*
*Барлык күчермәләрнең төзегрәге булды.*
*Язам дигән кешеләр яза моннан...*

Бу эшне кем өчен башкарганын болай аңлата:

*Яздым мин бу китапны үзем өчен,*
*Үземнән соң калган балаларым өчен.*
*Һәм дә мең мөселман мохтаҗ булса,*
*Укыйм яки язам дип сорар булса, –*
*Кызганмыйча аңа да бирүче мин...*
*Утыз көн дәвамында яздым, и ай йөзле,*
*Һәр ике дәфтәрне, Аллага шөкер.*
*Төпләп куйдым аны ике бүлеккә,*
*Һәр мохтаҗ кеше берсен алсын кулына...*
*...Ул дин кешеләре, моны укыганда,*
*Колак салып тыңлап, ишетсеннәр,*
*Дога белән мине искә алсыннар,*
*Сынык күңелемне шат итсеннәр...*

Урта Азиядә Утыз Имәни шулай ук Шәрык галиме Шәмси Әхмәд Казыйзадәнең (1580 елда вафат) дә «Тәнаих әл-әфкяр фи кәшеф эр-ромуз вә әсрар» («Символларны һәм серләрне ачуда фикерләрнең каршылыклары») исемле китабын күчереп язган һәм азакта, аны укучыларга тәкъдим итү рәвешендә, «Нәзмы Габдерәхим Болгари фи

хаккы Казыйзадә» («Казыйзадәнең «Хокук» китабы турында Габдерәхим Болгари шигыре») дигән 120 юллык шигырен дә китергән. Анда шагыйрь Шәмси Әхмәд Казыйзадәнең бу китабын «күңел афәтләренә шифа бирүче бер гаҗәеп нөсхә» дип атый, *«күреп, төрки имеш дип, санма җиңел», «әгәр төрки булса да, гаҗәеп мөшкел булган җирләре бар»*, дип, аны бик тырышып өйрәнергә киңәш бирә. Әлеге сүзләр, фән һәм поэзия өлкәләрендә бары гарәп һәм фарсы телләре генә хакимлек иткән ул заманда, шагыйрьнең төрки телгә халыкара дәрәҗәдә хокук таләп итүен дәлилли һәм аның бу адымы аерым игътибарга лаек. *«Ул кырык китаптан файдаланып язылган, моны белгән кеше камиллек табар, күңеленә мәгърифәт җиле тулыр. Аны күчереп язып алып, барлык улларыңа, кызларыңа, хатыннарыңа шуннан сабак бир»,* – ди ул һәм дүрт нөсхәне чагыштырып чыгуын әйтә. *«Әлеге китапны язарга теләгәннәр шушы нөсхәдән язсыннар»,* – дип ассызыклап та куя. Бу шигырь тексты без алда күргән «Тәсәррыф әйләйүбән сәгъи җидди...» белән аваздаш, хәтта «Тәсәрреф...»тәге соңгы 8 юл кабатланып та килә.

Утыз Имәни XVII гасырда Бохарада яшәгән Мәүләви мелла Кари китабының берничә күчермәсен үзара чагыштырып, текстологик эш башкарган һәм ахырга үзенең «Мәнзум» («Шигырь») дигән 34 строфалы шигырен язып куйган. Мөрәҗәгать-шигырьдә ул шул заман укымышлыларының теоретик мәсьәләләргә (хикмәт, фәлсәфә фәннәренә) бирелеп, туры юлдан читкә чыгуларын, шәригать сүзе белән эш итмәүләрен тәнкыйтьли. Гакыйдә (ышану, иман) гыйлемен «сөйләп бирүче», хәнәфиләр мәзһәбенә нигез салучы Әбү Хәнифәне аларга үрнәк итеп куя. Аның юлыннан барган мелла Кариның китабын мактый: *«Ул күп шәрех һәм хәдисләрне аңлатып бирүче, аның тикшеренүләрен барысы да таный, сүзләренә барысы да ышана, белем ияләре дә аны кабул иткән. Шуңа күрә бары аның шәрехаңлатмаларына гына ышан, бүтән аңлатучылар сүзенә һич карама»,* – ди. Шулай итеп, Урта Азиядә Утыз Имәни, нигездә, атаклы ислам галимнәренең хезмәтләрен өйрәнә, китап басу эше әле таралмаган вакытта аларны армый-талмый пропагандалый.

Бу чорда Габдерәхим шигырьләр һәм поэмалар да иҗат иткән. Фарсы телендә язылган «Бәет дәр зәмми суфийан мә-замана» («Замана суфиларын шелтәләү бәетләре», 24 строфа), «Мәүләви Җами гүяд...» («Мәүләви Җами әйтә...», 12 строфа), «Газәлияте тәүсыйфы Сәет Мостафа Сәлләми Руми» («Сәет Мостафа Сәлләми Румины сыйфатлау газәлләре», 19 строфа), «Мелла Бәкер көҗаи?» («Мелла Бәкер кайда ул?», 38 строфа) исемле шигырьләре шагыйрьнең Урта Азиядә яшәгән елларына нисбәт ителә.

Биредә Утыз Имәни гарәп телендә «Замме шурба әч-чәй» («Чәй эчүне шелтәләү»), «Рисаләи иршадия» («Туры юлга кертү рисаләсе»), «Инказ әл-һаликин» («Һәлак булучыларны коткару»), ә фарсы телендә «Сәеф әс-сарим» («Үткен кылыч») трактатларын да язган. «Замме шурба әч-чәй» трактатында ул Урта Азия халыклары

(үзбәкләр, таҗиклар) арасында киң таралган чәй эчүнең зарарлы да булуын әйтә. Чәй эчү белән артык мавыгуны Утыз Имәни бидгать, ягъни ортодоксаль дини тәгълиматка туры килми торган яңа гамәл дип саный; гәрчә ул шәригать тарафыннан тыелмаса да, шагыйрь чәй эчүнең 27 төрле тискәре ягын күрсәтә: чәйне бик теләп, кешенең хайвани теләген канәгатьләндерү максатында, Аллаһны онытып эчү; чәйне иртән иртүк, иртәнге намазны да укымыйча, эчә башлау; чәй эчүне күңел ачу чарасына әверелдерү; бер утырганда бик күп, кырыклапиллеләп чәшке чәй эчү; чәйне кайнар көе эчү (ул организмга зарар китерә); чәй эчкәндә шикәр, бал, төрле тәм-том куллану; эчәсе килү беткәннән соң да чәй эчү; чәй эчкәндә алтын яки көмеш савыт-саба куллану (ул күп чыгымнар сорый) һ. б. Монда шагыйрьнең көндәлек гамәлләрне шәригать кануннарына буйсындырырга теләве чагылыш таба.

«Рисаләи иршадия» хезмәтендә Утыз Имәни исерткеч эчемлекләр, аерым алганда аракы эчүгә каршы чыга. Балага кечкенәдән үк аракының зарарлы икәнен аңлатып үстерергә кирәк, ди. Аракы шәригать тарафыннан да, акыл-аң нисбәтеннән дә тыела. Аллаһ кешене яралткан вакытта Җәбраил фәрештә аркылы аңа өч зур бүләк бирә: акыл, инану һәм оят (оялу). Адәм галәйһиссәламгә шулар арасыннан берсен сайлап алырга тәкъдим итә. Адәм галәйһиссәлам акылны сайлап ала һәм аны болай аңлата: акылдан башка инану юк, ә оят (оялу) инану белән бәйле. Шушы риваятьтән чыгып, без Аллаһның үз колларына биргән иң зур хәзинәсе – акыл, дигән нәтиҗәгә килә алабыз. Акыл кешенең рухи дөньясының асылын тәшкил итә. Кем үзенең акылын саф килеш саклый, шул кеше ике дөньяда да хөрмәткә ия була; ә кем үз акылы турында кайгыртмый, ул ике дөньяда да хурлыкта кала, Аллаһның дошманына әверелә. Шуңа күрә һәр кеше үзенең акылын тоныкландыра торган нәрсәләрдән, аерым алганда, аракыдан сакларга тиеш. Ихлас мөселманнар нәкъ шулай эшлиләр дә. Ә Русия мөселманнары, Утыз Имәни карашынча, бу мәсьәләгә җитәрлек игътибар бирмиләр һәм аракы да эчәләр, тәмәке, насвай да тарталар. Әгәр кеше аз гына аракы эчсә дә, аның күңеленә шайтан кереп утыра һәм уй-фикерләре, теләкләре белән идарә итә башлый; инсан ихтыярсыз аңа буйсына, ярамаган гамәлләр кыла башлый. Аллаһ андый кешенең тәүбәсен дә кабул итми. Шушы урында әдип аракының хәрәм булуы, аны эчүдән тыелу зарурлыгы турындагы хәдисләр һәм атаклы дин галимнәре хезмәтләреннән мисаллар китерә. Шул рәвешле, Утыз Имәни үз милләтенең сафлыгы, чисталыгы, төзеклеге хакында да кайгырткан булып чыга. Аның бу фикерләре бүген дә актуаль яңгырый.

«Инказ әл-һаликин» («Һәлак булучыларны коткару») трактаты ислам динендәге кәлям, мантыйк һәм фәлсәфә мәсьәләләренә багышланган. Утыз Имәни кешенең белемле булуына зур әһәмият бирә. Ул исламда дүрт мәзһәбкә нигез салган галимнәрне атый. Үзе Хәнәфи мәзһәбендә булу сәбәпле, шуңа нигез салган Әбү Хәнифә шәхесенә,

аның юнәлешен аңлатуга аеруча зур игътибар бирә. Барлык белемнәрне ул ике төргә бүлә: фарыз гайн һәм фарыз кифая. Фарыз гайнны һәр мөселман кешесе белергә тиеш. Мәсәлән, әгәр кеше рибачылык (процентка акча биреп тору) таралган җирдә сәүдә белән шөгыльләнә икән, ул бу рибачылыктан ничек котылу юлын белергә тиеш; бу аның өчен иң беренче бурыч, ягъни фарыз гайн булып санала.

Белемнең икенче төре, Утыз Имәни фикеренчә, җәмгыять белеме – фарыз кифая. Аны аңлатканда, ул әл-Газалиның «Ихйа голүм әд-дин» («Дин гыйлемен тергезү») китабына таяна. Фарыз кифая ул – җәмгыятьтәге проблемаларны хәл итүгә юнәлтелгән белемнәр. Мәсәлән, медицина безнең тәнне (бәдәнне) сәламәт тотуга ярдәм итә; арифметика кешеләр белән мөнәсәбәткә кергәндә, мирасны бүлгәндә кирәк. Бу фикерне үстереп, Утыз Имәни болай яза (тәрҗемәдә бирелә): *«Игенчелек тә, балык тоту да, идарә итү, хәтта кан алдыру да – барысы да иҗтимагый бурыч булып санала. Үзегез уйлап карагыз: әгәр берәр регионда кан алдыру белгече булмаса, анда яшәүчеләр арасында авырулар тарала, ә бу аларны үлемгә илтә».* Әдип фикеренчә, әгәр берәр җәмгыятьтә кирәкле белгечләр юк икән, ул чакта анда яшүчеләрнең барысы да гөнаһлы булып санала. Шулай итеп, мөселман җәмгыятендә җитәкчеләр дә, гади халык та уйлап эш итәргә тиеш, дигән фикер үткәрелә. Шагыйрь татар җәмгыятен үзҗитешле, бәйсез итеп һәм үсештә күрергә омтыла.

Утыз Имәни магия (сихерчелек, күрәзәчелек) һәм астрологияне кирәкмәгән һәм зарарлы гыйлемнәр дип күрсәтә. Ә кәлям һәм фәлсәфәне шикле, шелтәләнә торган белемнәр рәтенә кертә. Алар бигрәк тә белемсез, надан һәм иманы нык булмаган кешеләрне ялгыш юлга кертеп җибәрә, адаштыра, дип саный ул. Утыз Имәни фикеренчә, фәлсәфә китапларын бары бик белемле мөселман гына дөрес аңлый ала. Кәлям, фәлсәфә һәм мантыйк фәннәрен өйрәнүнең кирәксез гамәл булуын исбатлау өчен, Утыз Имәни ислам галимнәре китапларыннан күп кенә өзекләр китерә.

Утыз Имәни формаль логик фикерләүгә нигезләнгән кәлям фәненең килеп чыгышына җентекләп туктала һәм аның барлыкка килүен соңгы гасырлардагы ислам галимнәренең бәхәсләргә һәвәс булуларыннан дип аңлата. Ул чынбарлыктан һәм гамәлияттән ерак торган коры фәлсәфә һәм мәгънәсез бәхәсләшүгә каршы чыга. Мондый гамәл татар кешесенә берни бирми. Ә татар иҗтимагый фикеренең торгынлыгына каршы көрәш Габдерәхим өчен ул чорда иң мөһим мәсьәлә булып тора.

«Сәйф эс-сарим» («Үткен кылыч») трактатын Утыз Имәни шәригать кануннарын һәм үзенең суфичыл карашларын бәян итүгә багышлаган.

Ул кешеләргә кирәкле байлыкны ике төргә бүлеп карый: 1) яшәү өчен кирәк кадәрле генә байлык; 2) кирәгеннән артык байлык. Гадәттә аларны бер-берсеннән төгәл генә аерып та булмый, чөнки кеше еш кына кирәгеннән артыкны да тели башлый. Шуңа күрә автор бу

өлкәдәге тәкъвалыкны болай аңлата: һәр кешедә алты төрле хаҗәт (ашау-эчү, киенү, торак йорт, өй җиһазлары, өйләнешү, җәмгыятьтә тоткан урын) була. Г. Утыз Имәни шуларның һәрберсенә аерым-аерым туктала. Мәсәлән, ашау-эчүгә килгәндә, әгәр кешедә бер көнлек азык бар икән, ул шуңа риза булып яшәргә тиеш. Әгәр азык аннан артык икән, яки кеше ашау-эчүне үзмаксат итеп куя икән, ул инде тәкъва, ягъни суфи булып саналмый. Кием-салымга килгәндә, әгәр кешедә үзен салкыннан яки эсседән сакларлык, үзенең ялангачлыгын капларлык бер күлмәк-чалбар, бер баш һәм аяк киеме бар икән, ул шуның белән канәгать булып яшәргә тиеш. Әгәр бу киемнәр аңарда икәү, яки артыграк та икән, ул инде тәкъва була алмый. Байлык җыюга килгәндә, суфи бер көнгә җитәрлек байлыкка канәгать булырга тиеш. Үзенең теләкләрен тыя алмаган кеше үзен тулысы белән шул байлыкка бәйләп куя һәм аннан чыга да алмый. Ә чын мөселманнар бу дөньяның алдагыч бизәкләренә, тылсымнарына ышанмый. Дөнья байлыгы ул – кешегә вакытлыча, әҗәткә генә биреп торылган байлык. Дөньядан киткәндә кеше ул байлыкны калдырып китә, үзе белән ул бары дөньялыктагы игелекле эш-гамәлләрен генә ала. Дөнья ул кешенең бишектән алып кабергә кадәр үтә торган күпере кебек; кемдер күпернең әле башында гына, кемдер аның уртасына җиткән, ә кемгәдер ул күпердән чыгып җитәргә бер-ике адым гына калган. Шуңа күрә кеше анда тукталып, йортлар корып яшәргә түгел, ә күпердән узып кына китәргә тиеш.

Бу трактатта гайбәт сөйләү һәм истикамәт турында да фикерләр бар. Шәригатьтә гайбәт сөйләү алты очракта рөхсәт ителә, диелә һәм шул очраклар санап кителә.

Ә истикамәткә (исламда дөрес юнәлеш, дөрес юл алуга) килгәндә, Утыз Имәни фикеренчә, бу шәригать термины үз эченә күптөрле мәгънәләрне сыйдыра. Барыннан да элек ул мөселманның тормышта һәрвакыт Мөхәммәд пәйгамбәрдән үрнәк алып яшәвен аңлата. Һәм әдип ул гамәлләрнең иң әһәмиятлеләрен күрсәтә. *«Әгәр барысын да санап китсәң, барысы бергә ике меңнән дә артык вазифага җыела»*, – дип яза Утыз Имәни. Күренә ки, бу юл җиңел түгел һәм боларны бары бик тәкъва, тугрылыклы һәм гадел кеше генә үтә ала. Шулай итеп, бу трактатта Габдерәхим үзенең суфичыл карашларын шактый тулы чагылдыра.

Утыз Имәни Урта Азиядә суфичылык темасына «Бәет дәр зәмми суфиян мә-замана» (Замана суфиларын шелтәләү бәетләре) дигән 24 строфалы шигырь дә иҗат иткән. Бу әсәрдә ул шул замандагы Урта Азия суфиларының нәфескә бирелеп, байлык туплап, кәеф-сафа корып, шәригать кануннарын үтәмичә яшәүләрен тәнкыйтьли.

Урта Азиядән туган иленә кайткач та Утыз Имәни трактатлар язудан туктамый: 1798 – 1834 елларда ул «Рисаләи дибага» («Тире иләү турындагы рисалә»), «Рисаләи шәфәкыйа» («Шәфәкъ рисаләсе») һәм «Төхфәт әл-әхбаб фи тәҗвид кәлам әр-Рабб» («Раббе китабын дөрес уку турында дусларга бүләк») трактатларын иҗат итә.

«Рисаләи шәфәкыйа» хезмәте Идел буендагы мөселманнарны гасырлар буена борчып килгән һәм күп бәхәсләргә сәбәп булган мәсьәләгә – җәйге кыска көннәрдә ястү намазын – кояш баеп, аның кызыллыгы беткәч укыла торган намазны – укыргамы, юкмы, дигән мәсьәләгә багышланган. Утыз Имәни монда үз карашын тәкъдим итә. Ул болай яза: *«Безнең бу болгар якларында кайбер кешеләр җәйнең иң кыска көннәрендә төнге намазны укымыйлар, ялгышырбыз дип уйлыйлар; ә икенче бер төркем кешеләр ул намазны кичке шәфәкънең кызыллыгы беткәч укыйлар, галимнәрнең фәтваларына нигезләнәләр».* Һәр ике төркем бер-берсен бозыклыкта, әхлаксызлыкта гаепли. Икенче төркем беренче төркемне фарыз булган намазны калдыруда гаепли, ә беренче төркем икенчеләрнең гаебен намазны вакыты кермәсә дә укуда күрә. Һәр ике төркем үзләренең дөрес икәнлекләрен фәкыйһларның – шәригать законнарын яхшы белүчеләрнең – сүзләре белән дәлилли. Әмма алар икесе дә хакыйкатьтән ерак торалар. Һәм без аны болай аңлатабыз. Беренче буын мөҗтәһидләр (дин китаплары буенча яңа хөкемнәр чыгаручы галимнәр) кичке шәфәкъ мәсьәләсендә төрле фикердә булганнар. Әбү Хәнифә, мәсәлән, кичке шәфәкънең бетүе дип кызыллыктан соң килә торган яктылыкны атаган, ә аның шәкертләре шәфәкъ дип кызыллыкны гына алганнар. Шулай итеп, хәтта шул чор галимнәре арасында да бер фикер булмау сәбәпле, безгә шәригатьнең төп кагыйдәсенә – Коръән һәм Сөннәдәге фикерләргә таянырга туры килә. Кичке намазның вакыты, мәсәлән, ныклы, ышанычлы фикерләр белән исбатлана һәм һәртөрле фараз итүләр белән кире кагыла алмый. Ә менә төнге намаз (ястү намазы) вакыты ныклы, ышанычлы дәлилләр белән ныгытылмый, шуңа күрә фараз итүләргә урын кала... Шәригатьнең бер кагыйдәсендә «Нигез итеп әйберләрнең иң беренче халәтен алырга кирәк», дигелгән. Утыз Имәни җәйге кыска көннәрдә ястү намазын укымасаң да ярый, дигән фикер әйтә. Аның бу фикере тиз арада халык арасына тарала. Үлмәс Беляева бу турыда: «Утыз Имәнинең бу фикерләре үз вакытында татар дөньясын шаулаткан. Казанда «Дингә ревизия ясаучы кеше чыккан» дип гауга таралган. Шушы яңа фикерләре өчен, замандашлары аны төрмәгә дә яптыралар. Үзе үлгәч тә аның бу идеясе дәвам иткән», – дип яза [Беляева, б. 47].

«Рисаләи дибага» («Тире иләү рисаләсе») хезмәтендә Утыз Имәни *«Корбанны мөселман кешесе чалса гына дөрес була. Аның тиресен дә христиан яки мәҗүси кеше эшкәртергә тиеш түгел; мөселман кешесе эшкәрткәндә генә дөрес була»,* – дигән фикер үткәрә, тирене шәригатьчә эшкәртүнең тәртибен аңлата. «Төхфәт әл-әхбаб фи тәҗвид кәлам әр-Рабб» («Раббе китабын дөрес уку турында дусларга бүләк») трактатында Габдерәхим кайбер дин әһелләренең Коръәнне ашыгып һәм тәҗвид кагыйдәләрен искә алмыйча укуларын тәнкыйтьли.

Шулай итеп, Утыз Имәни үзенең барлык дини трактатларында да мөселманнарны бары шәригать кагыйдәләре буенча гына гамәл

кылырга чакыра, шуның белән туган халкын белемле, мәдәниятле, төзек, матур һәм иманлы җәмгыятьтә яшәтергә омтыла.

**Әдәбият**


*Адыгамов Р.К.* Габдрахим Утыз-Имяни. Казань: Фэн, 2005. 234 с.

*Беляева Ү.* Утыз Имәни поэзиясе: филол. фән. канд. ... дис. Казан, 1948. 197 б.

Габдрахим Утыз-Имяни ал-Булгари. Избранное / сост. и пер. с араб. Р. Адыгамова. Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. 320 с.

*Адыгамов Р.К.* Роль Габдрахима Утыз-Имяни в изучении социокультурных и религиозных традиций татарского общества конца XVIII – первой трети XIX вв.: дис. ... канд. ист. наук. Казань, 2007. 192 с.



*Мәкалә «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасының 3.19 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*



***Шәрипов Әнвәр Мәгъдәнур улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор*
*(Яр Чаллы шәһәре)*

УДК 821.512.145

***А.С. Шәрипова***

# XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕ ҺӘМ ТЕАТР СӘНГАТЕНДӘ МӘДӘНИ БАГЛАНЫШЛАР

Статья посвящена изучению межкультурного диалога в татарской сценической литературе и искусстве начала XX века на примере татаро-азербайджанских культурных взаимосвязей. В ходе исследования утверждается, что совместная творческая деятельность татарской и азербайджанской театральных трупп, постановка пьес азербайджанских драматургов на сцене татарских театров стали в определенной степени предпосылкой для дальнейшего развития татарской драматургии и театра.

**Ключевые слова:** культурные взаимосвязи; драматургия; «Товарищество казанско-татарских артистов», трагедия, водевиль.

The article is devoted to the study of intercultural dialogue in Tatar stage literature and art of the early XX century on the example of Tatar-Azerbaijani cultural interrelations. The study asserts that the joint creative activity of the Tatar and Azerbaijani theater troupes, the staging of plays by Azerbaijani playwrights on the stage of Tatar theaters have become to a certain extent a prerequisite for the further development of Tatar drama and theater.

**Keywords:** cultural interrelations; dramaturgy; «Partnership of Kazan-Tatar artists», tragedy, vaudeville.

Татар һәм азәрбайҗан халкын тарихи тамырлар, мәдәни, рухи, дини уртаклыклар һәм төрки тел үзара берләштереп тора. Күп гасырлар дәвамында әлеге ике тугандаш халык бер-берсе белән тыгыз аралашып яши. Бу җәһәттән XX йөз башы сәхнә әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендәге әдәби-мәдәни багланышлар аерым игътибарга лаек.

Татар-азәрбайҗан мәдәни багланышлары 1908 елда Г. Кариев җитәкчелегендәге «Сәйяр» труппасы, Х. Араблинский оештырган азәрбайҗан театр труппасы белән берләшеп, «Казан-Кавказ артистлары ширкәте» исеме астында Елизаветполь (хәзерге Ганҗә), Тимерханшур (хәзерге Махачкала), Әстерхан, Казан, Түбән Новгород шәһәрләрендә спектакльләр кую чорында аеруча ныгый. Репертуарга татар драматургларыннан Г. Камалның «Бәхетсез егет», «Беренче театр», Я. Вәлинең «Оят яки күз яше» пьесалары, азәрбайҗан авторларыннан Н. Наримановның «Надир шаһ», Н. Вәзировның «Мосыйбәте Фәхретдин» трагедияләре, Г. Ахвердовның «Милләт дуслары» комедиясе, С. Ганизадәнең «Дурсунгали һәм баллы пәрәмәч» водевиле кертелә, спектакльләрнең азәрбайҗан телендә дә, татар телендә дә уйналуы билгеле. Ике труппаның кушылып эшләвенең алшарты булып, И. Илялова билгеләп үткәнчә, азәрбайҗан һәм татар милли театрларының эчке охшашлыгы тора, чөнки яшь театрларның икесендә дә рус реалистик сәнгатенең тәэсире ачык сизелеп тора, шул

ук вакытта һәркайсының үз милли рухлары саклана [Илялова, с. 59]. Әлеге адымга этәргән сәбәпләр буларак түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк: 1907 ел, бигрәк тә аның икенче яртысы, ике труппа өчен дә матди планда шактый авыр уза. Нәтиҗәдә труппаларда спектакльләр күрсәтү өчен актерлар җитмәү, яңа әсәрләрне сәхнәләштерү өчен мөмкинлекләр булмау чишелә алмаслык проблемага әйләнә. Шуның өстенә, цензураның көчәюе аерым бер шәһәрләргә, сәхнәләргә юлны яба. Матди кыенлыклар иҗади үсешкә дә тискәре йогынты ясый.

Уртак эшчәнлек труппаларның иҗади диапозонын шактый киңәйтә, тәҗрибә туплау мөмкинлеген тудыра. Бу чорда татар театр сәнгате мәгърифәтчелек хәрәкәтенең көчле йогынтысы астында була һәм «халык театры» буларак яши, үз заманы татар җәмгыятенең актуаль проблемаларын сәхнәдән күрсәтү, тамашачы күңеленә сентименталь пафос ярдәмендә үтеп керү, үгет-нәсыйхәтчелек алга куела. Күпкә алданрак формалашкан азәрбайҗан театры бу этапны инде үткән була, ул «югары сәнгатькә», Европа театр әдәбиятына йөз тота. «Татар артистлары азәрбайҗан дусларына алар өчен аз таныш булган көнкүреш, психологик реализм театрын күрсәтәләр, ә үзләре күтәренке хисләр һәм героик пафос сәнгате белән якыннан танышалар, романтик уен алымын үзләштерәләр» [Салихова, с. 55].

Режиссер Х. Араблинскийның татар сәхнә сәнгате үсешенә уңай йогынты ясавы бәхәссез. Көчле тавышлы, Отелло кебек катлаулы характерлар тудырырга сәләтле актер булу өстенә, 1907 елдан ул труппасында режиссерлык вазифасын да үз өстенә ала. «Аның кул астында Г. Кариев бай тәҗрибә мәктәбе уза, артистларыбыз сәхнә осталыкларын күтәрә, милли театрыбызга романтик рух иңә. Шулай ук татар халкын Шекспир, Шиллер, Гете әсәрләре белән таныштыруда да аның өлеше аз булмый» [Ханнанов, б. 101]. Театр белгече М. Арсланов язганча, «Надир шаһ»ның күпсанлы артистлар җәлеп ителгән киң сугыш күренешләре репетицияләрендә катнашып, яшь режиссерлар Г. Кариев һәм В. Мортазин-Иманский массакүләм күренешләрне сәхнәгә кую тәҗрибәсен туплыйлар» [Арсланов, с. 19].

Азәрбайҗан галиме Н. Тагиева, 1920 елларга кадәр Россия һәм Европа театрлары белән чагыштырганда, азәрбайҗан милли театрының позицияләрен төшереп торган һәм аның үсешенә комачаулык тудырган сәбәпләрнең берсе буларак, «милли актриса проблемасы»н, ягъни хатын-кыз персонажларны ир-атлар яки чит ил актерлары башкаруны аерып күрсәтә [Тагиева, с. 101]. «Казан-Кавказ артистлары ширкәте»нең берләшеп эшләве нәтиҗәсендә, татар театры йогынтысында азәрбайҗан хатын-кызлары сәхнәгә чыга башлый. Моны исә азәрбайҗан театр тарихындагы бер баскыч буларак бәяләргә мөмкин. Шул рәвешле, «Казан-Кавказ артистлары ширкәте» труппасының гастрольләре нәтиҗәсендә ике тугандаш халык арасында сәхнә сәнгате юнәлешендәге хезмәттәшлеккә нигез салына, әлеге эшчәнлек һәр ике як өчен дә билгеле бер дәрәҗәдә тәҗрибә мәктәбе булып тора.

XX гасыр башында тәрҗемәчеләр дә, татар театр труппалары да азәрбайҗан драматурглары пьесаларына шактый еш мөрәҗәгать итәләр. Бу азәрбайҗан әдәбиятында әдәби төр буларак драматургиягә нигез салыну башка төрки халыклар белән чагыштырганда алданрак булу белән бәйле. Драматургия белгече А.Г. Әхмәдуллин, татар әдәбиятында яңа жанрлар барлыкка килүгә этәргеч ясаган факторларның берсе буларак, тәрҗемә әдәбиятның булуын атый; ул, башка халыкларның тәрҗемә әсәрләренә мөрәҗәгать итүнең татар сәхнә әдәбияты үсешендә «олы тәҗрибә мәктәбе» булуын ассызыклап, татар театры тарихында Н. Нариманов, Н. Вәзиров, Г. Ахвердов кебек азәрбайҗан драматургларының аерым пьесалары мөһим роль уйнавы турында яза [Ахмадуллин, с. 12]. Әдәбият галимнәре Н. Ханзафаров, Ә. Закирҗанов билгеләп үткәнчә, тәрҗемә әсәрләр драматурглар өчен билгеле бер үрнәк ролен уйный һәм чит илләр, чит халыклар тормышы белән таныштыра, бу исә башка халыклар мисалында җәмгыятьне үзгәртү юлларын эзләүгә дә этәрә. (...) Аларның татар сәхнәсендә куелуы театр һәм драматургия барышына уңай йогынты ясый, татар театры әһелләренең иҗади үсешенә булышлык итә [Ханзафаров, Закирҗанов, б. 354–355; 365–366].

Азәрбайҗан галиме Т. Мамед азәрбайҗан әдәбиятында Н. Вәзиров, Н. Нариманов, Г. Ахвердов иҗат иткән чорны драматик төрне жанрлар ягыннан да, милли поэтика элементлары белән дә баету этабы буларак бәяли, бу исә әлеге әдипләрнең, иҗат итү белән беррәттән, турыдан-туры театр тамашаларын оештыручылар да, аларда катнашучылар да, башка халыкларның театрлары тамашачылары да булып торуы белән аңлатыла [Мамед, с. 67]. Шунлыктан тәрҗемә итү, татар сәхнәсендә куелу өчен нәкъ менә әлеге авторларның әсәрләре сайлану табигый. Бу пьесалар театр труппаларының репертуарын киңәйтү белән беррәттән, сәхнә әдәбиятында яңа жанрларның формалашуына этәргеч була.

Татар театры һәм драматургиясе үсеше тарихында Нариман Наримановның *«Надир шаһ»* әсәре (1899) үзенчәлекле урын били. «Әлеге пьеса азәрбайҗан әдәбиятында тарихи трагедия жанрына караган беренче әсәр булса, татар театры сәхнәсендә тарихи теманы яктырткан тәүге спектакль буларак билгеле» [Шәрипова, б. 2]. Пьеса, алда билгеләп үтелгәнчә, татар тамашачысы каршында беренче тапкыр 1908 елда «Казан-Кавказ артистлары ширкәте» тарафыннан Х. Араблинский режиссерлыгында азәрбайҗан телендә уйнала. Соңрак Әстерхан шәһәренең «Аркадия» бакчасы театрында, Түбән Новгород шәһәренең «Фоли-Бержер» театрында сәхнәләштерелә. 1913 елда пьесаны Г. Адаков татар теленә тәрҗемә итә, һәм ул Әстерхан татар театрында З. Солтанов режиссерлыгында сәхнәгә куела. Трагедиянең Ф. Сәйфи-Казанлы тәрҗемәсендәге варианты 1917 елның 20 гыйнварында Казанда Зур театрда күрсәтелә. Әлеге пьесаның шулай ук Уфада «Нур» театрында, 1920 елларда Беренче дәүләт татар драма театрында уйналуы мәгълүм.

Татар театр труппалары арасында аеруча популярлык казанган пьеса дип азәрбайҗан драматургы Нәҗипбәк Вәзировның *«Мөсыйбәте Фәхретдин»* трагедиясен атарга мөмкин. Аны тәүге тапкыр 1907 елда Казанда Г. Нугайбәк тәрҗемәсендә һәвәскәр «Яшьләр» труппасы сәхнәләштерә, һәм 1908 елда тамашачы игътибарына «Казан-Кавказ артистлары ширкәте» тәкъдим итә. Трагедия 1913 елда «Сәйяр» труппасы репертуарына кертелә һәм 1917 елга кадәр ел саен диярлек уйналып килә. Һ. Мәхмүтов әлеге спектакльне «яңалыкка мәхәббәт, искелеккә нәфрәт уята торган популяр спектакльгә әверелә һәм шул ук вакытта трагедиячел материалны тирәнрәк үзләштерүдә алга таба бер адым булып тора» дип бәяли [Мәхмүтов, Илялова, Гыйззәт, б. 144]. Шулай ук спектакльнең Оренбург татар театры белән берләшкән «Нур» труппасы тарафыннан 1913 елда сәхнәгә куелуы, алдагы сезоннарда да репертуарда калуы билгеле.


قزان ١٩٠٨ يل.

ياكى تياترده
جمعه كون ٧نچى نويابرده بولاچق اسپكتاكلنك

پروغرامماسى

مصيبت فخرالدين

فاجعه ٦ پرده‌ده نجف بك وزير زاده اثرى.

اويناوچيلار:

| | |
|---|---|
| فخرالدين بك . . . . . . . . . . | عزرائيل. |
| شاه مار بك ، آنك برادى . . . . . . . | عزيزف. |
| ملكه خانم آلارنك آناسى . . . . . . . | آدامڤا. |
| حاجى مراد / خليل } آلارنك خدمتكارلرى . . . . . . | آلنايف. / عليف. |
| رستم بك، زور ملكدار . . . . . . . | آلمازف. |
| محمود بك، آنك اوغلى . . . . . . . | زوداڤ. |
| سعادت خانم، رستمنك قزى . . . . . . | سلطانڤا. |
| گل‌بهار خانم، محمودنك خاتونى، فخرالديننك سڭليسى . . | تارخانڤا. |
| حورى ، فخرالديننك هم گل‌بهارنك سوت آناسى . . | بهارڤا. |
| احمد / ولى } رستمنك خدمتكارلرى . . . . . | اكرمف. / توقتامشف. |
| جهانگير بك . . . . . . . . . . . | قريمسكى. |
| فرهاد / محرم } جهانگيرنك دوستلارى . . . . . . . | رحيمف. / نصيرف. |

اسپكتاكل كيچ ساعت ٧١/٢ ده باشلانادر.

پوبليكه‌دن ٢ نچى زڤانوق بولغاچده اورونلارينه اوطرولارينى اوتنه‌مز.

Нәҗипбәк Вәзировның «Мөсыйбәте Фәхретдин» әсәре буенча «Казан-Кавказ артистлары ширкәте» тарафыннан куелган спектакльнең программасы. Казан. 1908 ел, 7 ноябрь

Моннан тыш, 1908–1917 елларда татар тамашачысы игътибарына азәрбайҗан театр җәмгыятенә һәм язучылар оешмасына нигез салган күренекле әдип Габдрәхимбәк Ахвердовның дүрт пьесасы тәкъдим ителә. *«Милләт дуслары»* комедия-водевиле 1908 елның 13 августында Түбән Новгородта Фоли-Бержер бакчасында «Казан-Кавказ театр ширкәте» тарафыннан азәрбайҗан телендә уйнала. 1917 елда Казанда Зур театр сәхнәсендә татар телендә *«Ачлар»* комедиясе, Әстерханда Х. Араблинский катнашында *«Хөррият каһарманы»* трагедиясе куела. 1918 елның 15 гыйнварында Оренбург Шәһәр театрында, труппа мөдире В. Мортазин бенефисында *«Ага Мөхәммәд шаһ Каҗар»* трагедиясе күрсәтелә. Шул рәвешле, Урта гасырлар Шәрык традицияләре йогынтысында иҗат ителгән азәрбайҗан трагедияләре татар театры репертуарында лаеклы урын ала, җәмәгатьчелек тарафыннан җылы кабул ителә, татар драматургиясендә

трагедия жанры формалашуга җирлек булып тора, тарихи пьесалар язылуга юл ача.

Октябрь революциясе елларында театр труппалары тарафыннан сәхнәгә музыкаль әсәрләр чыгарыла башлый. 1917 елның мартында, беренчеләрдән булып, Оренбургтагы «Ширкәт» труппасы драматург Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» пьесасын сәхнәгә куя. Әсәр тукымасында халык уеннары, җырлар мөһим урын билэгән, автор идеясен җиткерүгә хезмәт иткән әлеге пьесага Г. Ибраһимовның биргән бәясе түбәндәгечә: «“Галиябану”ның бөтенләй яңа хасиятләреннән берсе – аның бездә беренче мәртәбә сәхнәгә музыканы, җырны, бер иттифакый зиннәт ясап кына түгел, бәлки төп матди итеп, асыл мөндәриҗә кылып кертүедер. Буны “Галиябану” башлап йибәрде» [Ибраһимов, б. 108].

Татар театр сәнгатенә әлеге яңалык керүдә шулай ук азәрбайҗан драматурглары пьесаларының да өлеше бар. Мисал өчен, Әстерхан театрында азәрбайҗан сәхнә әһелләре белән тыгыз аралашкан татар артистлары Сара һәм Җәләл Байкиннар тырышлыгы белән күренекле композитор, драматург, азәрбайҗан милли операсына нигез салучы Гозәир Хаҗибәковның *«Аршин мал алан», «Ул булмаса, бу булсын»,* аның туганы З. Хаҗибәковның *«Хатынлы – өйләнмәгән»* музыкаль комедияләре сәхнәләштерелә. 1917 елда Оренбург татар театры труппасы репертуарына да *«Ул булмаса, бу булсын»* пьесасы кертелә. Шул рәвешле, алга таба татар драматургиясендә музыкаль-поэтик элементларга мөрәҗәгать итү ешая, театр сәнгатендә музыкаль бизәлеш традицияләренә нигез салына.

Татар драматургиясенә водевиль жанры чагыштырмача соңрак үсеш ала, ул 1950 елларда гына сизелерлек активлашып китә. «XX гасыр башында формалашу чорын кичергән сәхнә әдәбиятында водевильгә хас элементларны (мәзәк хәлләр, тизләтелгән хәрәкәт, көтелмәгән чишелеш һ.б.) үз эченә алган пьесалар байтак булса да, алар комедия жанры кысаларында карала» [Әдәбият белеме, б. 40]. Шул ук вакытта татар тамашачысы әлеге жанр белән 1908 елда ук таныша, алдан әйтеп үтелгәнчә, «Казан-Кавказ театр ширкәте» артистлары тарафыннан азәрбайҗан драматургы, театр эшлеклесе Солтанмәҗит Ганизадәнең *«Дурсунгали һәм баллы пәрәмәч»* бер пәрдәлек водевиле Әстерханда, Г. Ахвердовның *«Милләт дуслары»* комедия-водевиле Түбән Новгородта куела.

Азәрбайҗан-татар мәдәни бәйләнешләренең аерым игътибарга лаек тагын бер юнәлеше – Әстерханда татар театры труппасын оештыруда азәрбайҗан сәнгать әһелләренең аерым өлеш кертүе. 1909–1910 елларда сөргенгә җибәрелгән Н. Нариманов, «Молла Насретдин» журналы хезмәткәре Р. Наджафов, Каспий диңгезчелеге эшләре буенча Әстерханга килгән Г. Ахвердовның Әстерхан шәһәренең мәдәни тормышында актив катнашулары билгеле. Алар татар җәмәгатьчелеге белән берлектә «Шураи-ислам» җәмгыяте каршында татар-кавказ театр труппасын оештырып җибәрәләр, һәм иҗади

коллектив азәрбайҗан һәм татар телләрендә спектакльләр кую белән шөгыльләнә башлый. Труппаның репертуарын билгеләү, яшьләрне сәнгатькә тарту, спектакльләрнең сәхнәгә куелыш сыйфатын, идеялелекне үстерү юнәлешендә әлеге шәхесләрнең роле шактый зур. Бу турыда Һ. Мәхмүтов болай дип яза: «Әстерхан татар театры 1909 елдан башлап аеруча җанлана. Бу, беренче чиратта, илдәге гомуми культура үзгәрешләре йогынтысында З. Солтанов, Җ. Байкин, Г. Адаков һ.б. яшьләрнең эшне активлаштыруына бәйле булса, икенчедән, бигрәк тә 1909–1914 елларда Әстерханда читтән килгән бик күп культура эшлеклеләре яшәве белән дә аңлатыла. Мәсәлән, шундыйлардан күренекле революционер, драматург һәм доктор Нариман Нариманов, шагыйрь һәм драматург Сәгыйть Рәмиев, язучы Фатих Сәйфи-Казанлы, укытучылардан Хөсни Кәрим, Касыйм Туйбахтин, Саттар Еникиев, артист Әхмәт Кулалаев Әстерхан театры белән тыгыз бәйләнештә булалар, театрны оештыру, дөрес юнәлештә алып баруда күп ярдәм күрсәтәләр. Аерым алганда, бу яктан Н. Наримановның эшчәнлеге зур игътибарга лаек» [Татар совет театры, б. 308]. Шул рәвешле, Әстерханда татар театр труппасы эшчәнлегенә азәрбайҗан сәнгать әһелләренең дә тәэсире була, бу исә ике тугандаш халыкның мәдәнияте тагын да якынаюга китерә.

Йомгак ясап, XX гасыр башы азәрбайҗан-татар әдәби-мәдәни багланышларының төп нәтиҗәсе буларак, башлангыч чорны кичергән татар һәм азәрбайҗан театр труппаларының берләшеп эшләве сәбәпле, һәр ике якның тәҗрибә туплавын, азәрбайҗан драматургларының пьесалары тәрҗемә ителеп, татар театрлары сәхнәсендә куелуның милли сәхнә сәнгате үсешенә һәм аерым драма жанрлары формалашуга билгеле бер дәрәҗәдә йогынты ясавын, Әстерхан татар театр труппасын оештыруда татар һәм азәрбайҗан сәнгать әһелләре хезмәттәшлегенең ике тугандаш халык мәдәниятенең тагын да якынаюына китерүен атап үтәргә мөмкин.

**Әдәбият**

*Арсланов М.Г.* Татарский театр в контексте тюркоязычных сценических культур // Театр тюркского мира: перспективы развития: материалы международной научно-практической конференции, посвященной Году театра в России. 23 декабря 2019 года / сост.: А.Р. Салихова, Н.Х. Нургаянова, Д.Р. Фардеева; научн. ред. Э.М. Галимова. Казань: ИЯЛИ, 2019. С. 11–23.

*Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: истоки и проблемы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 511 с.

*Ибраһимов Г.* «Галиябану» хакында бер-ике сүз // Әсәрләр: 15 томда. 8 т.: әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 431 б.

*Илялова И.И.* Театр имени Камала. Очерк истории: Исследование. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 328 с.

*Мамед Т.* Азербайджанская национальная драматургия. Тбилиси, 2001. 247 с.

*Мәхмүтов Һ., Илялова И., Гыйззәт Б.* Октябрьгә кадәрге татар театры: Очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 399 б.

*Салихова А.Р.* Особенности формирования и развития татарского сценического искусства. Казань: ИЯЛИ, 2016. 360 с.

*Тагиева Н.* История национального театра в Азербайджане: процессы формирования и развития // Актуальные проблемы гуманитарных и естественных наук. 2019. № 8. С. 99–103.

Татар совет театры: очерклар / [А. Әхмәдуллин, Х. Гобәйдуллин, Б. Гыйззәт, Д. Гыймранова, И. Илялова, Х. Кумысников, Һ. Мәхмүтов]. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 496 б.

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

*Ханзафаров Н.Г., Закирҗанов Ә.М.* Драматургия // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / төз. Р.Ф. Рахмани. 4 т.: XX йөз башы / фәнни мөх. Р.К. Ганиева. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 533 б.

*Ханнанов Р.Г.* Төрки драматургия контекстында татар сәхнә әдәбияты (XIX гасыр ахыры – XX йөз башы). Филол. фән. канд. гыйльми дәрәҗәсенә диссертация. Казан, 2009. 177 б.

*Шәрипова А.С.* Татар драматургиясендә трагедия жанры формалашуга азәрбайҗан сәхнә әдәбияты йогынтысы // Жанрово-стилевое развитие национальных литератур в XX–XXI вв.: материалы Международной научно-практической конференции (4 декабря 2020 г., г. Казань). Вып. 2 / сост.: А.Ф. Ганиева, Ф.Х. Миннуллина, Л.Р. Надыршина. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2020. С. 268–275.

*Мәкалә «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасының 3.19 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Шәрипова Алсу Сәмигулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының инновацион эшчәнлек һәм тышкы элемтәләр буенча урынбасары*

УДК 821.512.145

***А.А. Шәмсутова***

# 1980–2000 ЕЛЛАР ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ МИЛЛИ КАҺАРМАН ТИПЛАРЫ

В этой статье основное внимание уделяется национальным героям, которые были отражены в пьесах татарских драматургов в 1980-е и 2000-е годы. Автор анализирует пьесы Т. Миннуллина, Р. Хамида, И. Юзеева, и др., классифицирует национальные герои, созданные ими в этот период; изучает национальные образы. При анализе произведений учитываются и другие элементы произведения, которые помогли создать неповторимые образы и раскрыть идею, которую несет татарская драматургия через этих героев. Автором статьи было выявлено, что драматурги обращают особое внимание на потерю национальной самоидентификации героев, отказ от родного языка, отказ от нации и народа. Все эти качества можно увидеть в разных образах, созданных в пьесах 1980–2000 г. В противовес им ставится другой тип идеологических героев, которые олицетворяют хранителя нации, народа. Обращение драматургов к подобным героям автор объясняет требованием времени. Автор отслеживает, как татарская драма 1980-х и 2000-х годов фокусируется на реальных аспектах жизни, идет борьба за сохранение нации, родного языка и самоидентификацию.

**Ключевые слова**: татарская драматургия 1980–2000 годов, национальный герой, история татарского народа, национальная самоидентификация.

This article focuses on the national heroes who were reflected in the plays of the 1980s and 2000s. The author analyzes the plays of Tatar playwrights T. Minnullin, R. Khamid, I. Yuzeev, etc., classifies the national heroes created by them during this period, studies national images and draws on new qualitative data collected in the context of the analysis of these plays. At the same time other elements of the work that helped to create unique images and reveal the idea that Tatar drama carries through these heroes are taken into account. The author of the article revealed that playwrights pay special attention to the loss of the national identity of the heroes, the rejection of the native language, the rejection of the nation and the people. All these qualities can be seen in different images created in the plays of 1980–2000. In a counterbalance to them a different type of ideological heroes is put. These heroes of drama represent the guardian of the nation and the people. The study of these characters is necessary in order to understand how the Tatar drama of the 1980s and 2000s focuses on real aspects of life. These beliefs encourage how the struggle for the preservation of the nation, the native language and self-identification is going.

**Keywords**: Tatar drama of 1980–2000, national hero, history of the Tatar people, national self-identification.

Россиядә XX гасыр ахырында булган үзгәрешләр сәнгать парадигмаларын да үзгәртте. Иҗтимагый формацияләр алышынганда татар драматургиясе дә, сәнгатьнең башка төрләре белән рәттән, үзгәреш кичерде. Бу табигый хәл, чөнки ул җәмгыятьнең торышына сизгерлеген сакларга омтылып, аны көзгедәге кебек чагылдырыр-

га тырыша [Шәмсутова, б. 84]. Татар драматургиясе тематик яктан да, проблемалар ягыннан да үсә, байый. Драматургиягә әледән-әле яңа исемнәр, яңа әсәрләр өстәлә бара. Бу хакта драматургия белгече, галим Азат Әхмәдуллин *«Илдә барган кискен вакыйгалар эчендә драматургия жанры да үз урынын табарга, сәхнәне заманча әсәрләр белән тәэмин итәргә омтыла»,* дип язган иде [Әхмәдуллин, 2012, б. 8]. Тема яңалыгы гына әдәбиятны үстерә алмый. Монда сәнгатьнең башкарган вазифалары (эстетик, тәрбияви, идеологик) әһәмиятле урын били. Бу вазифалар беренче чиратта әсәрләрдә сурәтләнгән, төп идеяне ачуга хезмәт итүче геройлар белән турыдан-туры бәйле.

1980 – 2000 еллар татар драматургиясендә чагылыш тапкан геройларны берничә типка аерып карап була [Шәмсутова, 2002, б. 14 – 16]. Беренчесе – *«рухи имгәк»* буларак бәяләнүче геройлар. Мондыйлар драматургиядә XX гасырның 80 елларында ук күренә башлады. Милләт фаҗигасын ачу ягыннан классик әдип Туфан Миңнуллин тудырган геройлар гыйбрәтле. Аның милләт киләчәген хатын-кызның роле, ананың гаиләдәге урыны белән бәйләп биргән идеяләре Гаяз Исхакыйның *«милләт анасы»* концепциясе белән аваздаш, шуның бүгенгедәге үстерелеше булып яңгырый [Шәмсутова, 2005, б. 87]. Мисалга Т. Миңнуллинның *«Әниләр һәм бәбиләр»* әсәрен китерергә мөмкин [Миңнуллин, 2002, б. 358–400]. Андагы хатын-кыз каһарманнарның үзләрен берничә типка аерып карарга булыр иде. Милләт анасы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән, бүгенге хатыннарга, кызларга да үрнәк булып торырлык Гөлфинә образы автор җиткерергә теләгән идеяләрнең бер өлешен яктыртса, Гөлфинәнең капма-каршысы булган, бүгенге тормыш шартларында тәрбияләнгән, «рухи имгәк» мисалы булган Дилемма образына автор шулай ук милләт турындагы, хатын-кыз бурычы турындагы мөһим фикерләрне туплаган.

Т. Миңнуллинның милләт язмышын реаль планда чагылдырган «Илгизәр плюс Вера» драмасындагы геройлар чынбарлыкны тулы рәвешендә күрсәтү ягыннан әһәмиятле [Миңнуллин, 2002, б. 7 – 52]. Әсәрнең төп сюжетын тәшкил иткән ике милләт арасында бер-берсен яратучылар элек тә булган. Пьеса геройлар тарган менә шушы вакыйганы милли фаҗига дәрәҗәсендә, фәлсәфи характерда ача. Уйланырлык проблема монда тирәндәрәк – катнаш никахтан туган балада ничек итеп татар рухын булдырырга, аңа татар телен ничек сеңдерергә? Автор әлеге сорауны ачыклау өчен символик «өянке образы»н куллана. Ул ике гаилә – ике милләт арасында чик булып тора, шул җимерелсә, алар арасында ихтирам һәм тигезлек бетә.

Драматургиядә милли фаҗиганы ачкан матур каһарманнарга мисалга Данил Салиховның «Чукрак» пьесасын китерә алабыз [Салихов, 1998, б. 111 – 176]. Әсәрдә бер гаиләнең өч буыны мисалында гына да (Мотавал хәзрәт – Нуриәхмәт – Мөбарәк) татар халкының деградацияләнүе, ягъни бетүе, мескенләнеп, нигезе җимерелүе, иң аяныч хәлгә, кабахәтлеккә кереп китүе күренә.

Пьесаның үзәгендә – татар халкының зыялы, мул тормышлы Мотавал хәзрәт гаиләсенең рухи һәм нәсел фаҗигасы. Әлеге гаилә, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге юкка гына хронологик тәртиптә бирелми. Аның язмышы татар халкы язмышын күрсәтә. Автор сәнгатьчә раслаганча, татар халкы тарихында 1917 елдан соң булган вакыйгалар шатлыклы түгел, алар гадәти драматизм белән генә дә сугарылмаган, бу – котылгысыз фаҗига.

Шулай булгач, Мотавал нәселенә туры килгән вакыйгалар да – фаҗига. Шул ук вакытта бу шәхси драма гына түгел, дидек, чөнки ул буыннар (Мотавал һәм Нуриәхмәт) яки туганнар (Галиәхмәт һәм Нуриәхмәт) арасында барган, шәхси җирлектә туган каршылыкка гына кайтып калмый (әйтик, «Өрәк» әсәрендәге Ильяс һәм аның атасы Мәҗит арасындагы кебек).

Мотавал нәселендәге шәхси каршылыкларны шул чор атмосферасы, шул чор вакыйгалары китереп чыгара; әсәрдәге конфликт иҗтимагый-сәяси характерда. 1917 елгы вакыйгалар тыныч кына, акрын гына аякка басып килгән татар халкын, бал кортының оясын туздырган кебек, туздырып, актив, хөр фикер-гамәллеләрне юк итеп, калганнарын язмыш иркенә ташлады. Шуңа да әсәрдәге геройларның (Нуриәхмәт, Мөбарәк, Гөлйөзем, Галимҗанның) язмышы һәм татар авылының котылгысыз рәвештә упкынга таба баруы аларның нәкъ менә большевикларның ялгыш, ялган, мәкерле идеясе тозагына эләгүе белән аңлатыла.

Автор бүгенге рухи манкортлыкның башын 1917 елгы революция, аннан соңгы «кызыл террор» еллары белән бәйләп бирә. Авызыннан аракысы, сүгенү сүзе китмәгән, атасына, анасына нәфрәт белән, имгәк дип караган «Мөбарәк»ләрнең тамыры кайдан килә? Әсәрнең потенциаль эчтәлегеннән чыгып анализлаганда, авторның бу сорауга җавабы ачык: әлеге тискәре күренеш мәчетләрне җимереп, гөнаһсыз яшь, саф кызларны көчләп йөргән, акыллы, эшчән кешеләрне «кулак», «халык дошманы» дип атып үтереп барган яки Себергә сөргән, үзләре исә укый-яза белмәгән, эшләргә яратмаган, әмма боерык биреп, кешене мыскыллаудан тәм тапкан Арыслан, Батырҗан, Галимҗаннардан башлана. Бу соңгыларының кылган гамәлләреннән ил елый, матур яшәргә хакы, көче, мөмкинлеге булган хатыннар, ирләр елый, алардан сәламәт, бәхетле булып туган, әмма бәхетсез яшәргә мәҗбүр ителгән, язмышлары каргышка төренгән «Мөбарәк» кебек «балалар» елый, дип күрсәтә драматург.

Әсәрдә татар милләтен фаҗига юлына алып кереп китәрдәй вакыйгалар күпләп тәкъдим ителә һәм куркыныч дәрәҗәгә җиткерелеп күрсәтелә. «Ил карты» дип йөртелгән мулланы Себергә сөрү, ире дип атаган кешесе шушы авылда, большевиклар арасында була торып, көчләүгә дучар ителгән, гомер буе шул көчләүләргә түзеп килгән Гөлйөзем вакыйгасы, мәчетләрне җимерү, үзләрен большевик дип күрсәтеп, масаеп, халыкны куркытып торткан Арысланның гамәлләре, асыл нәселдән булган Мөбарәкнең «Арыслан»нар тәрбиясендә үсеп, ата-ана-

га коточкыч мөнәсәбәте, яшь чагында яшь кызларны көчләп, халыкны зар елатып йөргән, картайгач та аракысын оныта алмаган Арысланның авылда иң белемле мулла булып йөрүе, шәхси теләкләре өчен бернигә карамый Батырҗанның ялган яла ягып, дусларын «сатуы», большевикларга күңел биреп, ышанып хезмәт иткән Галимҗанның үз-үзен һәлак итүе һәм, ниһаять, туган ягымда, туган җиремдә калам, тигезлек төзим дип атасын, абыйсын большевистик принципларга алыштырган, халыкны тук, тигез, бәхетле итим дип йөргән, әмма бик күп гафу итмәслек хаталар ясаган Нуриәхмәтнең асылынып үлүе...

Пьесада революция, колхозлаштыру еллары гына түгел, бүгенге көн вакыйгалары да сәнгатьчә, образлы итеп, реаль җирлектән ераклаштырылмыйча сурәтләнгән. Драматург күрсәткәнчә, нурлы, тыныч кына яшәп яткан татар авылын һәр өйдә бер «рухи имгәк» үстергән, аракыны имезлек кебек тотып йөргән, асылын җуйган татар авылы алыштыра; мәдрәсә бетергән, Коръәнне яттан белгән Мотавал кебек муллаларны азан алдыннан кунак булып, стаканлап аракы эчкән Арыслан кебек дин гыйлеменең кирәклеген дә тоймаган, чалма-чапан кию җиткән, дип санаган муллалар алыштыра. Автор пьесада менә шундый параллель сюжет сызыклары тудыра һәм алар аша укучы-тамашачыны уйланырга чакыра.

Шул рәвешле, бу әсәрнең конфликтын бер нәсел эчендә барган (Мотавал – Нуриәхмәт, Нуриәхмәт – Галиәхмәт, Нуриәхмәт – Мөбарәк) яисә ана һәм бала (Гөлйөзем – Мөбарәк), власть һәм гади кеше (Арыслан – Гөлйөзем, Арыслан – Галимҗан) арасында барган катлаулы, кайвакыт һәлакәткә китергән каршылыклы һәм шул чор кешеләре җилкәсенә төшкән тарихи катаклизмнар (революция, колхозлашу, мәчетләрне җимерү, репрессияләү һ.б.) формалаштыра. Әлеге конфликт әсәрнең магистраль линиясенә – сюжетына, аның үзенчәлекле характерына тәэсир итә, аның сюжеты төрле гыйбрәтле һәм аянычлы эпизодлардан тора, бу эпизодлар бөтен бер совет җәмгыятенең халәтен, юлын-мәсләген һәм сәясәтен ачык чагылдыра. Пьесадагы эпизодлар хронологик тәртиптә бирелә һәм алар эчендә мөстәкыйль конфликтлар тудырылган, бу кечкенә каршылыклар барысы бергә исә «җәмгыять һәм шәхес» дигән гомуми конфликтка буйсына, дип әйтергә мөмкин.

Үзенчәлекле милли герой сериясен бирүдә кызыклы ачышлар, яңалыклар алып килгән драматурларгның көчлесе – Ризван Хәмид. «Аның иҗатында манкортлыгы белән татар милләтенең киләчәгенә нокта куярдай Гәрәй-Гаррилар, туганнары-нәселе рухына үз принциплары биеклегеннән карый торган һәм тормышта үзе төзегән канун буенча яшәгән Илсурлар, милләтнең хәтере вазифасын башкарган Нәүхәбәрләр аерылып тора». [Шәмсутова, 2005, б. 87].

Р. Хәмид тудырган геройлар үзләренең кабатланмас характеры белән дә, сәнгатьчәлелек ягыннан да көчле. Геройларны ачу, алар аша татар укучысына әйтергә теләгән фикерләре ягыннан Р. Хәмиднең «Актамырлар иле» трагедия-реквиемы кызыклы [Хәмид, 1991, б. 128–151]. Әсәрнең «реквием» дип аталуы сәерсенү тудыра.

«Реквием» – үлгәннәргә багышлап иҗат ителә торган әсәр. Ни өчен драматург үз әсәрен «реквием» дип атый? Чөнки моның белән автор әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларның трагедия генә түгел, ә инкыйразга таба баручы бер милләт хакында «реквием» итеп сөйләнерлек фаҗига булуын ассызыклый, кисәтә [Shamsutova, 2021].

«Актамырлар иле» пьесасында бер татар нәселе мисалында татар халкының җыелма образы тудырыла. Хода һәм Тәңре дигән мифик образлар яктылыгында Мөштәри карт аша татар халкының кайчан, ничек һәлакәткә дучар булуы бәян ителә. Мөштәри карт (ил карты) буынын схематик рәвештә тасвирлап (Мөштәри – Мәрәс – Фаягөл – Гәрәй – Гарри), шуны ачык күрергә мөмкин: өлкән буыннан ерагайган саен татар токымы бетә, деградацияләнә, әсәрдәгечә әйтсәк, киләчәк буынга тапшырыласы рухи мирас тапшырылмый кала, аны тапшыруны һәм кабул итеп алуны кирәк дип санаучы да юк. Рухи мирасның җимерелүе Мәрәстән башлана, ул ата-анасы баглаган өметне акламый. Автор монда Мәрәс, Гарри кебекләрне тәрбияләүдә бары ата һәм ана җаваплы дигән фикерне кат-кат ассызыклый. «Гарри»ларның тууына да Фаягөл кебек хатын-кызлар сәбәпче. Фаҗиганы кульминациягә илтүче вакыйга – Бәкер кебек кеше талап аракы эчеп йөрүче, Фаягөл кебек акча өчен җанын бирергә әзер, үз баласын тугач та чүплеккә аткан бәндәләрдән туган Гәрәй-Гарриның үз нәселенең бөтен өмете булган саф татар кызы Фәридәне ата-бабалары кабере өстендә көчләү эпизоды. Бу вакыйганы тасвирлау аша Р. Хәмид үз анасын һәм туган телен күралмаган «Гарри» кебек совет чоры татар яшьләре өчен кызларның намус сафлыгы, бабаларының кабер ташы кебек «мәдәни кодлар»ның кыйммәте бетүен ассызыклый. Гарриның (аны бер дә Гәрәй дип атыйсы килми) асылын ачу өчен кулланылган бу беренче эпизод булса, алга таба әсәрдә тагын бер шундый эпизод тудырыла. «Кызларны ярату»ны талау-көчләү аша белдерә торган Гарри үз баласын дуңгызны имәргә куя. Бу – әсәрнең кульминациясе. Татар рухын мондый мәсхәрәләүгә дучар итмәс өчен, гүя, драматург баланы дуңгыз астында калдырып үтертә. Шуның белән дуңгыз сөте эчеп үскән «үле җаннар» үрчеткәнче, андый баланың юк булуы хәерле, дигән фикер үткәрә. Бу исә – әсәрнең җаннарны тетрәткеч өченче алымы. Димәк, татар рухы сынган гына түгел, ул әнә шул сынган рухлы «тере мәет», «үле җаннар» исемен йөртүчеләрдән тора. Автор бу хакта бик матур итеп болай ди: *«Ата-бабаларының телен һәм денен оныкларына тапшыра белмәгән бәндәләр синең заманда да җитәрлек иде. Хакыйкать аларның барлыгында түгел. Андыйлар күзгә күренеп күбәя – менә кайда хакыйкать»* [Хәмид, 1991, б. 138]). Бу әле әсәр язылган 1989–1990 елларда әйтелгән сүзләр. Мондыйлар кимемәде Татар илендә. Киресенчә, Көнбатышның тискәре йогынтысы нәтиҗәсендә һәм «үзгәртеп кору» дип исемләнгән, социалистик стройдан капиталистик формациягә күчү чорында балаларына ашарга алу өчен акча эшләү белән мәшгуль булып, аларга юньле тәрбия бирә алмаган, һәм дә милли тәрбиядән шактый ук ерак киткән, аны оныткан аналар тәрбиясендә мондый «гаррилар»

елдан-ел үрчи генә бара. Автор бик матур итеп: *«Ә бит кешене юлга чыгарып җибәргәндә юнәлешен күрсәтәләр»,* – ди. Бу түгелме безнең заман герое?! Татар милләтенең киләчәге менә шундый яшьләр кулына калачакмы?! Р. Хәмид пьесада менә шулар хакында фикер йөртергә чакыра. Киләчәктә мондый «үле җаннар» – «тере мәет»ләр «атасының баш сөяген тустаган ясап аракы эчмәсме?», – дигән сорауны ачык калдыра Р. Хәмид.

Татар милләтенең милли үзбилгеләнешен югалтуын күрсәтү ягыннан Илдар Юзеевның «Ак калфагым төшердем кулдан» [Юзеев, 2002, б. 42–80] драмасын әйтеп үтми мөмкин түгел. Әсәр моңа кадәр әле без татар драматургиясендә күрергә күнекмәгән геройларны кертүе белән кызыклы булса, алар аша милләтнең асылын ачу хакында җиткерелгән фикерләре ягыннан да кыйммәтле. И. Юзеев пьесаларындагы үзенчәлекле милли геройлар хакында башка галимнәрнең язмалары да игътибарга лаек [Миннуллина, 2019, с. 81–88].

Без биредә татар халкының ике ярга аерылуы, ягъни чит илләргә чыгып китүе нәрсә белән бәйле? дигән сорау аша драматург иҗатындагы идея-эстетик концепциягә генә тукталып узабыз. Автор Тайфур, Жак, Ратмир Зәкиевский образлары аша өлешчә әнә шул сорауга да җавап бирә. Талантлы, хөр фикерле, мөстәкыйль карашлы кешеләрнең ирекле Совет илендә кала алмавы, читтә исә туган туфрагын, газиз ана телен сагынып, үзенә урын таба алмыйча үз-үзен һәлак итүләре, илдә калганнарының милләтчелектә гаепләнүдән куркып, хәтта үз туганы белән дә милли мәсьәлә турында сөйләшә алмавы – болар барысы да татар халкының таркалу процессында төп баскычларның берничәсе генә. Әсәрнең идея ягын автор керткән матур образ – *ак калфак образы* (Жак кулында сакланган калфак та, ак калфак хакындагы җыр да) бер фокуска төйнәп тора. Әсәрдәге геройлардан без Жакны (Габделхак Ишмуллинны), Сафия Нурханны рухи хәзинә сакчылары кебек кабул итәбез, Шәмсияләр, Акчуриннар исә «югалган җаннар» («үле җаннар») сыйфатланмышы белән тамгалана алалар. И. Юзеев драматургиясе беркемне дә кабатламый торган, тәэсирле көчле милли идеягә ия драматургия иде. Аның пьесаларын бөтен тулылыгында ачып бетерү өчен, Л. Ваһапова үз хезмәтендә әсәрләрнең поэтикасы ягыннан якын килә [Вагапова, 2011, с. 9–11].

Икенче тип геройлар – *«гөнаһлы бәндәләр»*. Мондый типлар 1980–2000 еллар татар әдәбиятында аз түгел. Т. Миңнуллинның бөтен хәятнең асылы, рухи иминлек, сафлык хатын-кызда икәнлеген раслаган һәм шушы фикерне үзенчәлекле яктырткан «Сөяркә» пьесасы бу типларның матур үрнәген бирә. Бу әсәр сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгән герое ягыннан да, фәлсәфәсе ягыннан да кызыклы һәм гыйбрәтле [Миңнуллин, 1998, б. 165–247]. Т. Миңнуллин әлеге әсәрендә дә тормышта күбебез «күрергә теләмәгән» кешене – гаиләле ирнең «сөяркәсе» дип аталган типны әдәби образ дәрәҗәсенә җиткереп, аның гамәленең дөреслеген иҗтимагый фикер, дин кануннары һәм геройларның карашлары аша ачыклый. Әсәргә тискәре ярлыгы

ябыштырылган затны кертеп, аның аша драматург тормыш турындагы экзистенциаль характердагы карашларны да ача. Т. Миңнуллин күрсәткәнчә, Әнисә һәм Хәбир арасындагы мөнәсәбәтләрнең мәгънәсе тирәнрәк. Әнисә Хәбирне байлыгы өчен түгел, өйләнгән булса да, аны кеше булганы өчен яраткан. Драматург язмыш шаяртуы аркасында һәм дин кануннары яктылыгында үзен зиначы дип атаган Әнисәнең «сөяркә»ме-түгелме икәнен исбатларга алына, фәлсәфи яктылыктан торып бәяләмә бирергә тели. Әмма Т. Миңнуллинның геройлары эчке яктан сер тулы килеш калалар: пьесаны укыгач яки әсәрне карагач та, уйланырга урын калдыра автор. Әлеге әсәрдә дә автор «гөнаһ» сүзенә бәйле рәвештә берничә төрле фикерне бәрелештерә. Мәсәлән, Хәбир үзен гөнаһсыз дип саный, чөнки ул ЯРАТА. «*Сине яратканым өчен берәүнең дә мине җавапка тартырга хакы юк», – ди ул. – «Хәтта синең алланың да»* [Миңнуллин, 1998, б. 230]. Хаклык бармы аның сүзендә? Ярату – гөнаһ түгел. Әмма әсәрдәге Хәзрәт мондый мәхәббәтнең дин тарафыннан тыелуын дәлилли. Әнисә дә үзен кеше өлешенә кергән кеше дип, андый яратучы гөнаһ иясе дип саный. Әмма Хәбирнең сүзләренә көч өстәгәндәй, яшен яшәгән, ашын ашаган Хәбирә карчыкның сүзләрен дә китереп кертә автор. *«Яратмаган кеше белән яшәү гөнаһ»*, – ди карчык. Әлеге әсәрдәге фәлсәфи бәхәсне динле кеше үзенчә, динсезе үзенчә кабул итәргә мөмкин. Моны истә тотып, автор уйланырлык тагын бер сорау куя: *«Тормыш, язмыш. Нигә берәүләргә андый язмыш бирелгән, икенчесенә мондый?»*. Шушы сораугa Хәбир аша үзе үк җавап та бирә:*«Үз язмышын кеше үзе ясый... Ялгышы да үземнеке, барысы да үземнеке»*. Т. Миңнуллин фәлсәфи бу аспектны көчле психологизм аша бирә, Әнисә генә түгел, Хәбир дә «күңел диалектикасы» яктылыгында ачыла.

Драматургиядә тудырылган образлары ягыннан Рөстәм Мингалим иҗаты да кызыклы. Аның «Өченче бүлмәдә эт яши», «Тау астында илле бүре» кебек әсәрләре бүгенге тормышта гына туа ала торган катлаулы геройларны туплаган. Биредә аның «Өченче бүлмәдә эт яши» дигән әсәренә тукталасы килә. Әлеге әсәрдәге геройлар мисалында ни рәвешле кешеләрнең – бәхеткә омтылган адәм балаларының – үз бәхетләрен үзләре җимерүе тасвирлана. Автор раславынча, кешенең хәяте матур булуы, аның белән яшәве рәхәтлек бирү бары тик шул кешенең үзеннән тора. Рәйхан һәм Гөлия кебекләрне без «гөнаһлы герой»лар тибына кертә алабыз. Аларның *гөнаһы* – якын кешесенең җан тынычлыгын бозуда, урлауда, аның өметен сүндерүдә, ышанычын алдауда.

Гөнаһлы бәндәләр тибын драматургия шактый күп тудырды. Мәсәлән, Зөлфәт Хәкимнең «Шайтан куентыгы» [Хәким, 2000, б. 307–346] әсәре. Драматург бу пьесада бүгенге тормышта кешеләрнең бер-берсе алдында кичерә алмаслык гаепле булуын, бер-берсенең тормышын, өметен, язмышын җимерүен сәнгатьчә тасвирлый. Акча, матди байлыкка корылган, көнчелек, явызлык чәчрәп тор-

ган, рухи нигезе җуелган бүгенге тормышка әсәрдә матур хыяллар, бәхетле көлүләр, онытылмаслык вәгъдәләр биргән балачак дөньясы каршы куела [Саттарова, 2003, б. 102]. Менә шушы ике параллель яктылыгында Рәзим һәм Фәнзиләнең фаҗигасы милләтнең башка улкызлары фаҗигасы дәрәҗәсенә күтәрелә. Зурая барган саен, күңелдә балачак яктылыгы кимеп, өшеткеч һәм котырткыч салкын керүне автор «шайтан алу» дигән гыйбарә аша ача. Бу – авторның ачышы. Психологик һәм фәлсәфи яктан тирәнәйтәсе урыннары булса да, әлеге әсәр тамашачыны һәм укучыны кылган гамәленең ахырын уйлап эшләргә кирәклек хакында, бер-береңә мәрхәмәтле, ягымлы, изге теләктә булу зарурлыгы турында уйланырга этәрә.

Өченче тип геройлар – *маргиналь геройлар.* Аларны үзе яшәгән милли мохиттән читләшкән, аның кануннарын кабул итмәгән, үзенчә яшәргә дигән фикергә килгән геройлар дип атарга булыр иде. XX гасыр ахыры татар драматургиясендә маргиналь геройның формалашуы хакында А. Шәмсутова, А. Саттарова, Ф. Миңнуллина үз фәнни тикшеренүләрендә язып чыкканнар иде [Шәмсутова, 2005, б. 84–88; Саттарова, 2003, с. 110–115; Миннуллина, 2019, с. 41–44]. Бу тип геройның матур мисалын без Р. Хәмиднең герой концепциясен үстерүгә өлеш керткән һәм шулай ук кабатланмас характеры белән аерылып торган тагын бер каһарманында – «Каен җиле» драмасындагы Илсур образында күрә алабыз [Хәмид, 1987, б. 159]. Автор бу пьесада әһәмиятле бер моментка туктала. Кеше турында туган илендә нинди фикер, хатирә яши дә һәм аны белгән, аның белән эшләгән кешеләр нәрсә сөйли? Ике карашны, фикерне чагыштырып, драматург Илсур шәхесенең асылын ачыклый, шуның белән кешенең үзеннән соң калган эзе хакында уйлануларга этәрә. Пьесада автор экзистенциаль бу проблема хакында шактый катлаулы фәлсәфә кора. Илсурның яшәү принцибы шуннан гыйбарәт: үзенә якын булган кешеләргә бурычлы булмас өчен, алардан вакытында аерыла белергә кирәк, аларны онытырга, үзеңне дә оныттырырга кирәк. Бары шулай итеп кенә иҗтимагый сферада тамыр җәйгән «туган-тумачалык» режимына нокта куеп була, дип саный ул. Аның белән бергә эшләгән, аралашкан кешеләрнең барысының да Илсур позициясендә торулары ачыклана. Әмма аларның фәлсәфәсендәге беркадәр хаклылыкка күз йоммаган хәлдә, Илсур ишеләр белән килешеп булмый, дип саный автор. Моны ачыклау өчен, ул фәлсәфи сораулар куя: баланы якты дөньяга китергән ана һәм атага бурычны акча белән түләп бетереп буламы икән?! Әсәрдә яктыртылганча, баланың ата-анага булган бурычы – ул рухи вазифа, ягъни нәселенең якты исемен, тарихын киләчәк буыннарга тапландырмыйча илтеп җиткерү, милли үзбилгеләнешне саклап калу, ата-ана теленә тугры калып, шундый ук тугры, милли хисле балалар тәрбияләү.

Илсур кебекләр бары үзләре хакында гына уйлап, тормыш авырлыкларыннан, сынауларынннан җиңел генә котылырга телиләр. Алар, пьесадагы Юрзин әйткәнчә, «яшәү принципларын сынаган һәм башкача яшәү кирәк, дигән фикергә килгән». Аларның яшәү принцибы

гади: кызык булмаса, башлаган эшне ташларга, фатир да, гаилә дә кирәк түгел. Гадел һәм Гортензия, Гадел һәм Юрзин арасында барган кызыклы фәлсәфи бәхәсләрдән һәр укучы үзенә күрә бер нәтиҗә ясый ала. Әмма Илсур кебек үз мәнфәгате белән генә яшәүчеләр дә елдан-ел күбәя бара. Аларның санын әнә шул үз милли билгеләнешен, яшәү бурычын оныту арттыра, дип ассызыклана драмада.

Р. Хәмид әлеге әсәрендә кешелекнең Илсурга мөнәсәбәтен Ана образы аша ача. Анасы, Илсур утырткан каен төбендә улын көтә-көтә моңаеп, эчтән генә сыза-сыза да, бер көнне каенны кисеп аудара. Үзенә җан биргән, төн йокыларын калдырып үстергән иң изге, кадерле кешесен егерме ел буена бер генә тапкыр да кайтып күрмәгән улыннан анасы үләр алдыннан ваз кичә, аның хакындагы хатирәне дә җимерә. Әсәрдә Илсур образы каршылыклар аша бөтен тулылыгы белән ачылган.

Бүгенге драматургиядәге дүртенче тип геройлар – *«милләт сакчылары»*. Алар – татарның якты рухын мирас итеп саклый килгән, аны киләчәк буыннарга тапшырырга тиешле, әмма халкы өчен кирәксезгә әйләнгән Нәүхәбәрләр (Р. Хәмид. «Олы юлның тузаны», 1989; М. Гыйләҗев. «Бичура», 2002, һ.б.). Драматург Р. Хәмид тудырган олы җанлы, бөтен рухи байлыкны саклап килгән, үзе үк хәтер сандыгына әверелгән Нәүхәбәр карчык образы – «Олы юлның тузаны» монодрамасының бердәнбер каһарманы. Әсәр символикалылык ягыннан да, жанры җәһәтеннән дә үзенчәлекле: ул бер генә каһарманнан тора. Драматургиядәге «өч берлеккә» Р. Хәмид тагын дүртенче берлекне дә – герой берлеген дә керткән. Әмма шушы «берлекләр» аша драматург иң әһәмиятле проблемаларны ача. Беренчедән, Нәүхәбәр карчык үзе – Мирас, үткәннән бүгенгегә җибәрелгән мирас. Чөнки аның хәтерендә гасырның бөтен вакыйгалары, шул чор кешеләре хакындагы хатирәләр саклана. Икенчедән, Нәүхәбәр белән бергә бүгенгегә мирас итеп татар җанын, хатын-кыз халәтен, ир-ат холкын ача торган предметлар – көнкүреш әйберләре (көзге, самавыр, сандык, бала тапкандагы күлмәге, орденннар, мылтык һ.б.) килеп җиткән. Аларның һәрберсенең тарихы бар, димәк, хәтере бар, дигән сүз. Өченчедән, әсәрдә куелган вакыйга берлеге – Нәүхәбәр карчыкның улы янына шәһәргә китәргә җыенуы – өлкән буын белән бүгенге буын татар кешеләре арасындагы бәйләнешнең өзелә баруын, ата-ана белән бала арасындагы мөнәсәбәтне ачыкларга ярдәм итә. Димәк, бабаларыбыздан килгән рухи хатирә, аларның якты истәлеге Тәүфыйкларга, алардан туган балаларга кирәк түгел. Менә фаҗига кайда. Бу – әсәрнең икенче дәрәҗәдән аңлашыла торган идеясе. Беренче дәрәҗәдәге идея исә туганлык мөнәсәбәтендә торган ике кеше арасында туган каршылыкка (ана һәм бала арасындагы) бәйле. Гомумән, татар драматургиясендә Р. Хәмид – иң көчле идея-эстетик концепцияләр биргән көчле шәхесләрнең берсе. Аның драматургиясендә чагылыш тапкан геройлар галереясына Г. Каюмова хезмәтендә тирәнтен анализ ясалган [Каюмова, 2007, б. 21].

«Милли рух сакчысы» тибына кергән мондый геройларның икенчесе итеп Мансур Гыйләҗевнең «Бичура» драмасындагы Аксак һәм Күршекәй образларын атарга кирәк. Рухларны саклап торырга тиешле урын булган бүгенге татар авылын мисалга алып, автор анда татарның бишегендә – авылда рухның бетә баруына, аның кара җаннар камалышында калуы ихтималына чаң суга. *«Үлсәгез дә нигез калырга тиеш. Нигез бетсә, бичура да үлә»* [Гыйләҗев, 2002, б. 65]. Шушы фикер белән автор татарның бишек ташы булган, әби-бабаларыбыз киләчәк буынга орлык салган йортны ничек тә саклап калырга чакыра.

1980–2000 еллар татар драматургиясендә тагын бер тип герой – бишенче тип, *Чечен сугышы корбаны*. Алар җәмгыятьтә барган сәясәтнең асылын, шәхеснең холкын, «мин»ен җимерүдәге ролен чагылдыру ягыннан әһәмиятле. Мондый тип геройлар И. Юзеевның «Эзләдем. Таптым. Югалттым», Р. Батулланың «Кояш баеганда», Ю. Сафиуллинның «Йөзек һәм хәнҗәр» әсәрләрендә бирелде. Авторлар әлеге тип герой мисалында Чечен сугышының мәгънәсезлеген, аның басып алу сәясәте булуын гына түгел, ут эченнән кайтканнарның психикаы җимерелүен, аларның тыныч тормыш шартларында яшәргә яраксыз булуын күрсәтәләр.

Т. Миңнуллинның «Эзләдем, бәгърем, сине» драмасына тукталып үтик [Миңнуллин, 2002, б. 165–247]. Нурсинә кебек тумыштан гарипләр (инвалидлар) хакында татар әдәбиятында язылган тәүге әсәрләрнең берсе бу. Нурсинәләр җәмгыятьтән читкә тибәрелгән, *маргиналь затлар* булып кала бирәләр. Драматург, беренчеләрдән булып, Рәхимҗан кебек Чечен сугышында рухи яктан «үтерелгәннәр»не тасвирлый башлады. Ә монда исә ике гарипнең бүгенге рәхимсез тормышта бер-берсен саклап калуы, бер-берсенә рухи терәк булуы яктыртыла. Шул рәвешле, драматург үз чорының иң актуаль якларына да күз сала, аны заманча итеп, сәнгать әсәре дәрәҗәсендә ачарга омтыла.

Мәкаләдә каралган драма әсәрләре, аларда яктыртылган проблемаларга анализ түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкинлек бирде.

1. 1980–2000 еллар драматургиясендә үзенчәлекле каһарман типлары хакында сөйләгәндә, татар драматургларының әсәрләрендә татар халкының милли үзбилгеләнешен, телен, мәдәниятен саклау проблемасы алга чыгарылуын күрәбез.

2. Драма әсәрләрендәге милли каһарман типлары тарихи һәм иҗтимагый үзгәрешләрнең нәтиҗәсе буларак формалаша. Герой типлары милли кодлары югалган мәдәни мохиткә урнаштырылган кешеләрнең рухи кризисы нәтиҗәсе итеп карала.

3. Милли каһарман типларын яктырта торган пьесаларда милләт яшәеше проблемасы аеруча актуальләшә һәм кискенләшә. Әсәрләрдәге сюжет үстерелеше татар халкының традицион тормыш рәвеше җимерелү, социаль нормаларның үзгәрүе белән үрелеп бара. Болар барысы да әсәрләрнең төп идеясен ачуга хезмәт итә. Драматургия аша тирән сәяси һәм социаль-мәдәни үзгәрешләрне яктырту милли идеалларны яңадан бәяләргә өнди; мәдәни кодларны һәм

милләтнең үзбилгеләнешен саклап калырга сәләтле яшь буынның рухи үсешенең оптималь стратегиясен эшләү зарурлыгына китерә.

4. Бүгенге көндә дә татар драматургиясендә мондый төр әсәрләргә ихтыяҗ зур. Бу төр драмалар – яшәеш турында уйландыра, татар драматургиясенең биеклеген саклап кала ала торган әсәрләр. Алар татар укучысын һәм тамашачысын үз асылы, рухи кыйбласы хакында ныграк уйланырга этәрә.

**Әдәбият**


*Әхмәдуллин А.* Татар драматургиясе тарихын өйрәнү мәсьәләләре // *Әхмәдуллин А*. Офыклар киңәйгәндә. Казан. Татар. кит. нәшр., 2002.

*Вагапова Л.Н.* Поэтика драматургии Ильдара Юзеева: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 2011.

*Гыйләҗев М.* Бичура. Пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 287 б.

*Каюмова Г.И.* Концепция личности в драматургии Ризвана Хамида и ее художественное воплощение: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2007.

*Мингалим Р.* Тау астында илле бүре: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 312 б.

*Миннуллина Ф.Х.* Жанр драмы в татарской драматургии рубежа XX–XXI веков. Казань: ИЯЛИ, 2019. 144 с.

*Миңнуллин Туфан.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.

*Миңнуллин Туфан.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.

*Миңнуллин Т.* Эзләдем, бәгърем, сине // *Миннуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 4 т. Казан: Татар.кит. нәшр., 2002. Б. 165–247.

*Миңнуллин Т.* Сөяркә // Казан утлары. 1998. № 6. Б. 165–247.

*Салихов Д.* Чукрак // Д. Салихов. Яшьлек хатам – йөрәк ярам: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. Б. 111–176.

*Саттарова А.М.* Современная татарская драматургия (1985–2000 гг.): концепция эпохи и героя. Казань: Гуманитария, 2003.

*Хәким З.* Шайтан куентыгы // *Хәким З.* Мин төш күрдем... Пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. Б. 307–346.

*Хәмид Р.* Ак тамырлар иле // Казан утлары. 1991. № 10. Б. 128–151.

*Хәмид Р.* Каен җиле. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 159 б.

*Хәмид Р.* Олы юлның тузаны: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 190 б.

*Шәмсутова А.* 1980–2000 еллар татар әдәбияты: Проза һәм драматургия. Программа. Казан: Gumanitaria, 2002. 29 б.

*Шәмсутова А.* Тарих таный, иҗатына җаннарын салганнарны // Казан утлары. 2005. № 6. Б. 83–107.

*Shamsutova A.* A peculiar national hero in the Tatar drama of the 1980–2000. s // 9. Milletlerarasi Türkoloji Kongresi. Istanbul. 13–16 Eylul 2021.

*Юзеев И.* Ак калфагым төшердем кулдан // *Юзеев И.* Шагыйрь сәхнәсе: драмалар, комедияләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 42–80.



***Шәмсутова Алсу Атлас кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***А.Ф. Ганиева***

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА МИЛЛИ АСЫЛНЫ САКЛАУЧЫ АНА ОБРАЗЫ

В образе матери наряду с общечеловеческими чертами, присущими всем народам, отражается и самобытный менталитет каждого народа – мировоззрение и образ жизни. Автор статьи отмечает, что татарские писатели как древних времен, так и современности часто обращаются к этому образу, расширяя его значение, и в целях укрепления национального самосознания возвышают его до статуса архетипа.

В статье представлены итоги исследования, основанного на материале произведений Г. Исхаки, Г. Ибрагимова, М. Джалиля, А. Баянова, З. Хакима и др. авторов.

**Ключевые слова:** татарская литература, проза, архетип, образ матери.

The image of mother, along with the universal human traits inherent in all nations, reflects the original mentality of each nation – the worldview and way of life. The author of the article notes that Tatar writers of both ancient times and modern times often refer to this image, expanding its meaning, and in order to strengthen national consciousness elevate it to the status of an archetype.

The article presents the results of a study based on the material of the works of G. Iskhaki, G. Ibragimov, M. Jalil, A. Bayanov, Z. Hakim, etc. authors.

**Keywords:** tatar literature, prose, archetype, mother image.

Аналитик психологиядә кеше шәхесе структурасын, аның эчтәлеген ачу кысаларында өйрәнгән һәм архетип төшенчәсен фәнни әйләнешкә керткән швейцарияле галим К.Г. Юнг ана образының аң төпкелендәге төп архетип булуын әйтә: «Сам по себе он принадлежит к величайшим ценностям человеческой души и потому заселил все олимпы всех религий» [Юнг], К. Юнгча, ана архетибы күп аспектларда каралырга мөмкин. Киң мәгънәдә ул, – гомумән, хатын-кыз: ана, әби, каенана, туендыручы яки бала караучы, нәсел башында торган алиһә, Мәрьям ана һ.б. Тагы да киңрәк алганда, җәннәт, табыну йорты, шәһәр, ил, күк, җир, урман, диңгез, ай, материя, хәтта җир шары яки галәм үзе һ.б. Тар мәгънәдә исә, – туу, барлыкка килү урыны: сөрелгән басу, бакча, мәгарә, агач, чишмә, кое, савыт формасындагы гөл (гөлчәчәк яки лотос гөле), хайваннардан сыер, куян, ана бүре, гомумән, ярдәм итүче җан ияләре. Архетипта милләтнең борынгыдан килгән мифик күзаллаулары, социаль-иҗтимагый яшәү шартлары, фәлсәфәсе, дөньяга карашы чагыла.

Татар әдәбиятында ана архетибы аерым өйрәнелмәсә дә, хатын-кыз образының бирелеше ягыннан каралган хезмәтләр языла. Мисалга, А.А. Шәмсутованың «Идейно-эстетическая эволюция проблем феминизма в творчестве Г. Исхаки (1897–1954)» (2000),

С.Р. Никишинаның «Проблема женской эмансипации в татарской литературе начала XX века» (2002), Д.М. Хәйруллинаның «Образ женщины в русской и татарской литературе 1890–1917 гг. на примере творчества Г. Исхакова и М. Горького» (2005), Л.К. Хисмәтованың «Художественные особенности творчества Мадины Маликовой» (2009), М.С. Хөснетдинованың «Система женских образов в романах Якуба Занкиева» (2010), А.А. Фаттакованың «Женские образы в татарской просветительской литературе» (2011) хезмәтләрен китерергә мөмкин.

Ана архетибы тудыручы, дөньяга тереклек яратучы буларак барлык халыкларга карый, әмма әлеге образ һәр халыкның үзенә генә хас менталитетын – дөньяга карашын, яшәү рәвешен сеңдергән. Будда һәм христиан диннәрендә (кайбер конфессияләрендә) ана Алланы дөньяга китерүче итеп карала һәм аңа табыналар. Исламда ана – гадәти кеше, әмма иң зур хөрмәткә лаек зат. Алдагы диннәрдә ана изгеләштерелсә, исламда баланың анага мөнәсәбәте алгы планга куела. Ата-ана ризалыгы – Аллаһ ризалыгына тәңгәлләштерелә. Әлеге карашлар, табигый, сүз сәнгатендә дә чагылыш таба. Борынгы төрки Орхон-Енисей истәлекләрендә Билге каганның энесе, полководец Күлтәгин (732–735 еллар) хөрмәтенә язылган текстта шундый сүзләр бар: «Атам Илтериш каган һәм анам Илбилгә-хатын» кытайлар изүеннән котылып, туган җиребезгә урнашып, төрки дәүләт төзи алган! [История татар..., 2002, с. 411].

Татар әдәбиятында анага ихтирамлы мөнәсәбәт борынгы әдәбияттан ук килә. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында үсеш алган татар реалистик прозасы да үзенең башлангыч чорында ук гаиләне иң мөһим кыйммәт дип билгели. Шул ук вакытта мәдәни күтәрелешне тәэмин иткән мәгърифәтчеләр төп игътибарны, милли кыйммәтләрне алдагы буынга тапшыручы буларак, хатын-кызга, аерым алганда, ана образына юнәлтәләр. «В творчестве писателей-просветителей второй половины XIX – начала XX столетия особое место уделяется созданию женских образов, через которые проявляется позиция автора решении сложных, актуальных проблем времени» [Фаттакова, 2011, с. 3]. Иҗатында милли идеяне аеруча көчле яңгыраткан Г. Исхакый үз әсәрләрендә ана образына зур мәгънә йөге сала. Мисал өчен, «Остазбикә» хикәясендә Сәгыйдә, физиологик яктан бала табу мөмкинлеге булмаса да, рухи яктан ана булуга ирешкән хатын-кыз итеп бирелә. Вахит хәзрәтнең варисы булмау зыялы, затлы нәсел җебенең өзелүенә китерәчәк. Сәгыйдә ирен яшь хатынга өйләндереп, проблеманы чишү юлын таба. Әлбәттә, бу адым ансат кына эшләнми, Сәгыйдәнең күңел газаплары тирән психологик кичерешләрдә тасвирлана. Язучы төп героиняны шәхси тойгыларны җиңеп, югары бәхеткә ирешүче буларак күрсәтә һәм нәселне саклап калуны – ыруг, милләтне саклау дәрәҗәсенә үстерә.

Г. Исхакыйның «Зөләйха» драмасы патша самодержавиесенең татарларны көчләп чукындыру вакыйгаларына багышлана. Аның төп

персонажы рухи һәм физик газаплар күреп тә, динен, иманын саклап калу өчен гомерен дә кызганмаган милли героиня буларак сурәтләнә. Монда ана-ул мөнәсәбәте гадәти булмаган югарылыкта карала. Зөләйха улының рус рухание булырга җыенганын белгәч, аңардан баш тарта. Үләр алдыннан Захарның Әхмәткә әйләнеп, ислам динен кабул итүен белгәч кенә, улын кичерә. Ана өчен баланың иманы беренче урында. «Материнство Зулейхи – образец эстетики классицизма. В практике мировой литературы немало произведений, в которых оправдывается отрешение матери от сына или дочери во имя интересов нации и государства. Это не просто мать конкретного семейства, ее образ приобретает символическое значение матери нации, матери всего татарского народа. С гордостью несет Зулейха свой «крест». Поруганная властями, насильно оторванная от родной семьи, из милой ее сердцу этнической среды, женщина самоотверженно борется за сохранение своего этнического и гендерного самосознания. Она не желает становиться маргиналом. В этом заключается ее эстетическая ценность, и ее образ возводится до уровня святыни» [Хайруллина, 2015, с. 18]. Г. Исхакый үзенең әлеге әсәрендә милләт һәм диннең бөтенлеген, аларның кеше тормышында мөһим факторлар, кешене кеше итүче рухи төшенчәләр булуын ассызыклый. Зөләйха рухын, иманын саклаучы, намусына тугры калган горур милләт вәкиле булып кабул ителә.

Г. Ибраһимовның да инкыйлабка кадәрге чор иҗатында милли идеянең көчле булуын күрәбез. Аның әлеге дәвер әсәрләре арасында иң гүзәле саналган «Яшь йөрәкләр» романында кешенең дөньяга карашын киңәйтүдә, рухи матурлык тәрбияләүдә, милләтнең үзбилгеләнешендә, үсешендә һәм танылуында милли сәнгатьнең әһәмиятле роль уйнавы ассызыклана. Роман геройларның эчке каршылыгын, фәлсәфи уйлануларын, психологик кичерешләрен оста сурәтләве белән татар әдәбиятында үз чоры өчен яңалык була. Авторга рус классик романнары тасвири чараларын, кешенең рухи халәтен ачу үрнәкләрен өйрәнү иҗади җим булып хезмәт иткән. Г. Ибраһимов шулар үрнәгендә мәхәббәтнең татар холкына, менталитетына гына хас үзенчәлекләрен гаҗәеп осталык белән тасвирлый. Мәрьям белән Зыяның саф, керсез сөюе, җир мәхәббәте генә булмыйча, илаһилаштыру дәрәҗәсенә күтәрелеп сурәтләнсә, ана-бала мөнәсәбәтләре якты, нурлы, укучы күңеленә үтеп керерлек җылылык белән чагылдырыла. Зөләйханың сөекле газиз улын солдатка озату газаплары укучы күңеленең иң нечкә кылларын тибрәтерлек сентименталь ноталарда бирелә. Зыя солдатка алынды дигән көннән башлап, ана сүз белән аңлатып бирә алмый торган хәсрәткә төшә: ябыга, көя, «зур күзләре әллә кая эчкә батып, һәрнәрсәгә авыр, җитди, өмитсез карый торганга» [Ибраһимов, 2018, б. 422] әйләнә. «Дөньясы тузылган, эшләрендә тәртип беткән... Намазларын гадәттәгедән озак һәм күп укый. (...) Дөнья тын, авыл йокыга чума, өйләрдә ут сүндерелеп, Һәркем онытыла, икенче дөньяга китә – менә шул вакыт ул намазлыгын җәя,

янына басып кына кечкенә шәмен куя да тын вә ярым караңгы өйдә, пакь намазлык өстендә кулында тәсбих, алдында «Коръән» улдыгы хәлдә, сынган күңелдән илаһи бер хөлус» (ихласлык) белән тәңрегә тәүбәсен, догасын, теләген гарыз итә – ялына, ялвара. Бәгъзан шул хәлдә таңнар атып китә...» [Ибраһимов, 2018, б. 423]. Аның кичерешләрендәге әһәмиятле бер моментка игътибар итү кирәк. Әни кешегә бала һәрвакыт газиз. Тик автор иҗат иткән инкыйлабка кадәрге чорда – интернационализм идеясе сеңдерелгәнче – халыкта милли, дини асылны саклау хисе көчле була. Зөләйханың борчылуы улының җан һәм тән исәнлеге өчен генә түгел, ул аның «мыжгырдап торган чәчле, тәреле адәмнәр арасында, башында картус булган хәлдә, бисмилласыз, сул кулы белән тотып чучка ите ашап [Ибраһимов, 2018, б. 423] утыруыннан, «Коръән укый торган тавышының бетүеннән», «йөзенең урыс төслегә әверелүеннән» [Ибраһимов, 2018, б. 423] курка. Ана кеше баласының рухын, иманын кайгырта. Исхакый драмасындагы кебек, монда да, шулай ук Г. Тукайның «Ана догасы» шигырендә, Ф. Әмирханның «Зәгыйфь карчыкның корбаны» кебек хикәяләрендә дә ананың баласы өчен Алладан сорау мотивы кабатлана. Болар исә революциягә кадәрге әдипләр иҗатында иман һәм рух бөтенлегенең бәдәни яшәештән өстен куелуын күрсәтә.

Октябрь инкыйлабыннан соң гаилә институты тамырдан үзгәрә. «В первые годы существования советской власти семья и брак как социальные институты целенаправленно разрушались на законодательном уровне, действительно, “до основанья”. Одновременно активно вырабатывались и внедрялись новые моральные нормы и ценности, взамен прежних “буржуазных”. По сути, произошла девальвация морально-нравственных норм, общечеловеческих ценностей, которые можно было не учитывать в отношении “врагов”, “чужих”, даже если речь шла о членах семьи. Семья, по сути, была приспособлена к задачам тоталитарного государства» [Володина, 2013].

Моның белән хатын-кызның – ананың әдәбиятта сурәтләнешенә дә үзгәрешләр килә. Ана буыннан буынга тапшырылып килгән гаилә кыйммәтләрен саклаучы түгел, ә яңа җәмгыять төзүдә катнашучы – иҗтимагый эшчәнлек алып баручы һәм соңрак, социалистик реализм таләп иткәнчә, революцион үсештә сурәтләнергә тиеш була башлый. Әмма татар әдәбиятында М. Горькийның Пелагея Ниловнасы (социалистик реализмның беренче әсәре буларак бәяләнгән «Ана» романы, 1906) үрнәгендәге иҗтимагый карашлар үзгәрешен киң фәлсәфипсихологик планда гәүдәләндергән образны табуы кыен. Бездә хатын-кыз язмышы сурәтләнгәндә аның ире белән үзара мөнәсәбәтенә дә зур урын бирелә.

Инкыйлабтан соң совет хөкүмәте татарның дәүләтчелек тарихын каралтып күрсәтү, Казан ханлыгына тискәре караш тәрбияләү сәясәте алып бара башлый. Партия идеологиясен данларга мәҗбүр язучылар мондый мәсьәләләрне үзенчәлекле хәл итә: мисал өчен, М. Җәлилнең «Алтынчәч» либреттосында, Ф. Урманчеев язганча, «переплелись

идеи борьбы за национальную независимость и идеи упорной и продолжительной социальной борьбы» [Урманчеев, 1984, с. 164].

М. Җәлилнең үз әсәре нигезенә Җик Мәргән мифологик дастаны сюжетын сайлавы гаҗәп түгел. 1930–1940 еллар әдәбиятында халык авыз иҗаты иркен кулланыла башлый. Моның сәбәбе берничә фактор белән билгеләнә. Беренчедән, гомумсовет күләмендә фольклористика аерым фән буларак аерылып чыга һәм күп өлкәдә аңа игътибар арта. Икенчедән, халык авыз иҗаты язучыларга тар идеологик кысалардан котылу чарасы һәм шул ук вакытта миллилекне чагылдыруның бер юлы була. Әлеге Болгар һәм Казан ханлыгы чоры тарихи вакыйгаларына килеп тоташкан әкияти дастан да шагыйрьгә халыкның милли идеяләрен чагылдырырга мөмкинлек бирә.

«Алтынчәч» либреттосының үзәгендә дошман тарафыннан күп газапларга дучар ителгән, тугыз баласы, туксан тугыз турыны булган ана тора. «Көчле рухлы, язмышның сындырып сынауларына да бирешмәгән, бетүгә хөкем ителгәннән соң да югалмаган Тугзак ана татар халкының символик гәүдәләнеше, башбирмәс образы булып аңлашыла» [Мостафин, Йосыпова, 2014, б. 274]. Язучы милләт сүзен кулланмаса да, шул мәгънәдә килгән ыруг төшенчәсен бирә.

Бетермәкче идең ыругымны,
Менә – үзем, менә – улларым.
Халык мәңге үлми [Җәлил, 1976, б. 319].

Тугзак образында татар милли анасы архетибы гәүдәләндерелә. Әсәрдә сурәтләнгән социаль каршылык – ыругның ханга каршы көрәше – идеологик мотив. Берләшү һәм халыкның азатлык яклап яуга күтәрелүе төп идея булып тора, һәм бу Тугзак ана образы аша башкарыла.

Билгеле, мондый эчтәлекле әсәр утызынчы елларда тәнкыйтькә дучар була. Ф. Мөсәгыйть аңа «буржуаз караш калдыклары» дигән бәя биреп, мәкалә бастыра [Мөсәгыйть, 1937, 21 авг.]

Бөек Ватан сугышы һәм аннан соңгы еллар поэзиясендә ана тынычлык, кешелеклелек, тормыш, Туган ил, Ватан символларында килсә, проза һәм драматургиядә татар хатыны Миңлекамал, Нәфисә, Сания кебек, үзен Ватанга һәм партиягә багышлаган образларда гәүдәләндерелә. Алтмышынчы еллардан соң ана образына кабат милли эчтәлек салына башлый. Ә. Еники беренчеләрдән булып, «Әйтелмәгән васыять» (1965) повестендагы Акъәбине тормышта үзенең аналык вазифасын рухи-мәдәни кыйммәтләрне саклауда күрүче героиня буларак сурәтли. Әмма мирас итеп тапшырылырга тиешле кыйммәтләрне ул тапшыра алмый кала: яңа чор кешеләре булып формалашкан үз балалары, оныклары аны аңламый. Заман үзгәреше китереп чыгарган әлеге буыннар алмашындагы өзеклек авторның милләт киләчәге өчен сызлануы буларак җиткерелә.

Үзенең сәнгати фикерләве белән башкалардан аерылып торган Ә. Баянов «Тау ягы повесте»нда (1972) татар анасы архетибының

мәгънәсен үстерә. Бик үк гадәти булмаган тормыш материалы нигезендә язучы милли-фәлсәфи проблемаларны киң планда күтәрә. Приютта үскән Тәбрик исемле егет армия хезмәтеннән соң туган ягына – авылына кайта. Максаты – әнисен, әтисен табу, приютка бирелүенең сәбәпләрен ачыклау. Бер яктан, анасының күптән вафат булуы, үз атасының да, үги атасының да вак җанлылыклары һәм шуның аркасында әнисен үлемгә җиткерүләре, аларга үзенең кирәксезлеген тою – тирән психологик кичерешләрдә бирелә. Әмма, икенче яктан, Тәбрик Тугаш бабасын таба, туганы итеп якын күрүче Сөембикә апасы, аның чибәр кызы Гөләндәм белән таныша, ягымлы йөзле, яратып, көн дә чиратлап кунак итүче авыл халкы белән аралаша.

Ә. Баяновның һәр мәсьәләгә үзгә караш алып килүе әлеге повестенда да күренә: язучы үткән һәм киләчәк заман буыннары арасындагы бәйләнешкә башка яктан карый. Кешенең үткәнгә ихтирамлы булырга тиешлеге бәхәссез. «Бүгенге көн никадәр матур һәм мәгънәле, киләчәк көн никадәр якын һәм мавыктыргыч тоелса да, кешегә алар гына җитми, аңа тагын үткән тормыш та кирәк, үзенең каян килеп чыкканын да белү кирәк икән. Үз дәрәҗәсен тояр өчен, кимсенмәс өчен, ятимлек сизмәс өчен – бүгенге көн генә түгел, тарих та кирәк икән адәм баласына» [Баянов, 1979, б. 11]. Әмма «үткән»нең кешелек бурычы үтәлгәнме? Лаекмы ул киләчәк буыннарның хөрмәтенә? «Бабайлар каберлеге, алар белән очраша торган җир, янәсе. Ата-баба йоласы. Син дә ихтирам итәргә, мәхәббәт белән искә алырга, үзең башланган суга һәм туфракка табынырга тиеш. Ә алар, ул бабайлар, Тәбрикне ихтирам иткәннәр микән соң? Уйладылар микән аның җиргә киләчәге һәм язмышы нинди булачагы турында?! <...> Ә ни өчен ихтирам итәргә, ни өчен табынырга тиеш әле Тәбрик аларга? Үзләренең иң кадерле байлыкларын, йөрәк хисләрен түгел, хәтта телләрен, моңнарын да мирас итеп бирә алмаган ата-аналар хакына гыйбадәт кылу мөмкинме? Нәрсә хакына?» [Баянов, 1979, б. 93]. Шулай итеп, язучы буыннар арасындагы мөнәсәбәт мәсьәләсен башка яссылыкта күтәрә. Һәр кеше – үткән белән киләчәкне бәйләүче буын. Тарихыңны белү генә аз, син киләчәк буын алдында җавап та тотасың. «Йөрәк хисләре»ң белән бергә телеңне, моңыңны тапшыру – синең бурычың.

Автор халык мифологиясенә еш мөрәҗәгать итә (адәмнең балчыктан яратылуы, Алып батыр турындагы риваятьләр һ.б.). Символик образлар, кинаяле гыйбарәләр, метафорик чагыштырулар (буш йорт – буш җан, карачкы – кеше, кое төбе – халык хәтере, салкынлык, боз сөңгеләре һ.б.) куллану әсәрнең эчтәлеген күпмәгънәле итә. Шәҗәрә һәм аның януы, Болгар хәрабәләре, чишмә, кое, сандугач, гөлҗимеш, тау бөркетләре кебек символлар исә милли чынбарлыкны чагылдыру өчен файдаланыла. «Егетнең уйларын һәм язучының фәлсәфи карашларын туплаган лирик каймалар, чигенешләр хасил иткән бу катламда язучы татар тарихының символик урыннарын телгә ала һәм Тәбрик язмышын милләт язмышы белән янәшә кую – тагы бер яшерен эчтәлек тудыру омтылышы да ясый» [Заһидуллина, 2015, б. 287].

Повестьта ана архетибы киң мәгънәдә алына. Тәбрик өчен ана конкрет образдан Туган җир образына үстерелә. Тәбрикнең анасын эзләп кайтуы – асылга кайту, милли үзбилгеләнешен ачыкларга омтылыш булып аңлашыла. «Әлеге яссылыкта Тәбрикнең үз асылын, нәсел башын табарга тырышуы татар халкының үз тарихын эзләве белән кисешә» [Надыршина, 2014, б. 152].

З. Хәкимнең «Ана җыры» (2020) әсәре тема-идея, проблема ягыннан, шулай ук кайбер образлары белән дә «Тау ягы повесте»на бик якын. Рахман да, Тәбрик кебек, балалар йортында үсә, армия хезмәтеннән соң әнисен, әтисен ачыклау нияте белән туган ягына кайта. Ике әсәрдә дә сюжет кызыксындыру-интрига белән алып барыла. Шулай да, З. Хәким, Ә. Баяновтан аермалы буларак, төп геройны милли идеалга якынайта, XXI гасыр кешесенә үрнәк-өлге булып торучы образ итеп эшли.

«Ана җыры» фәлсәфи, лирик һәм сентиментал катламнардан тора. Ул төрле дәрәҗәдәге укучылар өчен кызыклы, чөнки ананың баласын югалтуы һәм аның еллар үткәч кенә табылуы – борынгы дөнья әдәбиятыннан алып, бүгенге массачыл әдәбиятка караган әсәрләргә кадәр иң киң таралган мотивларның берсе. Романдагы милли-фәлсәфи катлам исә аны массачыл әдәбияттан югары күтәрә.

Рахман – дөньяны музыка аша танып белүче герой. Өч яшенә – анасыннан аерылганчыга кадәр хәтерендә сакланып калган көй аны үз асылын билгеләүгә алып килә. Ә. Баянов повестендагы кебек, монда да ана образы киң планда килә. Ана – дөньяга китерүче, аның аша тел, моң, милләт төшенчәләре билгеләнә. Рахман бүгенге заман герое һәм аның язмышы фонында шәхес-милләт проблемалары үрелеп бара.

Романда күнегелгән, җайга салынган тормышның җимерелүе, ягъни хаос башлану вакыты итеп туксанынчы еллар күрсәтелә. Ил җимерелә – язмышлар җимерелә. Шул болгавыр елларда Рахман исемле сабый, анасыннан аерылып, пассажир поездында ерак Белоярск каласына китә. Балалар йортындагы тормышның тышкы ягына әһәмият бирмичә, автор игътибарын героеның рухи дөньясына юнәлтә. Абсолют ишетү сәләтенә ия баланың күңеле, әлбәттә, башкалар белән бер төсле була алмый. Өч яшенә кадәр хәтерендә аерым мизгел, күренешләр генә булып калган дөньяны, аеруча әнкәсенең бишек җырын, моңлы тавышын ул беркайчан да онытмый. Әлеге моң алга таба Рахманның үз-үзен табуына алып килгән юлга әверелә.

Әсәрдә җыр тарихи хәтерне саклаучы символ булып килә. Шундый матур мотив үрнәген Р. Батулла үзенең «Сөембикә» романында биргән иде. Болгар ханы кызы Гайшә бәгимнең фаҗигалы тарихлы көе гасырлар аша үтеп, Казан ханлыгы кешеләренең күңелендә дә яшәвен дәвам итә. Ул көйнең мәгънәсен үз тамырларын белгән, илен сөйгән, таза рухлы геройлар гына аңлый. «Ана җыры» әсәрендә дә көй, туган тел кебек, кеше асылының күрсәткече, миллилекне саклаучы рухи хәзинә, илаһи көч буларак бирелә.

З. Хәким, Ә. Баянов кебек, ата образының заманга бәйле үзгәргән модификациясен бирә. Вәсим Мәрзияне (Рахманның әнисен) улына бер яшь вакытта ук ташлый. Инде күп еллар үткәннән соң, егерме өч яшьлек чибәр егет каршына килеп баскач та, анда аталык хисләре уянмый. Соңгы ярты гасырда ата-ул мөнәсәбәтләренең җимерелүе – ир кешенең киләчәк буын алдында җаваплылык тоймавы тормышны хаоска китерүче сәбәпләрнең берсе буларак күрсәтелә.

«Ана җыры» романы, Д. Заһидуллина язганча, «Татар әдәбиятының милли-иҗтимагый юнәлешле традицияләрендә, кеше язмышы янәшәсендә милләтнең үткәне – бүгенгесе – киләчәге юлын, траекториясен сызган әсәр булып чыккан» [Заһидуллина, 2020, б. 149]. Авторны җәмгыятьтәге кешеләрнең туган телгә, милли сәнгатькә, үткәнгә мөнәсәбәте борчый һәм ул уңай геройларының сөйләмнәре, яшәү рәвешләре аша үз позициясен җиткерә, киләчәктә татар милләтенең үсеш юлларын күрсәтергә омтыла. Татарларның татарча сөйләшмәве, үз милләтеннән йөз чөерүе (Тимур, Асия образлары) әсәрдә үтемле чараларда бирелә. Чит мохиттә үскән Рахман моңа нык гаҗәпләнә. Моның белән язучы укучыга әлеге хәлнең гайре табигый күренеш булуын аңлатырга тели. Шулай ук язучы яшәү мәгънәсе мәсьәләсенә туктала һәм кешенең тормышта максаты булырга тиешлеген билгели, ә татар кешесе өчен ул ачык – үз телеңне саклау, милләтеңә хезмәт итү (Тимур белән әңгәмә).

Романда Рахман тормышында хәлиткеч роль уйнаган Фәйрүзә апа образы бар. Үзенең җыры-моңы белән ул сабый күңелен кузгатып җибәрә һәм баланың хәтерендә сакланган татарлык хисләрен уята. Рахманга ана җылысы биргән әлеге ханым татар анасы архетибы булып тора, Татарстаннан читтә яшәүче үз балаларына гына түгел, детдом баласы Рахманга да дөрес һәм милли тәрбия бирә.

Әсәрнең исеменә чыгарылган «Ана җыры» бөтен хикәяләүгә тон бирә һәм шул ук вакытта повестьның фәлсәфи проблематикасы үсеш векторын билгели [Хәбетдинова, 2020, б. 169]. «Кайбер җырлар иркәләп йоклата да, җилкетеп уята да. Елата да, елмайта да. Андый аһәң гүя башка дөньядан килә, икенче планетадан, башка күкләрдән агыла. Искиткеч матур көй, тантаналы моң, акыл белән генә төшенеп булмый торган җыр. Әйтерсең лә, монда түгел, Җиһан тирәнлегендә туган, әмма газап белән шатлык тулы бу Җирдә дә үзенә урын тапкан һәм кешеләрнең күңеленә керү сәләтенә ия бөек җыр». [Хәким, 2020, б. 80] Әлеге «җыр»ның «ана җыры» булуы әһәмиятле. Автор аны анадан балага күчә торган милли код итеп күрсәтә һәм аны яшәү коды дәрәҗәсенә үстерә. Конкрет бу рольгә язучы татар кешесенең күңел халәтен ачарга ярдәм итүче Идел, Аерылу, Диңгез, Төн, Кайгы образларын туплаган борынгы халык җыры «Су буйлап»ны сайлый.

«Алтынчәч», «Тау ягы повесте», «Ана җыры» әсәрләрен берләштереп торучы бер мотив бар, ул – ир-егетнең үз асылын, милләтен ачыкларга омтылу. Фольклор әсәрләре нигезендә язылган М. Җәлил-

нең «Алтынчәч» либреттосында Җик Мәргән дә Тәбрик, Рахман кебек, ата-анасын ачыклау аша үзен табарга омтыла:

«Тик мин белмим, кайда
Минем туган илем?..
Кем соң атам, анам?
Кем соң нәселем минем? <...>
Килеп чыктым монда
Ерак киң даладан,
Ләкин туган җирем
Таба алмыйм һаман!» [Җәлил, 1976, б. 280].

Тугзак белән Җик Мәргән табышканнан соң, ана оныгын үз халкының иреге өчен көрәшкә чакыра. Шулай итеп, ана әсәрдә гаделлек һәм азатлык символы да булып килә.

Гомумән, ана архетибы күп очракта милли проблематика белән бәйле бирелә һәм асылны саклауда мөһим образ буларак еш файдаланыла. Бу – милли үзаң үскән, милләткә югалу куркынычы янаган елларда аеруча күзгә ташлана. Татар әдәбиятында ана архетибына борынгы чордан алып бүгенге көннәргә кадәр киң мәгънәви йөк салынып килә. Ул конкрет кеше, хатын-кыз образыннан милләт символына үстерелә. Ә ана-ул мөнәсәбәтләрендә, бигрәк тә улның анасын эзләү, табу мотивларында татар кешесенең яшәү мәгънәсен эзләве һәм табуы чагылдырыла. Димәк, татар язучыларының ана образын киңәйтүе – архетип статусына күтәрүе милли үзаңны ныгыту, милләтне берләштерү максатыннан эшләнә.

**Әдәбият**

*Баянов Ә.* Тау ягы повесте: повестьлар һәм лирик парчалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 280 б.

*Володина Н.А.* Советская семья под контролем государства: 1917–1930-е гг. Современные проблемы науки и образования. 2013. № 5 URL: https://www.science-education.ru/ru/article/view?id=10628. (дата обращения: 20.08.2021).

Древнетюркские рунические письмена: Памятники в честь Кюль-тегина и Тоньюкука (Приложения) // История татар с древнейших времен: в семи томах. Т. 1: Народы Степной Евразии в древности. Казань: Рухият, 2002. 552 с.

*Җәлил М.* Алтынчәч // Әсәрләр: дүрт томда. 2 т.: шигырьләр, либреттолар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 592 б.

*Заһидуллина Д.* Зөлфәт Хәким. «Ана җыры» // Казан утлары. 2021. Б. 149–152.

*Заһидуллина Д.Ф.* Әхсән Баян: прозага шигърилекне һәм шартлылыкны кайтару // 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр: монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

*Ибраһимов Г.* Яшь йөрәкләр // Әсәрләр: 15 томда. 2 т.: повестьлар, роман / төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл. Ә.Х. Алиева. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 547 б.

*Мостафин Р., Йосыпова Н.* Муса Җәлил // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 264–286.

*Мөсәгыйть Ф.* Татар опера студиясе турында // Кызыл Татарстан. 1937. 21 авг.

*Надыршина Л.* Әхсән Баянов // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 6 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 139–159.

*Урманчеев Ф.И.* Джик-Мэген: Героический эпос татарского народа: Исследование. Казань: Татар. кн.изд-во, 1984. 312 с.

*Фаттакова А.А.* Женские образы в татарской просветительской литературе: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Тобольск. 2011. 22 с.

*Хайруллина Д.М.* Образ женщины в русской и татарской литературе 1890–1917 гг. на примере творчества Г. Исхакова и М. Горького: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005. 24 с.

*Хәбетдинова М.* «Барысы да ачыкланмаган» // Казан утлары. 2020. Б. 168–178.

*Хәким З.* Ана җыры // Казан утлары. 2021. Б. 3–80.

*Юнг К.Г.* Психологические аспекты архетипа матери. URL: https://flibusta.biz/read-book/kniga-psihologicheskie-aspekty-arhetipa-materi-131698 (дата обращения: 20.08.2021).

***Ганиева Айгөл Фирдинат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 908

*Г.М. Дәүләтшин*

## КАЗАН ХАНЛЫГЫНДА ФӘННИ БЕЛЕМНӘР ТОРЫШЫ

Казанское ханство – одно из постзолотоордынских государств, где продолжаются традиции Булгара и Золотой Орды, в том числе и в области науки. Оно тесно было связано с развитыми мусульманскими государствами. Научные знания развивались в общем русле. В статье рассматриваются состояние таких наук, как математика, астрономия, география и медицина. Автор приходит к выводу, что в обществе казанцев практиковалось немало научных знаний. В развитии их были заинтересованы и писатели и богословы. Их деятельность составляет единый процесс.

**Ключевые слова:** наука, знание, астрономия, география, математика, медицина, Мухаммедьяр, Кул Шериф.

The Kazan Khanate is one of the post-Golden Horde states, where the traditions of the Bulgar and the Golden Horde continue, including in the field of science. It was closely associated with the developed Muslim states. Scientific knowledge developed in a general way. The article discusses the state of such sciences as mathematics, astronomy, geography and medicine. The author concludes that much scientific knowledge was practiced in Kazan society. Both writers and theologians were interested in their development. Their activity is composed of a single process.

**Keywords:** science, knowledge, astronomy, geography, mathematics, medicine, Muhammadyar, Kul Sheriff.

Казан ханлыгы тарихы 1445–1552 елларны колачлый. Ханлык оешуга Җучи Олысы үзәкләрендәге эчке ызгышлар да, урындагы олысларда икътисадның, хакимиятнең, хәрби көчләрнең һ.б. ныгуы да, Болгар җирендәге феодаль таркаулык нәтиҗәсендә Казан бәклегенең / Болгар вилаятенең үсеп китүе дә йогынты ясый. 1445 елда Олуг Мөхәммәднең улы Мәхмүт Казандагы болгар династиясен бәреп төшереп, тәхеткә менә.

Казан ханлыгына озак яшәү насыйп булмаган. Язмыш биргән аз вакытның да шактый өлеше чит илбасарларга каршы көрәшкә, эчке ызгышларга сарыф ителгән. Шуңа карамастан, ул Шәрыктагы һәм Көнчыгыш Европадагы алга киткән илләр белән бер югарылыкка күтәрелә, Идел, Кама, Урал, Себер төбәкләренең мәдәни үзәгенә әверелә.

Административ-территориаль бүленеш эре даругалардан – аерым бер юнәлештәге әмир, бәкләр идарәсендә булган территориаль өлкәләрдән (Алат, Арча, Галич, Җөри, Нугай) тора. Алар, үз чиратында, олысларга яки йөзлекләргә бүленеп, еш кына җыен[1] системасы белән туры килгән (Ашыт, Байтирәк, Чабыр, Кушкапка, Мукшы һ.б.).

[1] Җыен – нигезендә икътисади, кан-кардәшлек, төбәк берлеге принциплары яткан, күмәк җирләр белән идарә итә торган бердәмлекләр.

Казаннан тыш, ханлык җирләренә Алабуга, Алат, Арча, Болгар, Җөри, Иске Казан, Кашан, Лаеш, Тәтеш, Чаллы кебек шәһәрләр, янәшәдә 750 дән артык авыл кергән.

Шәһәрләрдә, өлешчә авылларда тимерчелек, зәркәнчелек, чүлмәкчелек, күн-мех эшкәртү, тукучылык, төзелеш, кирпеч сугу, таш юыну, агач эшкәртү эшләре алга киткән. Умартачылык, балык тоту һәм сунарчылык белән дә көн күргәннәр. Аучылык хан һәм аның яраннарының яраткан шөгыле исәпләнгән.

Ханлык башкаласы Казан Болгар дәүләтенең төньяк-көнбатыш чикләрен саклаучы кирмән буларак барлыкка килә, монгол яуларыннан, Алтын Урда таркалу афәтеннән качып күченгән күп халыкларны үз тирәсенә сыендыра.

Казан ханлыгының мәркәзе риватьләрдә сөйләнелә, үз чорында ук күренекле язучы-шагыйрьләр тарафыннан яратып җырлана. Казан чит дәүләт илчеләрен, кунакларын һәм сәүдәгәрләрен бик еraktан берсеннән-берсе матур диварлары, биек күп манаралы мәчет-мәдрәсәләре, моңлы азан тавышлары белән каршы алган. «Казан тарихы» авторы 1556 елда шәһәрне басып алыр алдыннан Иван Грозныйның шәһәргә карап соклануын язган: *«Бөек кенәз падишаһ (...) шәһәр кирмәненең гадәти булмаган гүзәллеген күреп гаҗәпкә калды»* [Казанская история, с. 127–128].

Югары хакимият Җучи нәселендәге хан кулына туплана. 1518 елга кадәр ханнар Олуг Мөхәммәд, соңрак Кече Мөхәммәд нәселеннән чыгалар. Әмма соңгысы Гәрәйләр, Шәйбаниләр һәм Әхмәд нәселеннән булган ханнар идарәләре белән дә өзгәләнә.

Формаль яктан хан чикләнмәгән хакимлеккә ия: дәүләт документларына аның мөһере сугыла. Әмма ханнарның хокукы корылтай, Бөек сәед, бәкләрнең хакимлеге белән чикләнә.

Хан каршындагы киңәш органы – татар югары катлавы вәкилләре утырган диванда хәлиткеч урынны затлы Ширин, Аргын, Барын, Кыпчак ыруларыннан чыккан карачибәкләр алып тора. Югары административ һәм хәрби хакимлек, гадәттә, Шириннәр нәселеннән чыккан Олуг Карачи бәк кулында булган.

Ил өчен әһәмиятле мәсьәләләр (ханны күтәрү һәм төшерү, сугыш һәм солых, территориаль һ.б.) татар-монголлар традициясе буенча дәүләтнең югары катлавыннан булган ир-атлар катнашындагы корылтайларда хәл ителә. Ил тарихында 15 ләп корылтай җыелуы билгеле.

Дәүләт аппаратын күпсанлы түрәләр – бахши, сәркатипләр, хисапчылар, күчереп язучылар, битекчеләр, гыйлем ияләре, салым җыючылар, «Казан патшасы сакчысы» (финанс министры), дәүләт бахшие, сарай идарәчесе, ачкыччы, корал башлыгы, аталык һ.б. тәшкил иткән.

Халыкның төп өлеше – ханга яки алпавытка салым түләүче кара халык, ясактан тыш, җир, керем өчен салым түләгән, төрле йөкләмәләрне үтәгән. Илдә игенчелек беренче урынга куелып, терлекчелек ярдәмче хуҗалык тармагы исәпләнгән. Игенчеләр дәүләт җирләреннән файдаланган, община белән ясак түләгән. Ханга

хезмәттә булган кешеләргә ярлык нигезендә мәрхәмәт күрсәтеп, халкы белән бергә җир биләмәләре бүләк (сойыргал) ителгән.

Болгар иле һәм Җучи Олысының бай мәдәниятләре варисы булган Казан ханлыгы чит илләр белән борын-борыннан урнашкан бәйләнешләрне саклаган. Аеруча Урта Азия, Госманлы империясе, Мәскәү Русе (1328–1547), Мисыр, Иран, Кырым һәм башка татар ханлыклары белән сәүдә һәм рухи элемтәләр көчле була. Мөхтәрәм хаҗилар, ерак юлларны үтеп, мөселманнарның иң изге җире – Мәккәгә баралар, илчеләр Әстерхан, Бакчасарай, Мәскәү, Истанбул арасында ил мәнфәгатьләрен кайгыртып эш йөртәләр. Югары Кама, Көньяк Урал буйларында һ.б. җирле ярминкәләр эшли, алардан аеруча Ташаяк, Иделдәге Кунак утравындагы һәм Арча кырындагы ярминкәләр тирә-юньдә дан тота.

Ханлыкта ислам ныгый, үсә бара. Казан ханлыгында ислам күп гасырлык традициягә әйләнә. Халык, нигездә, шәригать кануннары буенча яши; ислам дәүләт диненә әверелә. Югары дин әһелләре, аеруча сәедләр, дәүләт эшләрендә катнашалар. Казан ханлыгы ислам нигезендә башка мөселман дәүләтләре белән ныклы дини, мәдәни, икътисади-сәүдә элемтәләрендә яши.

Идел-Урал буе халыклары арасында исламны җәелдерү буенча төп үзәкләрнең берсе булган Казанда да үз заманы өчен зур таш һәм агач мәчетләр, күпсанлы мавзолейлар – «изгеләр», ханнар һәм башка шундыйларның төрбәләре төзелгән.

Сакланып калган хезмәтләрдән, 1508 елда ук башкарылган «Коръән тәфсире» [Kadirova, с. 91–96], Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлы, әйткән сүзләре (хәдисләр) җыелмасы (1552 ел) төбәктәге дини фикерләүнең үсешен күрсәтәләр. Мөхәммәдьяр әсәрләрендә, бер яктан, динне изгеләштерү күзәтелсә, икенче яктан, башка диннәргә карата түзем караш та сизелә. Шушы ук фикерне рус тарихчысы М.Г. Худяков куәтли: *«Казан ханлыгы иҗтимагый тормышының иң якты сәхифәләреннән берсе дип башка диннәргә түземлелекне күрсәтергә кирәк...»* [Худяков, с. 197].

Мәгърифәт эше дин әһелләренә йөкләнгән Казан ханлыгында һәр мәчет каршында мәктәп-мәдрәсә эшләгән. Шул рәвешле, мәктәп-мәдрәсәләр, укырга-язарга өйрәтү белән бергә, дәүләт эш кәгазьләрен язучылар да, матур итеп китап күчерүчеләр дә, ясак җыючылар да, галимнәр, шагыйрьләр, дин белгечләре дә әзерләгән.

Илдән читкә китеп, Көнчыгышның фән, дин, мәдәният үзәкләрендә белем алып кайту мәгариф системасының үзенә күрә иң югары баскычын тәшкил иткән. Күп кенә татар укымышлылары, күренекле Көнчыгыш галимнәреннән, дин тәгълиматчыларыннан, суфилардан белем алып, шәркый ислам дөньясындагы казанышлар белән танышканнар, Көнчыгыш мәдәниятен үзләштергәннәр.

Казан иле кешеләренең мәдәниятле, аң-белемле булуын чит ил кешеләре дә билгеләп үтә. Шул вакытта Казанга килгән Австрия илчесе һәм сәяхәтчесе Сигизмунд Герберштейн: *«Казан татарлары*

*бүтәннәргә караганда аң-белемлерәк, алар иген игәләр, әйбәт өйләрдә яшиләр, киң сәүдә алып баралар»* [Герберштейн, с. 153], дип язган.

Дәүләттә зыялыларның берничә телне белүе табигый саналып, бигрәк тә гарәп һәм фарсы телләре киң кулланылган. Бәйрәм Хаҗиның «Гарәп-төрки лөгате» [Тимергалин] шул хакта сөйли. Кенәз А.М. Курбский да болай дип яза: *«...Татар теленнән тыш, бу ханлыкта 5 тел: мордва, чирмеш, воитек, ар, бишенче башкорт теле кулланыла»* [Древняя Казань, с. 136]. Әмма татар теле дәүләттә рәсми, аралашу-сөйләм, әдәби, хәтта күпмедер күләмдә халыкара тел статусында булып, дипломатия эшләрендә дә кулланылган. Мәскәүдә рус хезмәтендә татар тәрҗемәчеләре катламы формалашу да шул хакта сөйли [Усманов]. «Татарга тылмач кирәкми» дигән әйтем бу чорда да көчендә кала.

Казан ханлыгында җанлы зыялы тормыш хакында Ш. Мәрҗани хезмәтләрендә дә билгеләп үтелә: *«Галимнәр, шул исәптән габбаси изгеләр вә галәви сәедләр күп иде»* [Мәрҗани, 1900, б. 2]; бу турыда татар риваятьләре дә мәгълүмат бирә: *«Голәмәләре вә мөдәррисләре вә һәм көтепханәләре күп иде вә талибләре күп иде»* [Татар халык иҗаты, 1987, б. 55]. Казан Көнчыгыш Европада иң әһәмиятле китапханәләре булган шәһәр кебек күзаллана. Казанның бай китапханәсе легендаларга да кергән [Татар халык иҗаты, 1987, б. 55].

Казан ханлыгы чорында язылган, укылган, шул дәвердән безгә килеп ирешкән язма истәлекләр үзләренең табигатьләре белән гаять төрле. Алар арасында без төркичә, гарәпчә, фарсыча текстларны да, әдәби әсәрләрне дә, гыйльми, дини китапларны да, каберташ язмаларын һәм ярлыкларны да, тәрҗемә һәм оригиналь ядкярләрне дә очратабыз. Казан ханлыгында эш кәгазьләре культурасы югары үсешкә ирешкән була.

Затлы савытларны матур эчтәлектәге гарәп язулары белән бизәү Казан ханлыгында да һәм халкыбыз тарихының соңгырак чорларында да дәвам итә.

Болгар-татар каберташ язмалары культурасы Җучи Олысы болгарларыннан Казан ханлыгына күчә. Бу вакытта аларның бизәлеше, эчтәлеге тагын да сыйфатлырак була. Ташъязмаларда Аллаһка һәм кешегә дан җырлана, дөньялыкта яхшы эшләр эшләп калырга өндәлә.

Мөхәммәдьяр, Максуди, Кол Шәриф һ.б.ларның иҗат җимешләре – Казан ханлыгы язма мәдәниятенең даһи һәйкәлләре. Аларның үзләрендә үк язмачылык белән бәйле күренешләр, әсбаплар хакында сүз еш очрый, Казан ханлыгының югары үскән язма мәдәнияте күз алдына килеп баса.

XVI гасыр әдәби тормышы шаһите Мөхәммәдьярның:

*Бер гаҗиб бу кем шәһәрнең эче тулуг:*
*Шагыйрь улмыш барча кечек һәм олуг* [Мөхәммәдьяр, б. 40], –

дигән шигъри юллары Казан ханлыгы халкының Мөхәммәдьяр, Мөхәммәд Әмин, Кол Шәриф, Әмин-Гарифбәк, Өммикамал иҗатын гына түгел, башка шагыйрьләрне дә белгәнлеген сөйли.

Ханнарның кайберләре үзләре үк каләм остасы булганнар. Әбелгази Сафагәрәй Баһадир хан *«кылыч һәм каләм сәхибе»* [Кол Шәриф һәм аның заманы, б. 17, 72], ягъни ил өчен кылыч белән дә, үзенең язган әсәрләре белән дә көрәшкән. Мөхәммәд Әмин ханның (1487–1495, 1502–1518) талантлы, югары пафослы шигыре безнең көнгә кадәр килеп җиткән.

Казан ханлыгында да матур әдәбият әсәрләре тәрбия, педагогик максатларга хезмәт итә. Матур әдәбият җәмгыятьтә бар кешегә дә рәхәт, имин тормыш булырга тиеш, дип раслый һәм моңа гаделлек аша ирешү мөмкинлеген күрсәтә.

Ислам гыйлеме (‘илм)[1] традициясе Казан ханлыгында да дәвам ителә. Казан ханлыгында фәнни белемнәр бөтен мөселман дөньясыныкы белән бер юнәлештә үсә. Зыялылар Көнчыгышның Әбу Гали Сина, ибне Халдун, Газәли, Бируни, Зәкәрия Казвини кебек атаклы галимнәренең китаплары белән таныш булганнар.

**Математика.** Математик белемнәрнең үсеше сәүдә, җир эшләре, товар-акча салым системалары белән тыгыз бәйләнештә торган. Көнчыгыш илләрендәге кебек үк болгарларда да математик белемнәр аеруча акча-авырлык, салым системаларында, сәүдәдә, төзелештә, һөнәрчелектә, кәнсә эшендә кирәк булган.

Төрки-татар җәмгыятьләрендә, гомумән санга, санауга зур игътибар ителгән. Төрки-татар, монгол җәмгыяте, армиясе «төмәннәргә», «меңнәргә», «йөзләргә», «уннарга» бүлеп йөртелгән: шулай һәр кеше үзенең урынын, «санын» белгән. Санын белмәгән – җәмгыятькә кертелмәгән, исәпләнмәгән. Бүген дә татар телендә абруйлы кешене «санлы», аның капма-каршысын «сансыз» дип атау, «санлау» («санламау»), «санга санау» («санамау»), «санга алу» («санга алмау»), «санга сугу» («санга сукмау») кебек гыйбарәләр шушы мәгънәдә кулланыла [Исәнбәт, б. 66]. Казан ханлыгында да бу дәвам итә. Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» поэмасында *«Аны хуш сәуде, безгә булмады сан»* («аны яратты, безне кабул итмәде») юлы бар [Мөхәммәдьяр, б. 43]. «Сан» сүзе борынгы төрки телдән иске славян теленә үтеп керә [Шанский, Иванов, Шанская, с. 400]. Аның рус телендә төзелгән «сановный» сүзе әһәмияткә ия: югары санлы, дәүләттә югары урын алып торучы; көчле, мөһим; «сан» сүзеннән «сановник» сүзе дә бар – ул чиновник мәгънәсендә кулланыла.

Казан ханлыгы археологиясенең начар өйрәнелүе, язма чыганакларның аз булуы бу дәүләттә фәнни белемнәрнең торышын төгәл

[1] Мөселман доктринасында белемгә, гыйлемгә, фәнгә гадәттән тыш әһәмиятле урын бирелә. Белемгә омтылу һәр мөселманның бурычы дип игълан ителгән. Дини белем бөтенесен эченә алган мәңгелек күренеш дип хисапланган. Гыйлемлелек, бөтен нәрсәне белү, аңлау Алланың иң кодрәтле сыйфатларының берсе саналган. Кеше белеме дөньяви да, дини дә була алган. Гыйлемлелек беренче чиратта ислам традицияләрен үзләштерүгә, мистик уйга килүгә, логик фикер йөртүне аңлауга һәм энциклопедик белемле булуга кайтып калган [Ислам, с. 95]. Мөхәммәдьярда «фән», «гыйлмьият». Кара: [Кадирова, 2001, с. 147].

билгеләргә мөмкинлек бирми. Әмма, элгәреге чорлардан аермалы буларак, безнең көннәргә кадәр зур «Мәҗмәгыл-кавагыйдә» – Мөхетдин Мөйхәммәд ибн әл-Хаҗи Атмаҗиның «Мәҗмәгыл кавагыйдә гыйльме хисаб» («Арифметика фәне кагыйдәләре җыентыгы») (243 бит) килеп җиткән. Бу хезмәт, галим-математик В.М. Беркутов сүзләренә караганда, 1542 елда [Беркутов., 1987, с. 28; Беркутов, 1997], ә Г.П. Матвиевская һәм Б.А. Розенфельд фикеренчә, 1493 елда [Матвиевская, Розенфельд, кн. 2] төзелгән. Бу кулъязма хакында беренче тапкыр В.М. Беркутов язып чыкты. Өч өлештән торган җыентыкта тулы һәм вакланган саннарга, практик мисалларга аңлатма бирелә. Ул өч бүлектән торган, үз вакытында Казан мәдрәсәләрендә дәреслек буларак файдаланылган. Бу кагыйдәләр җыентыгы Казан ханлыгында математик белем бирүнең югары үсеш алуын раслый.

Хәтта соңгырак чорларда татарлар арасында таралган математик әсәрләр дә тамырдан үзгәрми. Дәреслеккә керештә бүлекләргә (фасылларга) кыскача аңлатмалар бирелә. Беренче кисәк тулы саннарга карый. Ул 16 бүлектән тора. Аларда исәп-хисап системасының икътисад, сәүдә белән турыдан-туры бәйләнештә булганнары да шактый: 11) мөлкәт бүлү, 7) «терсәк» (зираг) өлешләре, 13) лодра (ефәк үлчәме) вакланмалары, «таможня пошлиналарын җыю», «бутау», «йомырканы кәрҗиндә санау», «яллау турында», «мирас итеп калдырылган акчаны бүлү, яки аннан керем алу» һ.б.

Китапның өченче өлешендә кырык төрле мәсьәләне чишү ысуллары тәкъдим ителә.

Кулъязма кечкенә «икенче өстәмә китап» белән тәмамлана. «Өстәмә»ләрдә егерме арифметик бурыч-табышмакларны чишү ысуллары бирелә. Аларның күбесе борынгы китапларда очрый. Алар арасында «яшьне билгеләү», «янчыктагы акча суммасын чамалау», «шахмат күзәнәкләрен тиз санау» һ.б. бар. Шулай итеп, бу хезмәт арифметика буенча тормышта мөмкин булган барлык исәп-хисаплар өчен гамәли кулланма булып торган. Биредә шахмат турында да искә алына.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: исеменә карап (Атмаҗа–Atmaca хәзер төрекләрдә еш очрый торган ир-ат исеме) фикер йөрткәндә, әлеге математик әсбапның авторы төрек булгандыр. Әмма мөселман дөньясында фәнни трактатлар өчен этник, дәүләт чикләре юк. Моңа ул чорда төрки, шул исәптән госманлы һәм татар телләренең якынлыгы да ярдәм иткән. Шуңа күрә бу арифметик кулланма шактый киң таралыш алган һәм Идел буенда башлангыч белем алучылар һәм зыялылар арасында да билгеле булган. Ул Казан ханлыгы мәдрәсәләрендә дәреслек буларак файдаланыла һәм андагы математик белем бирүнең югары үсеше турында сөйли. Соңгы чорда татарлар арасында таралган математик әсәрләрдә дә принципиаль үзгәрешләргә дучар ителми.

«Могҗизнамә»дә ул чорда кулланылган метрологик терминнар да бар: *«Йирдән кабе кавәсәйн гәзәр»* [Мөхәммәд Әмин, б.146] ягъни җирдән ике ук атым ераклыкта. «Ук атым» ераклык үлчәү берәмлеге борынгы чордан ук килә. Болгарда да гамәлдә йөргән. Моннан төр-

ки-татарларда сирәк очрый торган юл үлчәве «агач» турында да сүз бар: *«Утыз өч агач юлы китәр иде»* [Мөхәммәд Әмин, б. 157].

Бу вакыттагы кабер ташларын өйрәнү метрология буенча кайбер нәтиҗәләргә һәм ул чорның математик белемнәрен ачыкларга мөмкинлек бирә.

Казан ханлыгы һәйкәлләре арасында 107–110 см озынлыктагы (биеклек) кабер плитәләре – 27 см (27×4=108) дүрт терсәк. Моннан тыш, 120 см га – 9, 130 см га – 7, 140 см га – 8 тапкыр зурлыклар кабатлана. Мондый кабер ташы терсәкләр һәм карышлар белән үлчәнгән, дип нәтиҗә ясарга була.

Рус этимологлары фикеренчә, «аршын» рус метрик системасына болгар һәм татарлардан XV–XVI гасырларда килеп кергән [Шанский, Иванов, Шанская]. А.З. Будагов сүзлегендә «казан-татар телендә» «тирсак, терсәк» урынына «аршин» дип куелган [Будагов, т. 1, с. 350].

Алтын Урдадан соңгы чордагы озынлык чараларының берсе– барлык төрки халыкларда киң таралган һәм Ираннан кергән аршын (фарсыча «араш» – «терсәк») [Севортян, с. 183–184]. Рус метрик системасына аршын XV–XVI гасырларда Идел буе татарларыннан керә [Шанский, Иванов, Шанская, с. 29].

Математик белемнәр уеннар өлкәсендә дә актив кулланылган [Ситдиков, рис. 161 (12, 19)]. Шахмат-шашка уеннары белән мавыгу болгар чорыннан ук килә. *«Юлдан бабаем барды, Шатран тактасы төшеп калды»* (чабата эзе), диелә борынгы татар табышмагында [Татар халык табышмаклары, б. 323].

Мөхәммәд Әмин Казанда Болакта, математик белемнәрне дә кулланып, инженерлык корылмалары төзетә [Тимергалин, 2 т., б. 491].

**География.** Болгар, соңрак Алтын Урда, Җучи Олысы һәм Казан ханлыгы мөселман дөньясының аерылгысыз өлешен тәшкил итәләр. Аларның дөньяга карашында территориаль-төбәктән бигрәк дини фактор өстенлек итә. Бу хәл мөселманнарның халыкара аралашуын бик нык җиңеләйткән, шул исәптән географик карашларын да баеткан.

География (җәгъръфия) фәне Көнчыгышта Ренессанс, ягъни Яңарыш чорының җимеше санала. Ул грек географиясе традицияләрен дәвам иттергән. Традиция нигезендә дөнья көньяктан төньякка җиде климатка (икълим), ягъни өлешкә бүленгән. Уртадагы, ислам үзәкләре урнашкан дүртенче климат бик эссе һәм бик салкын илләрдән бер үк ераклыкта яткан һәм, мөселман географлары фикеренчә, кеше яшәү өчен иң яхшы шартларны туплаган. Башка икълимнәр бу үзәктән никадәр ераграк урнашкан булса, анда яшәүче халыклар да цивилизациядән шулкадәр артта калган, ә инде җиденче икълим артында, төньякта яшәүче кабиләләр, гомумән, кыргыйлар дип уйланылган [Бартольд, с. 44–45; Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати, с. 71]. Болгар, Алтын Урдадан килгән бу карашлар Казан ханлыгы дәверендә дә дәвам итә. Алар әдәби әсәрләрдә дә яхшы чагылыш тапкан.

Географик карашлар Мөхәммәдьяр поэмаларында да урын алган. Алардан аңлашылганча, *бар дөнья*ның синонимы буларак, традицион рәвештә «мәшрикъ-мәгъриб», «җиде икълим» [Мөхәммәдьяр, б. 109, 126] төшенчәләре йөргән. Болгар, Казан җирләре «җиде икълимнең җиденчесендә» дип саналган. Бу чорда да һәр икълимнең язмышында күк йөзендәге җисемнәрнең мөнәсәбәте бар дип ышанганнар. Болгар – Казан ай яклавында тора дип исәпләнелгән. Бу вакытларда ислам символына әйләнгән күк җисеменең Казан химаячесе булып уйлануы калага карата мөселман дөньясында изгелеккә якын мөнәсәбәт урнашуга китергән. *«Казанның мөселман өлкәләреннән еракта һәм кяфер өлкәсенә чиктәш урнашуы», «Казанга һичбер җирдән ярдәм һәм таяныч ирешмәс, бары тик Тәңре якын һәм фәрештәләр ярдәмче»* булуы [Кол Шәриф, б. 77] да, Болгар чорындагы кебек, бу як мөселманнарына карата зур хөрмәт һәм теләктәшлек уяткан. Электән килгән астрология, ягъни «язмыш йолдызы», «бәхет йолдызы» кебек төшенчәләргә, һәркемнең күктә үз йолдызы булуга ышану, йолдызлар торышына карап юраулар бу вакытта да булган. Мөхәммәдьяр поэмаларыннан боларга күпләгән мисаллар китерергә мөмкин. Шунысы кызык, бу чорда географик өлкәләр мәсьәләсен география фәне түгел, ә бәлки риазият – математика өйрәнгән [Кол Шәриф, б. 76]. Кол Шәриф (Шәриф Хаҗитархани) йолдызлар, планеталардан хәбәрдар булган.

Казан ханлыгы чорында да мөселман тарихи-географик трактатлары белән кызыксыну сүрелми. Казан китапханәләрендә гарәп-фарсы галиме Зәкәрия Казвининың «Гаҗәибел мәхлүкат вә гараибел мәүҗудаг» («Гаҗәеп җан ияләре һәм көнкүрешнең могҗизалары») исемле китап укылган. Бу китапта табигать, җиһан хакында кызыклы мәгълүматлар тупланган. Академик И.Ю. Крачковский, А.Д. Седельниковның «Арабская книга в царской казне» дип аталган мәкаләсенә таянып, 1549 елда Казан илчелеге Кырымга барган вакытта аның рус гаскәрләре тарафыннан тартып алынуы хакында яза [Крачковский, с. 362].

В.В. Трепавлов бу вакыйганы икенче төрле аңлата [Трепавлов, с. 576]. 1549 елда Казан бәкләре солтан Сөләйман I гә, Казан тәхетенә Дәүләт-Гәрәйне җибәрүен үтенеп, илчелек юллыйлар. Госманлылар солтанына бүләк итеп, алар Зәкәрия әл-Казвининың фарсыча «Гаҗәибел мәхлүкат вә гараибел мәүҗудаг» китабын җибәрәләр. Шәһәрдә җанлы интеллектуаль тормыш хөкем сөрүе хакында башка мәгълүматлар да билгеле. Әйтик, Кырым ханы Сәгъдәт-Гәрәйнең 1526 елгы хатындагы үтенечтә «об отпуске в Казань к Сафа Гирею Усеин сеита для взятия там некоторых книг», дигән юллар бар [Исхаков, с. 96].

Шәриф Хаҗитарханиның «Зафәр намәи вилайәти Казан» исемле синкретик әсәрендә һәр өлкәнең (климатның) географик урынын билгеләү математик хисаплаулар юлы белән башкарылган. Ул чорда бу хисап математика гыйлеменә караган [Кол Шәриф, б. 76].

**Астрономия.** Традицион космогоник карашлар чынбарлыктан бик ерак булсалар да, аларда чын белем элементлары аз булмый. Традицион космогоник карашлар борынгы бабаларыбызның күк йөзен,

анда яктырткычларның урнашу тәртибен үзләренең биш бармаклары кебек белүләре хакында сөйли. С. Герберштейн татарларның йолдызларга карап яхшы ориентлашуларын махсус билгеләп үтә [Герберштейн]. Бу белем, нигездә, күзәтүгә, тойгыга гына нигезләнгән. Күк йөзе ничек күренсә, шулай кабул ителгән дә. Борынгы кешегә реаль белем җитмәсә, аңа хыял, мифлар ярдәмгә килгән. Бик борынгы заманнардан алып күк җисемнәренең төгәл терминологиясе булдырылган. Хәзер дә төрки телләрдә күк җисемнәренең исемнәрендә күп тәңгәллекләр бар. Аның тамырлары төрки уртаклык чорына ук китә [Татары, с. 315; Севортян, с. 631; Кадирова, 2018, с. 100–105].

Күк йөзе турындагы белемнәр профессионаллар даирәсендә генә калмыйча, киң халык арасында да тарала. Күк җисемнәре, аларның исемнәре, символлары магик тәэсир көче буларак та кулланыла. Алар халык юрауларында әһәмиятле урын ала.

Ибн Фадлан заманыннан ук килгән хәл ителмәгән (хәл ителмәслек) мәсьәләләрнең берсе – безнең якларда май-июнь аенда көннең озынлыгы, төннең кыскалыгы, ә кышын киресенчә төннең озынлыгы, көннең кыскалыгы сәбәпле ястү (ясигъ) намазының башкарылу астрономик вакытының чикләнүе нәтиҗәсендә аның укыла алмавы. Бу хакта дини әдәбиятта, диспутларда, аеруча ислам үзәкләрендә гасырлар буена кызу бәхәсләр бара. Бу бәхәс шактый дәрәҗәдә уйдырма, кысыр хәсрәт булса да, ул алга таба Жучи Олысында да, Казан ханлыгында да тынмый. Борынгы һәм үз чорындагы абруйлы хезмәтләрдә аны хәл итәргә омтылыш ясала. Хосусән, Хафизетдин бине Бәрәкәт әл-Нәсифинең (1310 елда үлгән) «Кәнз үл-Дакайык», «Әл-Вафи фил форуг», «Әл-Кафи» кебек абруйлы китапларына таянып эш ителә [Мәрҗани, б. 87].

Шәриф Хаҗитархани (Кол Шәриф) дә үзенең «Зафәрнамәи вилайәте Казан» хезмәтен нәкъ менә шушы хәлгә махсус тукталып башлап җибәрә: « *Җәүзү (май) йолдызыннан соң һәм Сәрәтән (июнь) йолдызының башында биш вакыт намазының берсенең – ясигъ намазының үтәлү вакыты калмас, чөнки ике имам (ягъни Имам Мөхәммәд һәм Йосыф) карашында шәфәкъ кызыллыгы, югалып китмәстән, бераз элегрәк хасил булган кызыллыктан гыйбарәттер»* [Кол Шәриф һәм аның заманы, б. 16].

Мәсьәлә башкада, бу хәл бөтен мәселман дөньясын борчып, Болгар, Казанны үзенә җәлеп итә, кяфер иле белән күрше булган Казан төбәгендәге мөселманнарга ярдәм итү теләгеннән тудыра. Аны үз күзләре белән килеп күрергә теләүчеләр дә аз булмый. Икенчедән, югарыда китерелгән хикәят Урта Азия, аеруча Харәземнең Болгар өчен дини үзәк булуын һәм исламның шуннан килеп таралуын тагын бер кат искәртә.

Хәтта бу мәсьәлә турында XIX гасырда да борчылалар. Ш. Мәрҗани бу хакта «Нәзурәтел-хак фи фәрдиат әл-гашаи вә ин ләм йагаб әш-шәфәкъ» («Әгәр дә шәфәкъ югалмаса, кичке намазның мәҗбүрилеге белән бәйле хаклыкка күзәтү») исемле аерым китап яза [Мәрҗани].

Урта гасырларда ук барлыкка килгән фәнни белемнәр татарларда әллә ни үзгәреш кичермичә соңгы чорларга кадәр гамәлдә була. Йолдызчылар квадрант, секстан кебек җайланмалардан киң файдаланалар.

**Медицина.** Урта гасырлар татар мәселман мистикасы, мифологиясенең күренекле белгече Ф.З. Яхин 1907 елда Казанда нәшер ителгән ««Төхфәтел мөлк» язмасына таянып, ислам дөньясында иң яхшы гыйлемнәрдән ислам гыйлеме, әхлак, тыйб һәм төш юрауны билгеләп үтә: *«Дүрт гыйлем җиһанда изге-яхшыдыр: әвәл, гыйлем диндер; икенче, гыйлем әдәптер; өченче,* ***гыйлем тыйббәдер****; дүртенче, тәгъбирдер»* [Яхин, б. 16]. Хәзерге заман фәннәр классификациясеннән чыгып карасак, бары өченчесе генә фәнгә карый. Ислам дөньясында тыйб кына иң файдалы, изге гыйлем булып чыга.

Аеруча бөек табиб Әбу Гали Синаның тыйб китабын яратып укыйлар. Андагы киңәшләрне тотып, үзләре туплаган тәҗрибәне дә кушып, авыруларны дәвалаганда файдаланалар. Болгар, Җучи Олысы дәүләтләрендәге кебек үк Казанда табибны *утачы,* ягъни *үләнче* дип тә йөрткәннәр. Ягъни дару үләннәре бу чорда да иң әһәмиятле шифалардан булган.

Патша, бәк балаларын каты авырудан терелтү, шуннан соң патша кызына өйләнү, ислам динен кабул итү, – алда күреп узганча, борынгыдан килгән сюжет [Дәүләтшин, б. 151–154]. Шуңа охшаш хикәят Мөхәммәдьярда да бар. Анда Заһид исемле берәүнең үлем җәзасы көтеп төрмәдә ятуы, бер дәва, бер табиб та терелтә алмаган бәк улын елан биргән үләнне изеп эчертеп савыктыруы, шуның белән җәзадан котылуы хикәяләнә. Бу вакытта да шифалы үләннәрнең, дәва буларак, киң кулланылышта булуы аңлашыла. Моннан тыш бу хикәяттәге елан дарулар белгече, символы буларак күзаллана. Бу – Борынгы Греция мифологиясендәге елан кыяфәтле Асклепийның татар варианты. Елан – хәзер дә даруханәләр символы. Казан ханлыгында мөселман «Шифа» китаплары да популяр була. Шуларның берсенә Мөхәммәд Әмин әл-Болгари шәрех яза. 1146 елда язылган борынгы «Шифа» китабын башта 1468 елда Болгарда, аннары 1473 елда Гыйракта күчерә.

Болгарда, Алтын Урдадагы кебек үк Казан ханлыгында дәва *ут,* табиб *утчы (үләнче), имче* дип йөртелгән.

Ул шул ук мәгънәне Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» поэмасында да очратабыз: *Анын имин һич утачы белмәгәй* [Мөхәммәдьяр, б. 71]. Ягъни «дәвасын, дару үләнен» [Кадирова, 2014, б. 155]. Димәк, Казан ханлыгында да дару үләннәре иң әһәмиятле дәвалау чаралары буларак файдаланылган. Гомеренең шактый өлешен Идел-Җаек буйларында, Кырымда уздырган, тирән фәлсәфи әсәрләре соңрак татарлар арасында киң таралган суфи шагыйрь Өммикамал (Исмәгыйль) (якынча 1475 елда үлгән) «татар мае», «татар дәвасы» исемле даруларны искә ала [Миңнегулов, б. 104].

Мәшһүр табиб Әбу Гали Синаның «Әл-канун-фи-т-тыйб» китабы бездә күп тапкырлар басылып чыга. Бу китап чын мәгънәсендә халык

медицинасының бер чыганагына әверелә. Андагы киңәшләрне тотып, үзләре туплаган тәҗрибәне дә кушып, авыруларны дәвалаганда файдаланалар. Аның исеме халыклаштырылып тоташ бер исемгә – Әбугалисинага әйләнә. Аның хезмәтеннән алынган өзекләрдән җыелган китаплар «халык медицинасы җыентыгы» дип йөртелгәннәр [Хайруллин, с. 36]. Халык арасында Шәрыкның бөек табибы Әбугалисина турында легенда, риваятьләр киң таралышта була. Әбугалисинаның татар халкы арасындагы мондый популярлыгының чишмә башы болгарлар чорына ук барып тоташа.

Матур әдәбият әсәрләре дини, фәнни казанышларны халыкка җиткерүдә үтемле чара да булганнар. Бу дәвер татар шагыйрьләре фән белән шөгыльләнүне, гыйльми эзләнүләр алып баруны данлыйлар. Мөхәммәдьяр әсәрләрендә галимнәргә зур бәя бирелә. Аларга хас югары әхлак сыйфатлары тасвирлана. Алардагы гадилек, сүзгә осталык мактала. Алла кебек үк, галим дә – яшерен серләрне ачарга сәләтле дип бәяләнә:

*И галим, Син серләрне белүче зат,*
*Галимлек – ул Синең мәңгелек сыйфат* [Мөхәммәдьяр, б. 142].

Галимлек бигрәк тә күренешнең асылына төшенергә омтылу кебек күзаллана:

*Тыш сурәтен галимнәр кабык диләр,–*
*Күңел халәтенә акыл төбиләр* [Мөхәммәдьяр, б. 114].

«Зафәрнамәи вилайәти Казан» әсәрендә тасвирланган иң югары акыллылык, зирәклек антик чорның бөек шәхесләре Аристотель, Платонга хас булган.

«Могҗизнамә»дә антик чорлардан ук килгән фәлсәфи фикерләүләр дә шактый. «Сәна. Аллаһны олылау шигыре» исемле өлештә шундый юл бар:

*Чар гонсыр җәмгын – адәм итә – Ул* [Мөхәммәд Әмин, б. 15].

Чар гонсыр – дөньяның нигезен тәшкил иткән, дөнья барлыкка килгәндә беренчел материя булган нәрсәләр. Күп кенә космогоник системалар нигезендә бер яки берничә халәт ята. Алар гадәттә дүртәү – ут, һава, җир, су. Мондый караш борынгы төрки халыкларда да (мәсәлән, уйгурларда) мөстәкыйль рәвештә барлыкка килгән һәм яшәгән. Моны Византия тарихчысы Феофилакт Симокатта язмаларыннан да аңлап була. «*Төркиләр барыннан да элек утны, һава һәм суны олылыйлар, җиргә дан җырлыйлар ...*» – дип язган ул [Симокатта Феофилакт, с. 161].

Казан ханлыгында да галим-голәмәләр, шагыйрь-язучылар, җырчы-музыкантлар, кул эшләре осталары һ.б. ханнар яки югары катлау вәкилләре кул астында гына яши һәм иҗат итә алганнар. Казан мәмләкәтендә фән, мәгърифәткә, сәнгатьнең төрле өлкәләренә химая кылучы ханнардан иң күренеклесе Мөхәммәт Әмин булган.

Шулай итеп, Казан ханлыгында фән-гыйлемнең төрле өлкәләре гамәлдә булган. Аның белән шагыйрь-язучылар да, дин әһелләре дә кызыксынган. Бу чын мәгънәсендә бердәм дини, әдәби, гыйльми күренешне тәшкил иткән. Дин белән фән дә бер-беренә каршы куелмаган. Киресенчә, алар бербөтен булган.

**Әдәбият**

*Әмирханов Х.* Тәварихы Болгария. Казан, 1883. 60 б.

*Әхмәтҗанов М.* Татар шәҗәрәләре (Беренче китап). Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 128 б.

*Бартольд В.В.* Культура мусульманства // Соч. М.: Наука. 1966. Т. VI. С. 44–45.

*Беркутов В.М.* Народный календарь и метрология болгаро-татар. Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. 28 с.

*Беркутов В.М.* Развитие математического образования болгаро-татар. Казань, 1997. 173 с.

*Будагов А.З.* Сравнительный словарь турецко-татарских наречий. Т. 1. СПб., 1869.

*Герберштейн С.* Записки о Московии / Перевод с нем. А.И.Маминова и А.В. Назаренко. М.: Изд-во МГУ, 1988. 430 с.

*Дәүләтшин ГМ.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 503 б.

Древняя Казань глазами современников и историков / Сост. и авторы комментариев Ф.Ш. Хузин, А.Г. Ситдиков. Казань, 1996. 444 с.

Ислам. Энциклопедический словарь. М., 1991.

Казанская история. Ист. повесть XVI в. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1954. 195 с.

*Исхаков Д.М.* Тюрко-татарские государства XV–XVI вв. Казань: Татар. кн. изд-во, 2009. 141 с.

*Кадирова Э.Х.* Поэмы Мухаммедьяра «Тухфа-и Мардан» и «Нур-и Содур»: лексика. Казань: РИЦ «Дом печати». 2001.

*Кадирова Э.Х.* Иске татар әдәби телендә космонимнарның кулланылышы // Тюркская ономастика: от истоков до современности: материалы Международной научно-практической конференции (Казань, 11–14 октября 2018 г.) / под ред. Г.Р. Галиуллиной. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. С. 100–105.

Кол Шәриф һәм аның заманы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 192 б.

*Кол Шәриф.* И күңел бу дөньядыр...: Газәлләр, кыйсса. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 94 б.

*Крачковский И.Ю.* Избр. соч. Т. 4. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1957. 919 с.

*Матвиевская Г.П., Розенфельд Б.А.* Математики и астрономы мусульманского средневековья и их труды (VIII–XVII вв. Книга 1–3. Книга 2. Математики и астрономы, время жизни которых известно. М.: Наука, 1983. 652 с.

*Мәрҗани Ш.* Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. 2 томда. Казан: 1885–1887. 1 т. 267 б.; 2 т. 328 б.

*Мәрҗани Ш.* Нәзурәт әл-хак фи фәрдиат әл-гашаи вә ин ләм йагаб әшшәфәкъ. Казан: Казан ун-ты типографиясе, 1870. 164 б.

*Миңнегулов Х.* Казан ханлыгы чоры язма мдәнияте // Кол Шәриф һәм аның заманы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 104 б.

*Мөхәммәдьяр.* Нуры содур. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 336 б.

*Мөхәммәт Әмин.* Могҗизнамә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 295 б.

Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.). Публикация Большакова О.Г., Монгайта А.Л. М., 1971. 133 с.

Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар / Төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйлаҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 368 б.

*Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков (Общетюркские и межтюркские основы на гласные). М.: Наука, 1974.

*Симокатта Феофилакт.* История / Перевод С.П. Кондратьева. М., 1957. 224 с.

*Ситдиков А.Г.* Казанский кремль: историко-археологическое исследование. Казань, 2006. 188 с.: ил.

Татар халык иҗаты. Бәетләр / Томны төзүчеләр: Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 352 б.

Татар халык табышмаклары / Кереш мәкалә һәм аңлатмалар белән җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. 323 б.

Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М.: Наука, 1967. 538 с.

*Тимергалин А.* Миллият сүзлеге. Өч томда. 2 т. / Фәнни консультанты Г.М. Дәүләтшин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. 684 б.

*Трепавлов В.В.* История Ногайской Орды. М., 2001., 751 с.

*Усманов М.А.* Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. Казань, 1979. 318 с.

*Хайруллин А.Н.* Влияние трудов Ибн Сина на развитие медицинских знаний в Татарстане.Ташкент, 1980. С. 36.

*Худяков М.* Очерки по истории Казанского ханства. Казань, 1990. С. 197.

*Шанский Н.М., Иванов В.В., Шанская Т.В.* Краткий этимологический словарь русского языка. М.: Просвещение, 1971.

*Яхин Ф.З.*Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан: ТДГИ нәшрияты, 2000. 268 б.

*Kadirova E.H.* Türk dillerinin eseri – Kur'an Tefsiri (XVI yy.) // Türkoloji üserine araştiırmalar / Uluslararası Hakemli Dergiıo. Afyonkarahisar – Kazan. 2015. N 11. S. 91–96.

*Мәкалә «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен*
*һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау,*
*өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4 номерлы чарасын*
*тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Дәүләтшин Гамирҗан Миргаҗан улы,***
*тарих фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирасы үзәге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398.1

*И.К. Фазлетдинов*

# БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫНЫҢ АВЫЛ ТАРИХЛАРЫН ТАСВИРЛАГАН РИВАЯТЬЛӘРДӘ МИФОЛОГИК МОТИВЛАР

Статья посвящена исследованию тотемистических и анимистических мотивов в преданиях об историях сел и деревень татар Башкортостана, их взаимосвязи с историческими фактами. В ней отдельно выделяются и анализируются мотивы, связанные с культом животного в сознании предков современных татар; исследуются различные интерпретации мотива «божественного предзнаменования» и «строительной жертвы» в преданиях указанного типа. Автор приходит к выводу о том, что данные произведения являются синтезом тотемистических, анимистических и антропоморфических воззрений наших предков с реальной историей народа.

**Ключевые слова:** предание, мифология, анимизм, тотемизм, антропоморфизм, мотив, трансформация, культ, предзнаменование.

The article is devoted to the study of totemic and animistic motifs in the legends about the stories of villages of the Tatars of Bashkortostan, their relationship with historical facts. It separately identifies and analyzes the motives associated with the cult of the animal in the minds of the ancestors of modern Tatars; examines various interpretations of the motive of «divine omen» and «building sacrifice» in the legends of this type. The author comes to the conclusion that these works are a synthesis of totemic, animistic and anthropomorphic views of our ancestors with the real history of the people.

**Keywords:** legend, mythology, animism, totemism, anthropomorphism, motive, transformation, cult, omen.

Авыл атамаларының барлыкка килүе филология фәнендә берничә яссылыкта өйрәнелә. Тел галимнәре, мәсәлән, аңа телдәге номинация күренешен өйрәнгәндә кагылалар һәм аларны «икенчел номинация»нең бер төре буларак тикшерәләр. Аның төп мәгънәсе телдә инде күптәннән яшәп килгән сүзләрнең кулланылыш функциясен үзгәртү, шул рәвештә, аларның яңа эчтәлек алуына һәм яңа вазифада файдаланыла башлавына кайтып кала [Телия, с. 129]. Шулай итеп, атамада чагылыш тапкан сүзләрнең семантикасы үзгәрә, чынбарлыкның кеше аңында художестволы чагылыш табуы нәтиҗәсендә, алар туры мәгънәләре белән түгел, ә икенче, ассоциатив мәгънәдә кабул ителә башлый [Телия, с. 130]. Бу процессның аңда ни рәвешле баруын авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдән дә күрергә мөмкин.

Кызганычка каршы, географик атамаларның, авыл исемнәренең барлыкка килү процессын махсус тикшерү эше белән соңгы елларга кадәр, нигездә, телче галимнәр генә шөгыльләнде. Аларның

хезмәтләрендә төп игътибар гыйльми этимологиягә бирелә. Атаманы халыкның үз күзлегеннән, үз тормыш тәҗрибәсенә таянып аңлату рәвешен анализлау исә икенче планга күчте. Рус риваятьләре материалына нигезләнеп, әлеге мәсьәләне махсус тикшерү эшен Н.А. Криничная башлап җибәрде. Географик атаманың барлыкка килү мотивын ул «төбәккә килеп урнашу һәм аны үзләштерү» циклына караган риваятьләр составында карый һәм аны «топонимик мотив» дип атап, еш кына риваять сюжетын хасил итеп килүен билгели [Криничная, с. 70]. Галимә әлеге мотивның өч төп версиядә гәүдәләнеш табуын ассызыклый:

1) Атама төбәккә беренче булып килеп утырган кешенең исеменә, я булмаса, кушаматына нигезләнеп аңлатыла [Криничная, с. 70];

2) Атама авыл урнашкан урынның борынгы исемен үзенә күчерә [Криничная, с. 71];

3) Атама төбәккә беренче булып утырган кешенең, я булмаса аборигенның милли үзенчәлекләренә бәйле рәвештә барлыкка килә [Криничная, с. 73–74].

Галимә фольклордагы топонимик мотивның «тарихи, этнографик, географик фактларга һәм лингвистик законнарга, гадәттә, бөтенләй буйсынмавын» ассызыклап үтә һәм шул ук вакытта, нәкъ шушы сыйфатның риваять сюжеты барлыкка килүгә һәм аның үстерелүенә аерым мөмкинлекләр ачуын билгели [Криничная, с. 77]. Без исә Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаучы риваятьләрендәге авыл атамасының барлыкка килү мотивы әлеге өч версиягә генә сыешып бетми, дигән фикердә торабыз.

Билгеле булуынча, бүгенге көндә күпчелек халкын татарлар тәшкил иткән авыллар, нигездә, Башкортстанның төньяк-көнбатышында урнашкан. Аларның барлыкка килүен тасвирлаган риваятьләрнең күпчелегендә авыл исеменең килеп чыгышы да аңлатыла. С.М. Гыйлаҗетдинов билгеләвенчә, бу – «топонимик риваятьләргә хас күренеш» [Татар…, 1987, б. 13].

Кулыбызда булган риваять материалыннан күренүенчә, Башкортстандагы күп кенә татар авылларының атамалары халкыбызның борынгы мифологик күзаллаулары, атап әйткәндә, тотемистик һәм анимистик карашларына нигезләнеп барлыкка киләләр.

Мондый риваятьләрдән ата-бабаларыбызның тере табигатьне изгеләштереп каравын да, тормыштагы һәр күренештән яшерен мәгънә эзләвен дә, үзенә теләктәшлек, ярдәм сорап, илаһи көчләргә табынуын да күрергә мөмкин. Табигатьтәге һәр күренешне борынгы кеше үзенчә интерпретацияләгән, аңа үзенчә бәя биргән, реаль чынбарлык белән бәйләргә тырышкан. Шуңа да авыл атамаларын мифологик карашларга нигезләнеп аңлаткан риваятьләрдә файдаланылган мотивлар үзләренең күптөрлелеге белән аерылып тора. Шундыйларның берсе – борынгы хайваннар культына, аларны изгеләштерүгә корылган. Әлеге культка караган образлар пантеонында ат образы аерым урын тота. Фольклорчы-галим Фатих Урманче билгеләвенчә, «ат

башта тотемистик карашлар формалашуда җитди роль уйнаса, акрынлап мәҗүси алла дәрәҗәсенә күтәрелә. Төрки-монгол һәм төрки-татар халыклары мифологиясендә һәм фольклорында күп гасырларга сузылган әлеге процессның төрле этаплары чагылыш таба» [Урманче, 2008, б. 124].

Моның ачык чагылышын төрки халыкларның риваятьләреннән, шул исәптән, авыл тарихларыннан да күрергә мөмкин. Фольклорчы-галим Ф.А. Нәдершина фикеренчә, «яңа җирләргә килеп нигезләнү» мотивы күпчелек риваятьләрдә традицион алымга таяна: фәлән-фәлән кешенең угланнары (алар, гадәттә, ике, өч, биш агай-эне итеп алына) югалган йорт хайваннарын эзләп килеп, шулар туктаган уңдырышлы җирдә нигез корып, ыру җәеп, яшәп китә» [Нәҗершина, б. 130].

Бу алым Башкортстан татарлары риваятьләре өчен дә традицион. Мәсәлән, Туймазы районы Ярмөхәммәт авылы тарихын тасвирлаган риваятьтә [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш…, б. 37–38] «Әй буенда яшәүче берәүнең ат өере» югалуы, шуларны «эзләп, ике кеше безнең якларга килеп» чыгуы һәм бирелә «малкайларның үләнгә мул, бай урында ашап» йөрүен күрүе бәян ителә. «Бу урын кешеләргә бик охшый» һәм шуңа күрә «Ярмөхәммәт исемле кеше шушында күченеп» килеп, яңа авылга нигез сала һәм аңа үз исемен бирә.

Кыйгы районы Үрге Кыйгы авылы турындагы риваятьнең бер варианты да [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк…, б. 40] охшаш сюжетка корылган. Биредә Кыйгыр исемле бер «ярлы егет»нең аты югалу, «аптырагач», аның «ат көтүчесе булып» урнашуы, ләкин «көтүгә бүреләр һөҗүм» ясап, «берничә атны имгәтеп» ташлаулары сурәтләнә. Кыйгыр җәзадан качып, «безнең якларга килеп чыга» һәм шунда «урманда йөргәндә ат көтүен күреп кала». Шулчак, «бер бия аның янына килеп баса. Бу – Кыйгырның аты була. Егет шушында өй сала, гаилә корып җибәрә». Шулай итеп, югарыда телгә алынган ике риваятьтә дә «кешеләрнең үз мал-туарлары котлы урын табып бирә» [Нәҗершина, б. 131]. Бу исә борынгыларның атны изгеләштереп карауларының ачык дәлиле булып хезмәт итә.

Күчеп утыручылар кайчандыр ташлап киткән чирле мал-туарның яңа урында кыш чыгып, хуҗаларын каршылавы һәм, шуңа бәйле рәвештә, авылга әлеге җирдә нигез салынып, исем табылу мотивына корылган риваятьләрдә дә халкыбызның борынгы ат культы үзенчәлекле чагылышын таба. Мәсәлән, Стәрлебаш районы Бүзат авылы тарихын тасвирлаган үрнәктә [Фазлетдинов. Стәрлебаш…, б. 423] «өч Пенза татары»ның яңа урыннарны килеп караулары, охшатулары, ләкин, кайтыр юлга чыккач, аларның бер атлары кинәт авырып» китүе сурәтләнә һәм «юлчылар аны бер чишмә янында калдырып китәргә мәҗбүр» булулары хакында хәбәр ителә. «Бер ел тирәсе вакыт үткәч, 7 гаилә бу якларга күчеп киләләр һәм чишмә янындагы аланга төпләнәләр. Бер көнне суга барган хатын-кызлар чишмә янында бер ат очраталар... Ул үткән килгәндә калдырып киткән чирле ат булып чыга. Бу ат – акбүз ат була. Аның савыгуына һәм исән-сау

кышлавына куанган халык авылларына Акбүзат дип исем кушарга булалар». Әлеге риваятьтә борынгы бабаларыбызның мифологик карашлары ачык күзаллана.

Ф.А. Нәдершина язуынча, «ак, бүз (күк) атлар төрле халыкларның мифологиясендә кешеләргә бәхет китерүче, изгелекле җан ияләре сыйфатында чагылыш тапкан» [Нәҙершина, б. 85]. Бу фикерне башка тикшеренүчеләр дә куәтли. Мәсәлән, Галимҗан Гыйльманов акбүзатны Кояш символы итеп карый. «Шуңа күрә, борынгы ышану буенча, акбүз атка атлана алган, аны үзенә буйсындыра алган кеше изге максатына ирешә – җир астына да төшә, утлы таулар аша да чыгып, бер төн эчендә дөньяның читенә дә барып җитә ала» [Татар..., 1996, б. 55]. Шулай итеп, белгеч фикеренчә, «Акбүз атлар яктылыкны, Көнне, Кояшны гәүдәләндергәннәр» [Татар..., 1996, б. 55].

Югарыда телгә алынган риваятьтә, без әлеге илаһи көчкә ия булган мифологик персонаж – Акбүзатның халыкның иҗтимагый аңы үсеше нәтиҗәсендә трансформация кичереп, гадәти җир тормышына якынаюын күрәбез. Биредә аның югарыда санап үтелгән илаһи сыйфатлары чагылыш тапмый. Бу исә риваятьнең борынгы мифлардан, әкиятләрдән соңрак иҗат ителүен дәлилли. Ләкин, шул ук вакытта, борынгы мифологик карашларның әлеге риваятькә тәэсире дә ачык тоемлана. Пенза татарлары тарафыннан калдырып кителгән чирле атның савыгып, бер елдан үзләрен шушы җирдә каршы алуы ниндидер гайре табигый, сәбәбенә төшенергә гади акыл гына җитмәслек вакыйга итеп карала һәм әлеге «могҗиза» атның, борынгылар карашынча, илаһи көчкә ия акбүз ат булуы белән аңлатыла. Акбүзатның кешеләрне яңа урында каршы алуы, шулай ук, нигез корасы җирләрнең уңдырышлы, үлән-суга бай, яшәр өчен уңайлы, котлы икәнлеген күрсәтүче илаһи билге сыйфатында да чыгыш ясый. Шуңа да кешеләр авылны Акбүзат дип атап, киләчәктә үзләрен бәла-казадан сакларга, яңа урында үзләренә бәхетле тормыш тәэмин итәргә омтылалар. Риваятьтән күренүенчә, борынгы мифологик карашлар халыкның бүгенге реаль тормыш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, ягъни практик максатларга хезмәт итәләр.

Шул ук вакытта әлеге үрнәк авылның борынгылыгы, аның халык аңында мифологик күзаллаулар хакимлек иткән чорларда ук нигезләнүе турында фаразларга мөмкинлек бирә. Рус фольклорчысы Н.А. Криничная билгеләвенчә, атны изгеләштерү кешелек җәмгыятенең иң борынгы чорларында ук барлыкка килеп, ул «явыз көчләрдән саклаучы, мәҗүси тәңреләрнең кодрәтен кешеләргә җиткерүче илаһи зат» буларак, авыл тарихларын тасвирлаучы риваятьләр составына килеп керә [Криничная, б. 50]. Күренекле галимебез Ф.И. Урманчеев Бүзат, яки Акбүзатның борынгы төрки-монгол эпосларында «Күктән төшкән илаһи зат, батырның җиңелмәс яклаучысы» сыйфатында сурәтләнүен күрсәтә [Урманчеев, с. 309].

Димәк, яңа урында беренче булып очраган ат – инде гади йорт хайваны гына түгел. Борынгы халык аны шушы җирләрнең хуҗасы,

иясе итеп карый, тәңреләрнең ихтыярын кешеләргә җиткерүче – арадашчы дип саный һәм, авылга аның исемен биреп, илаһи көчләргә хөрмәт-ихтирамын күрсәтергә тырыша, киләчәктә кешеләргә мәрхәмәтле булуын, зыян китермәвен үтенә. Шулай итеп, әлеге җанвар үз җирләренә күчеп утырган кешеләрнең киләчәге белән идарә итәргә сәләтле изге җан – тотем дәрәҗәсенә күтәрелә. Югарыда китерелгән риваятьтә нәкъ шушы зооморфик һәм антропоморфик карашлар чагылыш таба.

Димәк, Бүзат авылы тарихында ат культы ике яктан ачыла дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин. Аның беренчесе татар халкының борынгы мифологик карашларын үзендә чагылдырса, икенчесе милләттәшләребезнең реаль тормыш ихтыяҗларына бәйле рәвештә барлыкка килә. Еллар узу белән, риваятьтәге илаһи акбүзат үзенең күп кенә мифологик атрибутларын җуеп, кешенең аерылгысыз юлдашы, терәге – гадәти җир атына әверелә.

Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрендә аттан башка йорт хайваннарын изгеләштерү функциясен дә күрергә мөмкин. Мәсәлән, Зилаер районы Чуенчы-Чупан авылы турындагы риваятьтә [Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр..., б. 52–54] тәкә культын ачык тоемларга мөмкин. Биредә «якын-тирә авылларда яшәүче башкортлар авылыбызны Каратәкә дип тә» атаулары турында хәбәр ителә һәм моның сәбәпләре аңлатыла: «Авыл корырга тәгаенләнгән җирдә Чупан байның җәйләве булган. Көз җитеп, малларны утарга ябып куйганда, ни сәбәптәндер, бер тәкә бүленеп калган. Кибән төбендә кыш чыгып, яз көне хуҗаларын каршы алган. Шуннан авылга Каратәкә исеме ябышып калган».

Риваятьтән күренүенчә, «Чуенчы-Чупан – Зилаер районында бердәнбер татар авылы. Ул 1901 елда барлыкка килгән». Каратәкә атамасы исә бу җирләрнең борынгы хуҗалары – башкортлар арасында бик күптәннән, әле Дәүләкән районы Чуенчы авылыннан татарлар килеп, җир сатып алып, шушы урында төпләнгәнгә кадәр үк яшәгән. Шуңа да аның тамырлары мифология белән бәйле традицион мотив – йорт хайванының яңа урында кыш чыгып, хуҗаларын каршылавы һәм, шуңа бәйле рәвештә, авылга әлеге урында нигез салынып, исем табылуына килеп тоташа. Биредә тәкә кешеләргә төпләнер урын табып бирүче изге хайван дәрәҗәсенә күтәрелә һәм атаманың барлыкка килүенә сәбәпче була. Туймазы районы Карамалы-Гобәй авылы тарихының икенче вариантында [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш..., б. 32] үгез культының тәэсире тоемлана. Ул шулай ук традицион мотивка – югалган йорт хайванының хуҗаларына яшәр урын табып бирүенә корылган. Ләкин биредә кешеләргә яшәр өчен урынны тере түгел, ә үле мал-туар күрсәтә. Риваятьтә, «Кәлшәле авылыннан» югалган «бер кара үгез»нең «елга буеннан» тиресе генә табып алынуы, шуңа бәйле рәвештә, халыкның елгага Карамалы исемен бирүе («чөнки тире кара төстә була»), аның янындагы «авыл да Карамалы-Гобәй дип атала» башлавы тасвирлана. Шулай итеп, әлеге

үрнәкне халыкның борынгы мифологик карашлары таркала башлаган чорда иҗат ителгәндер, дип уйларга кирәк, чөнки биредә югалган мал-туарның хуҗа кешене яңа җирдә «могҗизалы» каршылавы кебек вакыйгалар урын алмый. Авыл нигезләнәсе урында үгезнең тиресе генә табылуы да традицион мотивның трансформация кичерүен – илаһи сыйфатларын югалтып, реаль тормышка якынаюын дәлилли.

Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрендә яңа урнашкан җиргә тере мал-туар корбан итү мотивы аерым игътибарга лаек. Аның нигезендә шулай ук хайваннар культы ята, дип исәпләргә кирәк.

Яңа нигезгә тере корбан китерү йоласы тамырлары белән ерак тарихка килеп тоташа. Н.А. Криничная фикеренчә, «борынгы заманнарда йорт салынасы урынга беренче булып аяк баскан кеше корбанга китерелгән. Ул – илаһи көчләр тарафыннан сайланган изге шәхес дип ышанылган һәм һәртөрле очраклылык биредә инкяр ителгән. Гадәттә, борынгы җәмгыятьтә корбанга гыйффәтле яшь кыз, сөекле ана, яраткан хатын һәм нигез салучы өчен башка якын кеше китерелгән» [Криничная, с. 57]. Борынгылар уйлавынча, «төзеләсе йортка шушы йоладан соң җан кергән, ул корбанга китерелгән кешенең холыкфигыль сыйфатларын үзенә алган» [Криничная, с. 59].

С.М. Гыйлаҗетдинов әлеге мотивның Казан шәһәренә нигез салынуны тасвирлаган «Елан тавы» [Татар..., 1987, б. 49–50] һәм «Умартачы кызы» [Татар..., 1987, б. 50–51] риваятьләрендә чагылыш табуын билгеләп үтә. Аларда «кала төзеләсе урын еланнардан азат ителгәч, хан бу җиргә аяк баскан иң беренче кешене җир астына күмәргә боера. Ләкин бу кеше хан улы икәнлеген күргәч, төзүчеләр аның урынына этне күмәләр. Изге йола бозылганлыктан, риваятьләр Казанның киләчәктә җимереләчәген фараз итәләр» [Гилязутдинов, с. 24]. Димәк, йорт саласы урынга корбан китерү борынгы җәмгыятьтә мәҗбүри йола булып исәпләнгән һәм аны бозу төрле бәлаказаларга илтә, дип ышанылган. Э. Тайлор раславынча, әлеге йола «борынгы вакытларда чыннан да булган гына түгел, ә озак вакыт Европа тарихында да яшәп килгән» [Тайлор, с. 61].

Кешелекнең аң ягыннан үсеше нигезгә тере бала корбан итү йоласына зур үзгәрешләр кертә. Н.А. Криничная язуынча, борынгы ышануларны югалту нәтиҗәсендә, ул изге һәм мәҗбүри гамәлдән мәгънәсез кеше үтерүгә әверелә. Йоланың трансформация кичерүе, корбан ителәсе кешенең нинди дә булса йорт хайваны: әтәч, тәкә, ат белән алыштырылуына китерә. Ләкин корбан булып, бары тик кешене алыштыра алырлык изге мал-туар гына хезмәт итә ала. Һәм биредә яңа нигезгә кеше корбан итү йоласының трансформациясен генә түгел, ә халыкның борынгы тотемистик ышануларын да күрергә мөмкин [Криничная, с. 58].

Әлеге мотив Илеш районының Бишкурай авылы тарихын тасвирлаган риваятьтә [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк..., б. 39] үз чагылышын таба. Биредә «кураз» сүзенең «фарсы теленнән»

кергәнлеге һәм «мәгънәсе әтәч дигәнгә» туры килүе турында хәбәр ителә. Яңа урынга күчеп килгән биш гаилә басуга үзләре белән «берәр әтәч алып» чыга һәм «җир башында» аларны «суеп йолкалар». Шуннан соң гына «моңа тиклем кеше кулы тимәгән җирнең чирәмен күтәрәләр. Шул биш әтәч исеме белән Бөет язы дигән су буенда авыл нигезләнә. Беренче йортны салганда да биш әтәч суюю йоласы башкарыла. Шуңа да авылны Бишкураз дип атап йөртә башлыйлар».

Күренүенчә, риваятьтә тасвирланган йоланың төп максаты – «җир ияләренең күңелен күрү» [Тайлор, с. 61]. Корбан китереләсе мал сыйфатында кешеләрнең әтәчне сайлавы да очраклы түгел. Галимҗан Гыйльманов фикеренчә, «әтәч – дөнья халыклары мифологиясендә Кояшны символлаштыручы җан иясе. Аларның асыл мифик мәгънәләре бер үк – вакыт санау.., ул Кояш кебек үк сакчыллык, иминлек символы булып та тора» [Татар..., 1996, б. 49]. Димәк, Бишкурай авылы турындагы риваятьтә борынгылар яңа урында чәчүлек ясар, йорт салыр алдыннан биш әтәчне корбан китереп, Җирдән, Кояштан муллык, иминлек, әлеге җирдә киләчәк тормышларының бәхетле булуын сораганнар. Авылны корбанга китерелгән кош-корт исеме белән Бишкураз дип атау да нәкъ шушы максатлардан чыгып башкарылган. Биредә әтәчне изгеләштереп, аны илаһи сыйфатларга ия итеп карау ачык тоемлана.

Яңа нигезгә тере мал-туар корбан итү мотивы Кушнаренко районы Каратәкә авылы тарихын тасвирлаган риваятьтә дә [Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр…, б. 71] чагылыш таба. Монда әлеге урынга беренче булып килеп төпләнгән мулланың «берсе – ак, ә икенчесе – кара» төстәге ике тәкәсе булуы, «бер бәйрәмдә» ак тәкәнең корбанга чалынуы турында хәбәр ителә. «Мулла нигез салган авылга башка күчеп килүчеләр... мулланың тәкәсен күреп, үзара килешеп, авылга Каратәкә исемен биргәннәр»,– дип әйтелә риваятьтә.

Күренүенчә, әлеге үрнәктә корбанның кемгә атап, ни рәвешле китерелгәне тасвирланмый, ягъни бу – йоланың мәгънәви нигезе, сәбәпләре халык хәтереннән җуелып баруына бер дәлил булып тора. Ләкин, тикшеренүчеләр раславынча, борынгы төркиләрдә ак тәкә – «Җир өстенә яктылык бирә торган Көн Кояшын», кара тәкә – «Җир асты Кояшын» символлаштырган [Татар..., 1996, б. 44]. Галимҗан Гыйльманов үз хезмәтендә бу фикерне дәлилләп, этнографиягә мөрәҗәгать итә һәм Түбән Кама керәшеннәрендә әлегә кадәр сакланган Учук йоласын китерә. «Аны, чын мәгънәсендә, Кояштәңрегә табыну йоласы дип атарга мөмкиндер,– ди ул. – Бу көнне авылда (яки йортта) ак тәкә суялар. Итләр пешеп чыккач, кояшка таба карап, келәүләр әйтә башлыйлар... Һәркем үзенчә теләгән: җылы кирәк булганда – җылылык, кояш нуры теләгәннәр; яңгыр булмаганда – яңгыр; кысрыклык, корылык булганда – икмәк; балалары булмаганнар бала теләгәннәр. Кояш тәңресе мәрхәмәтле, җирдәге бөтен иминлек, бәхет аның кулында, дип уйлаганнар» [Татар..., 1996, б. 44].

Югарыда китерелгән риваятьтә дә шушы ук ритуал – Кояшка табыну чагыла. Мулла ак тәкәне корбанга китереп, Кояштан үзенә яңа җирдә имин, бәхетле тормыш сораган, дип фараз итәргә мөмкин. Ә соңрак күчеп килүчеләр, авыл атамасында Кара тәкә исемен мәңгеләштереп, җир асты көчләреннән үзләренә мәрхәмәтле булуларын, зыян китермәүләрен үтенгән. Шулай итеп, беренче карашка, гадәти тормыш вакыйгасын тасвирлауга корылган риваять, чынлыкта, халкыбызның борынгы мифологик карашларын, йолаларын чагылдыра.

Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрендә күчеп утыручыларга яшәр өчен җирне теге яки бу хайван, яисә кош бүләк итү мотивы да зур урын тота. Аның нигезендә шулай ук борынгы тотемистик карашлар, тере табигать культы ята, дип исәпләргә тулы нигез бар, һәм бу еш кына авыл атамаларында ук чагылыш таба.

Мәсәлән, Шаран районының Күгәрчен Бүләк авылы турындагы риваятьтә [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш…, б. 39–40] күчеп килүчеләргә бу җирләрне күгәрченнәр «бүләк итүе» тасвирлана. «Яланның уртасында үсеп утырган ялгыз имән башына күгәрченнәр оялаган була. Алар юлчыларны күрү белән, күккә күтәрелеп, гөрли башлыйлар. «Түрдән узыгыз! Китмәгез! Бу бездән сезгә бүләк! – дигән төсле, кешеләрнең өстеннән әйләнеп очалар.

Юлчылар: «Бу безгә күгәрченнәрдән бүләктер, алар безне җибәрергә теләмиләр», – дип уйлап, монда төпләнеп калырга уйлыйлар. Әбием сөйләве буенча, шулай итеп, Күгәрчен Бүләк исемле авыл барлыкка килә», – дип хәбәр ителәә риваятьтә. Биредә күгәрчен культы ачык тоемлана. Халык бу кошларны илаһи көчкә ия, изге зат итеп санап, күгәрченнәрнең баш очына күтәрелеп, гөрли-гөрли очуларында да символик бер билге, мәгънә таба. «Димәк, әлеге җирләрдә төпләнсәк, тормыш имин, яхшы булачак. Югары көчләр күгәрченнәр аша шуны хәбәр итәләр», – дип уйлый борынгы кеше. Шулай итеп, ул үзенә хас уйлау, сөйләшү, бүләк итү кебек сыйфатларны әлеге кошларга да күчерә. Ягъни биредә борынгы мифологиягә хас җанлы һәм җансыз табигатьне кешеләштерү – антропоморфизм чагылыш таба. Халык күгәрченнәрне «Күк һәм Җир арасында илче-хәбәрче вазифасын башкаручылар» [Татар..., 1996, б. 189] итеп күрә һәм моны авыл атамасында да чагылдыра.

Шуны да әйтик, күгәрчен культы татар халкының туй, йола җырларында, күп әкият-дастаннарында ачык тоемлана. «Аларның һәммәсендә дә күгәрчен мәрхәмәтлелек, тынычлык һәм, нигездә, саф мәхәббәт символы булып кала» [Урманче, 2009, б. 174].

Яңавыл районының Айбүләк авылы тарихын тасвирлаган риваятьтә дә [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк…, б. 55–56] тотемистик карашлар, аю культы чагылыш таба. Ләкин алар биредә тирәнгәрәк яшерелгән. Беренче карашка, риваять гадәти көнкүреш вакыйгасына корылган кебек. Биредә «урманны кисеп, авыл төзи башлагач, барлык аюлар да качышып» бетүе, «кайберләрен исә»

халыкның «аулап» үтерүе турында хәбәр ителә. Имеш, шуннан соң бу урын «Аю бүләк итеп калдырган авыл» дип атала башлый. Шулай итеп, атаманың килеп чыгышы халыкның образлы фикерләвен генә чагылдыра, дип тә уйларга мөмкин. Ләкин «төрле континентларда яшәүче халыкларның материалын гомум байкап чыгу һәм өйрәнү нигезендә аюга бәйле карашларның бик борынгы һәм күп яклы булганлыгы ачыкланды. Җыеп кына әйткәндә, дөнья мифологиясендә чагылган бу образның сыны, «кыяфәте» һәм роле шушы рәвешле күзаллана: аю – илаһи җан (божество); кешеләргә файда китерүче изгелекле культур герой (мәсәлән Обь угорлары, ненецлар аюны үзләренә ут алып килүче изге җанвар дип исәпли); теге яки бу традицияне башлап җибәрүче; нәсел җебен таратучы тотем, җир асты дөньясының хуҗасы; изге корбан хайваны; аю кыяфәтендәге кеше, шаман ярдәмчесе һ.б.» [Нәҗершина, б. 38]. Югарыда сөйләнгән риваятьтә дә аюның «кешеләргә файда китерүче изгелекле герой» булганлыгы күзгә ташлана. Аюларның кешеләргә яшәр җир бүләк итүе турындагы этиологик мотив үзе үк әлеге затның антропоморфик сыйфатларга ия икәнлеген күрсәтә һәм бу авыл халкында гасырлар дәвамында аю культы яшәп килгәнлеген дәлилли. Халыкның аң ягыннан үсеше нәтиҗәсендә, борынгы бабаларыбызның мифологик карашларын – аюны җир иясе, изге хайван итеп санауны чагылдырган мотив бары тик эстетик вазифа үти башлый. Әлеге риваятьтә мифологиянең «күзгә бәреп» тормавы да шуның белән аңлатыла, чөнки ул үзенең борынгы рәвешеннән нык үзгәргән, халык аңында күп кенә детальләрен җуйган булуы мөмкин.

Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрендә авылны яңа җирдә, ау вакытында иң беренче булып очраган җәнлек исеме белән атау мотивы да чагылыш таба. Аның нигезендә шулай ук халкыбызның борынгы тотемистик ышанулары ята. Мәсәлән, Краснокама районының Иске Кабан авылы турындагы үрнәктә [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк…, б. 37] «кешеләр, шушы урынга килеп утыргач та, аңа исем эзли» башлаулары һәм «ауга чыкканда нинди җәнлек очрый, шуның исемен бирергә» карар кылулары турында хәбәр ителә. Икенче көнне ауга чыгуга, аларга кабан дуңгызы очрый... Авылга Кабан дигән исем бирәләр»,– дип аңлатыла риваятьтә атаманың килеп чыгышы.

Туймазы районының Чокадытамак авылы турындагы риваять тә [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш…, б. 37] шушы ук мотивка корылган. Бередә өч егетнең «чишмә янында тукталып хәл җыйганда», «өч кыр казы атып» алулары, шуннан «озак та уйлап тормыйча, биредә яшәргә төпләнергә» карар итүләре һәм авылны «беренче табышлары исеме белән – Өч казы дип» атаулары тасвирлана.

Яңа урында беренче булып очраган җанвар – гади җәнлек түгел. Борынгы халык аны шушы җирләрнең хуҗасы, иясе итеп карый һәм авылга аның исемен биреп, үзенең шушы җанварга булган хөрмәтихтирамын күрсәтергә тырыша, киләчәктә кешеләргә мәрхәмәтле

булуын, зыян китермәвен үтенә. Шулай итеп, әлеге җанвар үз җирләренә күчеп утырган кешеләрнең киләчәге белән идарә итәргә сәләтле изге җан – тотем дәрәҗәсенә күтәрелә. Югарыда китерелгән риваятьләрдә нәкъ шушы антропоморфик карашлар чагылыш таба. Алар борынгы халыкның җанлы табигать белән тыгыз бәйләнештә торганлыгын, аны кешедә булган барлык сыйфатларга да ия илаһи зат итеп карауларын исбатлыйлар. Авыл атамаларында тере йорт хайваны, кыргый җәнлек исемнәре гамәли максатлардан чыгып, халыкның яңа җирдә бәхетле тормышын тәэмин итү өчен файдаланыла. Аң ягыннан үсеш кичереп, мифология кеше тормышындагы хәлиткеч ролен югалткач кына, хайваннар дөньясыннан алынган тотемнар эстетик вазифа үти башлый. Шулай итеп, бары тик «инануга нигезләнгән мотивларның уйдырма икәненә әкренләп төшенү аркасында, мифологик сюжетлар халык аңында әкияткә яки легендага, ә тотемнар художестволы образларга күтәрелә» [Әхмәтйәнов, б. 61]. Каралган типтагы риваятьләрнең барлыкка килү процессын әнә шулай күзалларга кирәк.

Башкортстан татарларының авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләре арасында илаһи билге («божественное предзнаменование») мотивына корылган үрнәкләр дә очрый. Аның мәгънәсе шунда: илаһи көчләр күчеп килүчеләргә төпләнер өчен урынны магик билге аша үзләре күрсәтәләр һәм бу атамада да чагылыш таба. Югары көчләр бу билгене төрлечә бирергә мөмкин. Мәсәлән, Чишмә районы Яңавыл (борынгы исеме Күчәрсынды) авылы турындагы риваятьтә [Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр…, б. 97] мондый билге булып арба күчәре сыну вакыйгасы хезмәт итә. Шуны да әйтик, арба күчәре сыну – илаһи билге икәнлеге яшәргә яңа җир эзләп юлга чыгучылар өчен алдан ук мәгълүм була һәм, шул рәвешле, урын сайлау өчен мотивация баштан ук билгеләнә: «Чыгар алдыннан кабиләнең ир-атлары үзара килешеп куялар: «Менә без хәзер юлга чыгабыз. Кайда арбабызның күчәре сына, шунда тукталабыз», – диләр. Боларның арба күчәрләре нәкъ безнең авыл утырган урында ватыла». Күренүенчә, арба күчәре сыну биредә, чыннан да, югары көчләр тарафыннан җибәрелгән илаһи билге сыйфатында чыгыш ясый. Күчәрнең теләсә нинди урында сынмыйча, кешеләргә яшәр өчен уңайлы урында гына сафтан чыгуы да шуны раслый. «...Бер яктан елга агып ята, икенче якта – урман. Нигә шушында төпләнмәскә? Кабилә башлыгы Сәгыйть һәм ырудашлары шушында калырга карар итәләр. Авылга алар Күчәрсынды дигән исем бирәләр».

Шулай итеп, биредә илаһи билге кешеләрнең практик ихтыяҗлары белән тәңгәл килә. Ул бу урыннарда тормышның яхшы, җирнең уңдырышлы, табигатьнең яшәр өчен уңайлы булуы, явыз рухларның зыян сала алмаячаклары турында хәбәр итә. Күчеп килүчеләр, «өстән» билгеләнгән урынга төпләнеп, авылны шушы вакыйгага багышлап атап, илаһи көчләрнең яклавыннан, мәрхәмәтеннән файдаланырга өметләнәләр. Димәк, биредә дә халыкның борынгы ышанулары чагылыш таба.

Шушы ук мотив Татарстанның Буа районы Казма авылы тарихында да кабатлана [Татар…, 1987, б. 156–157]. Биредә «Татар Мәмәтхуҗасыннан»... «кая гына күчермәсеннәр, шунда утырам инде»,– дип, яңа җир эзләүче бер бабайның зиректән ясалган «арба күчәре»нең «казылмага төшеп» сынуы һәм шул урында әлеге исемдәге авыл хасил булуы турында хәбәр ителә. Алдагы үрнәктән аермалы буларак, биредә арба күчәре сыну турыдан-туры илаһи билге итеп каралмый, урын сайлауга мотивация дә алдан билгеләнми. Авылның шушы җирдә нигезләнүе дә, күчеп килүче бабайның ары барырга мөмкинлеге булмау белән (арба күчәре сынык), ягъни объектив ситуациядән чыгып аңлатыла. Бу, үз чиратында, әлеге риваятьнең Чишмә районы Күчәрсынды авылы турындагы үрнәктән соңрак, халыкның мифологик карашлары таркалган чорда иҗат ителгәнлеген күрсәтә. Шул ук вакытта биредә әлеге «илаһи билге» мотивының таралу географиясе дә зур булганлыгы ачык күзаллана.

Караидел районының Өч тиен авылы тарихын тасвирлаган риваятьтә [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк…, б. 33] мондый билге булып, яңа урыннан тимер акча табылу вакыйгасы хезмәт итә. Ул авылга исем кушылуга да сәбәпче була. Акча тапкач, мосафир:

«– Күп җирләрдә булдым, озын гомер гиздем, тик бәхетне тапмадым, – ди.

– Бу өч тиен акча юкка гына булмас, Ходай бирде аны миңа, – ди.

– Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, шуннан да шәп җир булмас, – ди.

Йорт салып, кәләш алып җибәрә. Авыл исеме шуннан торып калган».

Шулай итеп, юлдан акча табылу вакыйгасы биредә күчеп утыручыга монда төпләнергә кушып, Ходай тарафыннан җибәрелгән әмер сыйфатында чыгыш ясый. Тикшеренүчеләр язуынча, «Урта гасырлар башында алтын һәм көмеш әле акча сыйфатында файдаланылмый – натураль алмашу өстенлек итә. Борынгы җәмгыятьтә алар товар алмашу чарасы, яисә байлык җыю чыганагы булудан бигрәк, мөһим билге функциясен үтиләр...» [Гуревич, с. 196]. Аларда шушы байлыкка ия булган кешенең бәхете һәм уңышы материальләшә дип исәпләнә. Шуңа да, күп кенә йола һәм гадәтләрдә йорт төзегәндә почмаклар астына алтын, көмеш, ә кайчак бакыр акча салып калдыру күренеше бар: акча өйдән бәхет һәм байлык китмәсен өчен салына [Криничная, с. 114–115]. Ягъни алда телгә алынган риваятьтә дә яңа җирдән акча табылу бу урынга нигез салган кешеләрнең киләчәктә тормышы имин, бәхетле булачагын хәбәр итүче символ сыйфатында чыгыш ясый.

Илеш районының Теләкәй авылы турындагы үрнәктә [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк…, б. 51] мондый илаһи билге булып, яңа урында кешеләрнең теләкләре кабул булу вакыйгасы хезмәт итә. Бу теләкләр шулай ук халыкның игенчелек белән бәйле тормыш ихтыяҗларына нигезләнә. Биредә «Казан ягыннан килүче бер төркем

кеше»нең очраклы гына бер җирдә туктап, «иген чәчеп» каравы һәм «Ел яңгырлы килсен, иген уңсын», дип теләк теләгәч, табигать көчләренең аларны тыңлавы, көзен уңыш мул булуы турында хәбәр ителә. «Кешеләр сөенешеп: «Иген уңды, теләкләребез кабул булды, әйдәгез, монда төпләнеп кенә калабыз!» – дигәннәр. Шулай итеп, яңа авыл хасил булган. Аны Теләкәй дип атаганнар.

Күренүенчә, бу үрнәктә дә халыкның борынгы ышанулары чагылыш таба. Игеннең мул булуын ул үзенең теләкләренең нәтиҗәсе итеп карый, югары көчләр аның тавышын ишеткәннәр, дип исәпли һәм монда төпләнсәләр, алар кешеләрне үз ярдәмнәреннән ташламас, дип ышана. Ягъни иген уңуы бередә шулай ук илаһи билге итеп карала.

Борынгы җәмгыятьтә кеше үзен явыз рухлардан саклар өчен төрле магик эчтәлекле ритуаллардан файдаланган. Мәсәлән, яңа өйгә бичура ияләшмәсен өчен, күченер алдыннан мич чыгару [Насыйри, б. 52], балага явыз көчләр зыян салмасын өчен, аны балигълык яшенә җиткәнче алмаш исем – җанвар, кош-корт исеме белән атап йөртү [Дмитриев, с. 14] борынгы профилактик магия чаралары булып торалар. Авылга исем кушу шулай ук биредә яшәүчеләрне явыз рухлардан саклаучы магик ритуал булгандыр, дип фараз итәргә мөмкин. Кызганычка каршы, аның тәртибе, рәвеше турында мәгълүматлар безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән. Ләкин «яшәгән урыныңа озак исем кушмасаң, йортыңа бәла-каза килер» дигән борынгы ышану бүгенгә кадәр яши. Һәм ул риваятьләрдә дә чагылыш таба.

Моңа мисал итеп, Авыргазы районы Ишле авылы тарихының беренче вариантын [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш…, б. 24] китерергә мөмкин. Риваятьтә «бу җирләргә Казан ягыннан өчдүрт гаилә күчеп» утыруы һәм «көннәрдән бер көнне бу кешеләрнең маллары үлә» башлавы тасвирлана. «Гаеп җирдәдер»,– дип, алар яңа урынга күченәләр, ләкин монда да шул ук хәл кабатлана. «Бер көнне авылга Куҗак исемле бер бабай» килеп, бу казаның сәбәбен аңлата:

– Сез монда ишәеп киткәнсез икән, бер бәләкәй авылга әйләнгәнсез. Тик авылыгызга һаман исем кушмагансыз. Сез аны Ишле дип атагыз, – ди. Халык уйлана һәм, бабай белән килешеп, авылга Ишле исеме бирә».

Күренүенчә, авылга исем бирү биредә халыкны төрле бәла-казалардан саклаучы изге йола итеп бәяләнә, ә кешеләргә әлеге акыллы киңәшне биргән Куҗак бабай үзе илаһи зат дәрәҗәсенә күтәрелә. Риваятькә таянып, авылга атама бирүнең борынгы җәмгыять өчен олы әһәмиятен ачык күзалларга мөмкин.

Шулай итеп, авылны тотем җанвар, изге корбан исеме белән атау, атамада югары көчләр тарафыннан җибәрелгән «илаһи билгене» мәңгеләштерү кебек мотивларның риваятьләрдә үзәк сюжет хасил итүе кешеләрнең нәкъ әнә шул илаһи көчләр ярдәмендә үз-үзләрен бәла-казалардан, явыз рухлардан араларга тырышуы белән аңлатыла. Атамада урын алган изге җанвар, илаһи билге явыз көчләрне бирегә якын җибәрмәскә, халыкның бәхетле тормышын тәэмин итәргә

тиеш була. Мондый риваятьләр халыкның иң борынгы карашларын чагылдыра. Алар реаль чынбарлык күренешләре белән халкыбызның мифологик карашларын, иҗади фантазиясен бергә берләштереп килә һәм фольклорның башка жанрлары белән тыгыз мөнәсәбәттә торып, кабатланмас синтез тудыра.

**Әдәбият**

*Әхмәтйәнов К.Ә.* Поэтик образлылыҡ. Икенсе китап. Өфө: Китап, 1994. 192 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М.Сөләйманов Уфа: Китап, 2018. 344 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 312 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 296 б.

Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 304 б.

*Гилязутдинов С.М.* Татарские исторические предания и легенды и их художественные особенности: автореф. дис. ... канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 2000. 32 с.

*Гуревич А.Я.* Категории средневековой культуры. М.: Искусство, 1972. 318 с.

*Дмитриев С.В.* Мотив подмены младенца в сказках, легендах, преданиях // Фольклор народов РСФСР: межвузовский научный сборник / отв. ред. Л.Г. Бараг. – Уфа: Издательство БашГУ, 1990. С. 12–18.

*Криничная Н.А.* Русская народная историческая проза: вопросы генезиса и структуры / ответ. ред. В.К. Соколова. Л.: Наука, 1987. 232 с.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. 1 нче кисәк / төзүче Н.Ш. Насыйбуллина; фәнни мөхәррир И.И. Ямалтдинов. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2021. 440 б. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән).

*Насыйри Каюм.* Сайланма әсәрләр: 2 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 340 б.

*Нәҙершина Ф.А.* Халыҡ хәтере: монография / яуаплы редакторы Нур Зарипов. Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1986. 189 б.

*Тайлор Э.Б.* Первобытная культура / перевод с английского Д.А. Коропчевского, предисловие и примечания профессора А.И. Першица. М.: Государственное издательство политической литературы, 1989. 576 с.

Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Беренче китап / Галимҗан Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 388 б.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов; фәнни редакторы Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 368 б.

*Телия В.Н.* Вторичная номинация и ее виды // Языковая номинация: виды наименований / отв. ред. Б.А. Серебренников, А.А. Уфимцева. М.: Наука, 1977. С. 129–221.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: I т. (А – Г). Казан: Мәгариф, 2008. 303 б.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: II т. (Д – С). Казан: Мәгариф, 2009. 343 б.

*Урманчеев Ф.И.* Развитие татарского фольклора в контексте «Запад – Восток // Очерки по истории татарской культуры (в контексте «Запад-Восток») / под. ред. М.З. Закиева, Ф.И. Урманчеева, А. И. Садековой. Казань: Фикер, 2001. С. 300–348.

*Фазлетдинов И.К.* Стәрлебаш районы татарлары риваятьләренең тарихи һәм мифологик нигезләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Башкортстан татарлары. Стәрлебаш. 1 нче кисәк / төзүче Н.Ш. Насыйбуллина; фәнни мөхәррир И.И. Ямалтдинов. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2021. Б. 406–435.

*Мәкалә «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020 – 2024 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасының 3.19 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Фазлетдинов Илдус Камил улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент;*
*Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы доценты (Уфа);*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 378

*М.В. Кильдеев*

# ТӨБӘК ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫНДА СОЦИОЛОГИК ФӘННӘРНЕ УКЫТУНЫҢ МЕТОДИК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ ТУРЫНДА

В статье рассматривается состояние преподавания социологических дисциплин в вузах в постсоветский период. Показана определенная преемственность современной вузовской социологии с преподаваемыми в советский период обществоведческими дисциплинами.

В статье описаны различные проблемы преподавания социологии: сокращение учебных часов, оторванность программ и учебников от российских реалий и умозрительность, неудачные адаптации западных теорий к российскому опыту.

Предлагаются способы решения накопившихся проблем. Точка зрения автора заключается в том, что решением может стать создание региональных учебников, основанных на местном материале. Далее излагается методический опыт написания учебного пособия по социологии на татарском языке.

**Ключевые слова**: преподавание общественных наук, вузовская социология, двуязычное обучение, социология в Татарстане.

The article examines the state of teaching sociological disciplines in universities in the post-Soviet period. A certain continuity of modern university sociology with social science disciplines taught in the Soviet period is shown.

The article describes various problems of teaching sociology: the reduction of teaching hours, the isolation of programs and textbooks from Russian realities and speculation, unsuccessful adaptations of Western theories to the Russian experience.

The ways of solving the accumulated problems are proposed. The author's point of view is that the solution may be to create regional textbooks based on local material. Further, the methodological experience of writing a textbook on sociology in the Tatar language is described.

**Keywords:** teaching social sciences, university sociology, bilingual education, sociology in Tatarstan.

Хәзерге вакытта социология чагыштырмача яшь фән санала, чөнки аны югары уку йортларында 30 еллап элек кенә укыта башладылар. Шуңа карамастан, Россия җәмгыятендә аның традицияләре шактый тирән, һәм тарихы тоташтан диярлек кискен үсеш һәм тирән торгынлык чорларының алмашынуыннан гыйбарәт. Ике тапкыр, ил башында Николай II һәм И.В. Сталин торган заманнарда, бу фән тыелган була. Шулардан соң кыска, әмма уңышлы яңарыш чорлары башлана. 1960 елларда вузларда социологик эзләнүләр лабораторияләре ачыла, мондый лабораторияләр һәм бүлекләр предприятиеләрдә дә булдырыла. Социологларга ихтыяҗ туа, ләкин аларны бер

генә уку йорты да әзерләми. Аларның вазифаларын яңа фән белән тәэсирләнгән төрле һөнәр ияләре башкара. 1988 елда КПСС ҮКның «Совет җәмгыятенең мөһим проблемаларын чишүдә марксистик-ленинчыл социологиянең ролен күтәрү» турындагы карары чыккач, уку йортларында ниһаять социология өйрәнелә башлый.

Шул ук заманнарда, 1990 еллар башында, СССР Конституциясеннән КПССның совет җәмгыятендәге җитәкчелек роле турындагы 6 статья алына. Мәгариф һәм фән өлкәләрен коммунистик идеологиядән арындыру башлана. Шулай ук совет заманында укып, югары белемгә ия булучыларга яхшы таныш «җәмгыять белеме» предметлары (КПСС тарихы, политэкономия, диалектик материализм (диамат), тарихи материализм (истмат), фәнни коммунизм) уку планнарыннан чыгарыла. Әйтергә кирәк, вузларда оештырылган сораштырулар күрсәткәнчә, әлеге предметлар студентларда бөтенләй диярлек кызыксыну уятмаган. 1967 елда Казан университетының социологик лабораториясе җитәкчесе Р.Г. Балтанов уздырган сораштыру нәтиҗәләре дә шул турыда сөйли. КПССның игътибар үзәгендә торган җәмгыять белеме предметларын теләп өйрәнүчеләр университет студентлары арасында нибары 4,5%, Казанның башка вузларында – 17% тәшкил иткән [НА РТ. Ф. 624. Оп. 1. № 485. Л. 17]. КПСС өлкә комитетының иҗтимагый фәннәрне укытуны яхшыртуга багышланган бюро утырышында укытучылар адресына кискен тәнкыйть сүзләре яңгырый: «марксизм-ленинизм классикларының теоретик нигезләмәләре хәзерге заман белән начар бәйләнгән», «дәресләр еш кына студентларга үзләштерү өчен авыр һәм аңлашылмый, вузның профиленә һәм тыңлаучыларның һөнәри мәнфәгатьләренә туры килми диярлек» һ.б. Студентлар лекцияләргә «начар йөри» һәм тырышып укымый. 1979/80 уку елының җәйге сессиясендә имтиханда «өчле» алучылар бик күп булган. Казан химия-технология институтында – «КПСС тарихы» буенча студентларның 46% ы, «марксистик-ленинчыл философия буенча» – 56,2% ы; Казан төзүче-инженерлар институтында – «марксистик-ленинчыл философия» буенча 40,4% ы имтиханны «өчлегә» тапшырган [ЦГАИПД РТ. Ф. 15. Оп. 8. № 932. Л. 2]. Эш шунда ки, бу предметлар мәҗбүриләр рәтендә торган. Булачак «коммунизм төзүчеләр» соңгы курсларда фәнни коммунизм буенча дәүләт имтиханы тапшырырга тиеш булган.

1980–1990 еллар аралыгында социология өчен хәлиткеч, драматик советтан соңгы (постсовет) чор башлана. Идеологик предметларда махсуслашкан кафедралар, исемнәрен алмаштырып, «социология», «политология», шулай ук «культурология» атамалары белән эшләрен дәвам итәләр [Салагаев]. Булмаган, моңарчы беркайда әзерләнмәгән социологларны элеккеге «җәмгыять белеме» әһелләре алыштыра. Алар, юнәлешләрен «үзгәртеп корып», социологик гыйлем таратырга керешә. 1992 елдан Россия вузларында социология мәҗбүри предмет буларак раслана. Әлбәттә, исемен алыштыру гына яңа фәнне тернәкләндереп җибәрә алмый. Мин моны 1993 елда социология

бүлегенә укырга керүче яшьләрнең берсе буларак үзем дә раслый алам. Без, шуны белештермичә, «Социалистик өйрәтмәләр тарихы», «Марксистик-ленинчыл философия», «Социализм шартларында шәхеснең активлыгы» шикелле предметларны китапханәләрдән чыкмыйча тырышып укыдык. Ә укытучылар, хәйләләп, яратып укыткан предметларына башка исемнәр кушып, аларны иске конспектлар буенча укытуларын дәвам иткәннәр.

1990 еллар урталарыннан югары уку йортларында социологиянең «алтын гасыры» башлана. Казанның кимендә өч вузында социологлар әзерләнә, дүрт диссертация советы эшли. Югары белем бирү дәүләт стандартлары (ФГОС) нигезендә ул, предмет буларак, бөтен вузларның барлык белгечлекләрендә диярлек укытыла. Әмма 2009 елдан яңа буын стандартлар гамәлгә кергәч, күпчелек юнәлешләрдә даими фәннәр исемлегеннән төшереп калдырыла. Моның төп сәбәбе: укыту программаларының һәм дәреслекләрнең көн таләбенә җавап бирмәве. Аларның авторлары социология кебек кызыклы, эмпирик мәгълүматка искиткеч бай, тере кешеләрнең уй-гамәлләренә төшенү ысулларына өйрәткән предметның үзәгенә коры теоретик схемаларны, төшенчәләрне, схоластик бәхәсләрне, дисциплина тарихын куялар. Шуңа күрә студентларның күпчелеге аны кызыксыз, әһәмиятсез, чынбарлыкка катнашы булмаган, киләчәктәге һөнәри эшчәнлек өчен файдасыз бер предмет итеп кабул иткән. Күрүегезчә, социология яңа чорда истмат, диамат, КПСС тарихы кебек предметларның тарихын кабатлаган. Һәм бу очраклы түгел.

Кыска вакыт эчендә Югары аттестация комиссиясе (ВАК) шәһәрдәге барлык диссертация советларының эшчәнлеген туктатты. Төп сәбәп – фәнни дәрәҗәгә дәгъва итүчеләрнең күбесе фәнни эшкә сәләтсез булып чыга. Социологик эшчәнлек – ул, беренче чиратта, иҗади эш. Ә бүгенге вуз структуралары укытучыларның һәм студентларның фәнни эшчәнлеген стимуллаштырмый. Югары уку йортлары укытучылары вакытының 80–90% ы укыту-методик эшкә китә. Совет вузларында укыту-методик һәм фәнни-эзләнү эшләренең нисбәте 50 гә 50 була. Фәнни эшчәнлек формаль (һәм беркемгә кирәкмәгән) критерийлар белән үлчәнә. Максималь уку-укыту күләме, югары рейтинглы һәм чит ил журналларында даими нигездә мәкаләләр бастыру, төрле мониторингларда катнашу кебек бурычлар алда торганда, фәнни эш алып бару һәм студентларның мөстәкыйль фәнни эшенә җитәкчелек итү укытучылар өчен артык, өстәмә йөкләмә генә булып кала. Фәнни эшчәнлеккә сәләте дә, теләге дә булмаган укытучының укытуы да нәтиҗә бирми.

Хәзерге шартларда студентларга җәмгыять турындагы төп фәннең укытылмавы белән килешергә ярамый. Укытылган хәлдә дә, студентларга ул «Политология һәм социология», «Социология һәм психология» буларак керә, һәм ул болай да аз академик сәгатьләрне башка фәнни дисциплиналар белән бүлешергә мәҗбүр була. Барлык белгечлекләрдә дә тигез күләмдә, аз-азлап укытуга, ягъни элекке за-

манга кайтып булмый. Булган сәгатьләр санын саклап калу өчен, кафедралар «Коррупция һәм аңа каршы көрәш», «Тыныч халыкның террорчылык идеологиясенә каршы торуы» кебек максатсыз, системасыз предметларны укытырга мәҗбүр итеолә.

Беренче чиратта, укучыларга сыйфатлы, заманга ярашлы белем бирү максаты куелу зарур. Хәзерге кыскартылган программалар буенча социология турында тулы күзаллау бирү мөмкин түгел. Безнең карашка, социолог булмаганнарга ул, шартларга карап, махсус курслар аша укытылырга тиеш. Мәсәлән, педагоглар өчен – мәгариф социологиясе, гаилә социологиясе, яшьләр социологиясе; булачак идарәчеләр өчен – оешма социологиясе һәм хезмәт социологиясе; дини уку йортларында – дин социологиясе; икътисадчылар өчен – җәмгыять корылышы һәм иҗтимагый дифференциация; тарихчылар һәм этнографлар өчен – этносоциология; юристларга – девиацияләр социологиясе; архитекторларга – шәһәр социологиясе; журналистларга – социологик методлар һәм техникалар кебек курслар укыту бик тә урынлы һәм файдалы булыр. Социологик белемне системалы нигезгә кую аның абруен күтәрергә һәм башка фәннәр арасында лаеклы урынын табарга ярдәм итәр иде.

Предметны укытуда практикага якынлашуның икенче юлы – аны урындагы шартларга яраклаштырып татарча укыту. Социологияне татар телендә укыту «Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Кануны нигезендә алып барыла. Предметларны татарча укыту икетелле – русча һәм татарча яхшы белгән белгечләр әзерләүне күздә тота. Физика, югары математика, материаллар каршылыгы, теоретик механика, гомуми химия, төрле гуманитар фәннәр һ.б. буенча уку әсбаплары булдырыла. Шул исәптән социология буенча да аерым хезмәтләр (мәсәлән, финанс-икътисад университетында [Иванов], технология университетында [Сергеева], архитектура-төзелеш университетында [Кильдеев]) уку әсбаплары дөнья күрде. Алар буенча икетелле группаларда укытылды.

Россиядә мәгариф өлкәсендәге үзгәрешләргә бәйле рәвештә, вузларда ике телдә уку-укыту туктатыла башлый. Ләкин «Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Канунының 8 статьясы («Тәрбия һәм укуукыту телен сайлау хокукы») буенча, дәүләт Татарстан территориясендә мәгариф оешмалары системасын дәүләт телләрендә тәрбияләү һәм укытуның башка формалары белән тәэмин итәргә тиеш. Эшне ике телдә алып барырдай белгечләр һәм хезмәткәрләргә кытлык туды һәм ул артканнан-арта бара. Татар телен камил белгән укытучылар, журналистлар, радио- һәм телевидение дикторлары, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре педагоглары, медицина хезмәткәрләре, юристлар, психологлар, агрономнар, тәрҗемәчеләр, редакторлар һ.б. Татарстанда гына түгел, республикабыздан читтә дә бик кирәк. Шунлыктан Татарстанның мәгариф системасы алдына икетелле һөнәри

укыту системасын торгызу һәм камилләштерү максаты куела. Аны үтәү төрле предметлар буенча татар телендә уку әсбаплары һәм укыту-методик комплектлар булдыруны таләп итә. Бу һөнәри циклларга кергән предметларга да, гуманитар, социаль һәм икътисади цикллар предметларына да кагыла.

Безнең тарафтан язылган лекцияләр җыентыгы архитектура-төзелеш университетының татарча укыту буенча методик комиссиясе карары буенча (техник фәннәр кандидаты Р.Ә. Шакирҗанов редакциясендә) зур булмаган тираж белән басылган. Аның концепциясе ике конференциядә һәм бер методик семинарда тикшерелде. Китап ике факультетта укыту процессында файдаланылды һәм укучылардан уңай бәяләмә алды. Җыентыкның камилләштерелгән һәм тулыландырылган варианты үз вакытында «Мәгариф» нәшриятына тапшырылды, әмма нәшрият бетерелү сәбәпле басылып чыга алмады. Хәзер, ун еллап вакыт узганнан соң, югары белем өлкәсендәге үзгәрешләргә һәм яңалыкларга туры китереп, аның яңартылган вариантын әзерләү мәсьәләсе көн тәртибенә куелды.

Әлеге китап социология фәнен предмет буларак өйрәнүче студентлар өчен язылды[1]. Дөнья, ил һәм төбәк материалларында иҗтимагый система һәм җәмгыять структурасының нигезләре күрсәтелә, Россия җәмгыятенә хас күренешләргә һәм үзгәрешләргә фәнни бәя бирелә. Беренче максат – студентларны социологик теория һәм ысуллар белән эшләргә өйрәтү. Шуңа күрә биредә фәннең кайбер әһәмиятле юнәлешләре, аерым фикерләр генә урын алды. Кешеләрнең тарихи, этник, сыйнфый, максатчан туплану формаларына да игътибар бирелә. Икенче максат – укучыларның аналитик фикерләвен үстерү.

Китаптагы уналты лекция дүрт бүлеккә карый: «Теоретик социология», «Җәмгыять корылышы», «Җәмгыяви институтлар», «Социологиянең гамәли тармаклары». Лекцияләргә кушымта итеп терминнар исемлеге бирелә, аларның русчага тәрҗемәсе белән бергә кыскача аңлатмалар китерелә. Текст рәсемнәр, схемалар, таблицалар, тематик мисаллар белән баетыла. Һәр лекциягә әдәбият исемлеге һәм контроль сораулар өстәлә. Китапта урын алган үзенчәлекле иллюстратив тарихи, этнографик, әдәби, лингвистик материал социологик мәсьәләләргә төшенә алу сәләтен үстерүгә хезмәт итә.

Укучылар аудиториясенең белем һәм әзерлек дәрәҗәсеннән чыгып, без социологик белемнең нигезләрен җиткерүне максат итеп куйдык. Фәннең тарихи һәм теоретик алшартлары, методологиясе турында шактый киң һәм тәфсилле итеп язылды. Кешеләрнең тарихи, этник, иҗтимагый-сыйнфый оешу формаларына, җәмгыяви институтларга һәм практикаларга зур игътибар бирелде. Әлбәттә, социология-

---

[1] Дәреслекнең структурасы һәм эчтәлеге Казан федераль университетының мисал итеп алынган «09.03.04 – Программная инженерия» бакалаврлар укыту юнәлеше өчен тәгаенләнгән дисциплина программасы белән килештерелгән.

нең аерым тармакларын да тулырак яктыртып булыр иде, әмма дәүләт стандарты гомуми курска аерым дисциплиналар тутыруны хупламый. Гендер социологиясе, сәясәт социологиясе, мәдәният социологиясе кебек махсус дисциплиналарның студентларга кирәге дә юктыр (әгәр алар киләчәктә социология буенча кандидатлык минимумын тапшырырга ниятләмәсә). Этносоциологиягә һәм дин социологиясенә дә зур урын бирелде, чөнки бу дисциплиналарның тарихы узган гасырның 60–70 нче елларында ТАССРның шәһәр һәм авылларында үткәрелгән социологик эзләнүләр белән бәйләнгән.

Китапның структурасын эчтәлек белән баету мәсьәләсендә без икеләнеп калдык: рус һәм чит ил дәреслекләренең (аларның стилистикасы, дәлилләү системасы, фикерләү рәвеше белән бергә) эчтәлеген кабатларгамы, яки социологик проблематиканы бәян итүнең мөстәкыйль алымын табаргамы? Белем бирү стандартларына туры китерү өчен, алда торган рецензия һәм рекомендация кебек мәшәкатьләрне дә күздә тотып, беренче юл иң кулае булып күренергә мөмкин. Әмма куелган максатлардан чыгып, укучылар аудиториясенең үзенчәлеген исәпкә алып, без икенче юлны сайладык.

Студентны фәнни метод белән коралландыру максаты популяр дәреслекләрнең кирәкле урыннарын сайлап алып тәрҗемә итү белән генә хәл ителми. Көнбатыш социология дәреслекләре, хәтта иң яхшылары да (Э. Гидденс, Н. Смелзер авторлыгында), «полипарадигмальлек»[1] шаукымына бирелеп, теория, методология һәм ысул төшенчәләренә төгәл эчтәлек салмыйлар. Бу уңайдан без бик тә модалы һәм социологик дәреслекләр өчен мәҗбүри саналган «парадигма» төшенчәсен кулланмадык. Бу төшенчәнең тарафдарлары, мәсәлән, җәмгыятьнең һәм этносның булу-булмавын шик астына алалар. Ә безнеңчә, мәсьәләнең мондый куелышы фәннән ерак һәм социологияне башка социаль фәннәрдән, аеруча тарих һәм этнографиядән читләштерә. Ә ул фәннәр туплаган байлыклар, конкрет социологик тикшеренүләр белән бергә, теоретик социологиянең эмпирик нигезен хасил иткәннәр. Укыту процессында фәнни принципларны тарихи һәм этнографик материал белән сурәтләү укучы туплаган иҗтимагый-гуманитар гыйлемне активлаштыра һәм сөйләнәсе текстны мәгънә белән баета.

Минемчә, материалны бәян иткәндә теориягә дә өстенлек бирелмәскә, ә аның нигезендә фәлсәфи белемнәр ятарга тиеш. «Полипарадигмальлек»кә бәйле бәхәсләр һәм концепцияләр философия төшенчәләре белән бик яхшы тасвирлана: номинализм – реализм, детерминизм – антидетерминизм, тарихилык – антитарихилык, натуральлек – объективлык, утопия-идеология, материализм-идеализм. Җәмгыять эволюциясенә тарихи-материалистик караш социология

[1] Фәнни парадигма – күпчелек галимнәр җәмәгатьчелеге кабул иткән рациональ фәнни эшчәнлек моделе. Полипарадигмальлек шартларында берничә теория (парадигма) янәшә яши ала. Берсенең дә өстенлеге танылмый.

белән башка фәннәр – тарих, этнография, этнология, икътисад арасындагы предметара бәйләнешләр урнаштырырга ярдәм итә. Бу мәсьәлә шактый актуаль, чөнки техник белгечлекләрнең уку-укыту планнарында зур күләмдә тугандаш социогуманитар дисциплиналар урын алган. Ләкин алар биргән белемнәр арасында бәйләнеш, эзлеклелек, дәвамчанлык юк диярлек. Бер предмет дәресләрендә кергән белемнәр башка предметта яңадан кабатлап бирелә, яки, киресенчә, шул ук темага капма-каршы фикерләр әйтелә.

Без мөһим темаларны тикшергәндә төрле теоретик карашларны күрсәтергә тырыштык. Социаль үзгәрешләр темасы китапта төрле теорияләр күзлегеннән бирелә (формацияләр теориясе, Д. Беллның индустриаль җәмгыять теориясе, модернизация теориясе). Хәзерге җәмгыять үсеше (глобализация, постмодерн җәмгыять, периферия капитализмы) теорияләре бер дәрәҗәдә бирелә.

Бүген Россия чынбарлыгын аңлый һәм күрә белү проблемасы бик кискен тора. Моның сәбәбе – катгый рәвештә марксизм философиясеннән баш тарту һәм һичбер тәнкыйтьсез турыдан-туры чит ил (аеруча АКШ) социологиясенең теоретик нигезләрен кабул итүдә. Нәтиҗәдә, хәзер социологиянең тарихи-материалистик ысулдан баш тартмаган фәннәр белән фәнара элемтәләре өзелеп бетте дияргә мөмкин. Илебез авторлары язган дәреслекләр тарих һәм этнография белән дус түгел. Аларда Россия һәм төбәкләр тәҗрибәсеннән бигрәк, АКШ дәреслекләреннән алынган мәгълүмат урын ала. Әйтик, гаилә социологиясе темасындагы зур гаилә төшенчәсе безнең кайбер дәреслекләрдә рус, татар, мордва үрнәгендә түгел, хәтта мәктәптә, география дәресләрендә искә дә алынмаган Тробриан утрауларының җирле халкы мисалында күрсәтелә.

Хәзерге вакытта Россиянең үсеш векторы итеп постиндустриализм җәмгыяте алына. Бу технобюрократик утопияне АКШ галимнәре 1970 елларда уйлап чыгарган. Янәсе, алга киткән илләрдә сәнәгать табигый рәвештә бетүгә йөз тота, ә матди кыйммәтләр җитештерүне «мәгълүмат җитештерү» алыштыра. Чынлыкта бу халыкара корпорацияләр предприятиеләрен салымнар һәм түләнәсе хезмәт хакы түбән булган өченче дөнья илләренә чыгаруны аклау булып тора. Ә бездә бу теория деиндустриализацияне һәм чиновникларның һәм идарәчеләрнең санын арттыруны аклый булып чыга.

Тарихи булмаган авторлык позициясе аркасында студентларда социологик белемне Россия чынбарлыгында куллана белмәү тәрбияләнә. Билгеле булганча, кайбер дәреслекләрдә илнең чынбарлыгы Көнбатыш авторлары теорияләренә иллюстратив материал булып хезмәт итә һәм Россия җәмгыяте ниндидер норматив «Көнбатыш җәмгыяте»нең кимчелекле үрнәге итеп күрсәтелә. Фактларны тырышып-тырышып теориягә яраклаштыру, яки аларны чит ил дәреслекләреннән үзләштерү күпчелек мәгълүматларга игътибарны киметә. Социология дәресләре студентта кызыксыну уятмаса, ул, имтиханны тапшыруга, өйрәнгәннәреннән арынырга ашыгыр. Шуңа

күрә дәреслек авторлары алдында торган иң мөһим мәсьәлә – бәян ителгән материалны республика спецификасына якынайту. Җәмгыятьнең гомуми эволюциясен җиткерүдән тыш, студентка татар тарихының үзенчәлеген, Татарстан алдында торган мәсьәлә һәм бурычларны аңлатырга, мөһим социаль үзгәрешләрне яктыртырга кирәк. Шул сәбәпле дәреслектә татар халкы тарихының аерым сәхифәләре, республиканың иҗтимагый-сәяси тормышындагы вакыйгалар да урын алды. Китапта мәктәп программасына кертелгән Һади Такташ, Муса Җәлил, Миргазиян Юныс кебек әдипләрнең әсәрләреннән өзекләр бирелде, М. Госманов, С. Еникиев, И. Әмирхан, М. Бакиров кебек галимнәрнең гыйльми хезмәтләре дә файдаланылды.

Мәсәлән, гадәти (традицион) җәмгыятькә хас гаиләнең зур формасы иске татар морзалары нәселе материалында аңлатыла. Шул чорларда өйләнешү процедуралары, экзогамия-эндогамия кагыйдәләре һ.б. (игенче татар гаиләсе мисалында).

«Иҗтимагый тигезсезлекнең тарихи формалары» дигән бүлекчәдә иллюстратив материал итеп Казан ханлыгы һәм Алтын Урда дәүләте, татар теленең тарихи этимологиясенә караган материаллар китерелә. Мәсәлән, тигезсезлекнең патриархаль коллык кебек формасы барлыкка килүне татар телендәге «туснак» сүзенең берьюлы *бурычлы кол*ны да, *бурыч залогы*н да белдерүе бик яхшы аңлата. Ә инде классик колбиләүчелекнең нигезләре татар телендәге «улҗа» сүзенең берьюлы «трофей» һәм «әсир» мәгънәләрен колачлавыннан ачык күренә. Җирле материал шулай ук иҗтимагый утопия, индустрияләштерү, маргинальлек, гадәти җәмгыять, ыру-кабиләчелек чоры җәмгыяте, оешма патологиясе, җәмәгатьчелек фикере белән идарә итү, совет этносоциологиясе, җирле халык һ.б. махсус темаларны һәм төшенчәләрне тасвирлау өчен кирәк.

Татар телендә социология терминнарын системага салу дәреслек язганда иң катлаулы мәсьәләләрнең берсе булды. Эш шунда ки, татар телендә социология буенча дәреслекләр язу, тәрҗемә итү беркайчан системалы рәвештә алып барылмаган.

Телебез җәмгыятьнең иҗтимагый-сыйнфый структурасы һәм дәүләтчелек белән бәйле терминнарга бик бай. *Зыялылар*, *катлау*, *фирка*, *хөкүмәт*, *салым*, *нөкерләр*, *идарә* кебек сүзләр борынборыннан татар теле лексикасында үз урынын алган. 1917 елга кадәр татарларда көчле иҗтимагый философия мәктәбе булган. Моны сүзлекләрдә *җәмгыять*, *сыйныф*, *таифә*, *икътисад*, *сәясәт*, *мәдәният*, *мәнфәгать*, *гавам* кебек сүзләрнең булуы раслый. 1920 елларда марксизм классикларының политэкономия буенча хезмәтләрен тәрҗемә итү тәҗрибәсе татар телен *өстәмә кыйммәт*, *базис*, *өскорма*, *яшәеш*, *читләштерү* сүзләре белән баета.

Марксизм – XIX гасыр ахырының алдынгы философик теориясе ул. Аннан соң да иҗтимагый фәннәр зур үсеш кичерә. Тарих, икътисад фәннәре дә, философия дә алга китә. Психология һәм политология фәнни статус ала. Ләкин яңа лексиканы системага салу һәм

татар телендә әйләнешкә кертү эше тиешле дәрәҗәгә куелмаган була. Шуңа күрә социаль фәннәр лексикасы әле дә ярлы. Әйтик татарча сүзлекләрдә «поведение», «индивид», «установка», «распределение», «толпа» кебек элементар иҗтимагый фәннәр төшенчәләрен белдергән, башка мәгънәләр белән чуълланмаган төгәл лексик берәмлекләрне табып булмый.

Текстны язганда терминнар җитмәүчәнлеген мин өч алым белән каплап барырга тырыштым: (1) әйләнештә булган лексемаларга өстәмә мәгънә салып (*гавам, хасият, караш* һ.б.); (2) сүзлекләрдә «искергән» тамгалы төшенчәләрне активлаштырып (*җәмгыяви*, *җән-фәрман*, *мохтарият*, *нөкерләр*, *таифә*); (3) терминнарны башка фәннәр сүзлекләреннән үзләштереп (*гомуми тупланма*, *сынамлык*, *сынап тикшерү*). Безнең өчен аеруча төзелеш атамалары сүзлеге бик кулай чыганак булып чыкты [Шакир].

Йомгаклап әйткәндә, югары уку йортларында социология фәнен укыту 2010–2020 елларда яңадан торгынлык чорына керү сәбәпле, хәзерге вакытта әлеге фәнгә укучыларның игътибарын һәм кызыксынуын арттыру, элекке уку-укыту күләмнәрен кайтару өчен, программа һәм алымнарны камилләштерү сорала. Бу очракта социологияне һәм башка социогуманитар цикл фәннәрен, төбәк һәм милли материалга нигезләнеп, туган телдә укыту аларны үзләштерүне практика белән бәйләп тормышка ашыруның бер юлы булып тора. Без моны үзебезнең тәҗрибәдән чыгып әйтәбез.

**Әдәбият**

*Бурханова Ф.Б., Валиахметов Р.М.* Справка о подготовке социологов и преподавании социологии в Республике Башкортостан. Электрон публикация. [М., 2017] URL: https://www.ssa-rss.ru/files/File/Monitoring_sostoyaniya_SO/Informaciya%20iz%20regionov/ Respublika%20Bashkortostan.pdf (28.08.2021)

*Иванов В.В.* Социология. Укыту буенча ярдәмлек. Казан: Матбугат йорты, 2001. 76 б.

*Кильдеев М.В.* Социология фәне буенча лекцияләр: уку кулланмасы. Казан: КДАТУ, 2007. 115 б.

НА РТ (Татарстан Республикасының Милли архивы). Ф. 624. Оп. 1. № 485. Л. 17.

*Салагаев А.Л.* Кризис провинциальной вузовской социологии и перспективы развития независимых исследовательских центров // Девятые Вавиловские чтения. Сб. статей / под общ. ред. В.П. Шалаева. Йошкар-Ола: МарГТУ, 2006. С. 273–280.

*Сергеева З.Х.* Социология буенча лекцияләр курсы: Уку әсбабы. Казан: Казан дәүләт технол.ун-ты, 2001. 44 б.

Социология: учебник / Ю.Г. Волков. 4-е изд., перераб. и доп. М.: Кнорус, 2017. 320 с.

Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге: 10000 нән артык сүз / Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе; Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ; [махсус мөх-ре Ф.С. Хәкимҗанов; фәнни мөх-ре Ф.Ф. Гаффарова]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 510 б.

*Шакир Р.* Русча-татарча төзелеш атамалары сүзлеге: 18 500дән артык термин / мөх-ре Р.Г. Әхмәтьянов. Чаллы, 1992. 514 б.

ЦГАИПД РТ (Татарстан Республикасының Үзәк дәүләт тарихи-сәяси архивы). Ф. 15. Оп. 8. № 932. Л. 2.

*Мәкалә «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Кильдеев Мансур Вил улы,***
*социология фәннәре кандидаты, «Яшьләр инновацион һәм профилактик программалар республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениясенең аналитика бүлеге социологы*

УДК 371.32

*Ә.Ф. Галимҗанов*

# ТӨГӘЛ ФӘННӘРНЕ ТАТАРЧА УКЫТУ ТУРЫНДА

Рассмотрена проблема преподавания точных и естественных наук на татарском языке. Обращено особое внимание преподаванию информатики, как предмета, который обеспечивает межпредметную связь.

**Ключевые слова**: точные науки, преподавание на татарском языке, билингвизм.

The problem of teaching exact and natural sciences in the Tatar language is considered. Special attention is paid to teaching informatics as a subject that provides interdisciplinary communication.

**Keywords**: exact sciences, teaching in the Tatar language, bilingualism.

Икетелле укыту, яисә туган телдә укытуның өстенлекләре яисә зарары турындагы фикер тарихта берничә тапкыр үзгәргән. Мәсәлән, Борынгы Римда латин һәм грек телләрендә икетелле укыту булган. Урта гасырларда шулай ук католик дине хакимлек иткән илләрдә беркем дә сөйләшмәгән латин телендә укытканнар. Ләкин инде XX гасыр башында ук чит телдә, ягъни туган тел түгел телдә укытуның нәтиҗәлелеге туган телдә укытуныкына караганда түбәнрәк икәнлеге исбат ителгән булган. 1928 елда ике телдә укыту турында халыкара конференция балаларның туган телдә генә белем алуы турында рекомендация кабул итә, ә икенче тел 12 яшькә җиткәнче кертелергә тиеш була ([Bureau International de l'Éducation, 1929] мәгълүматлары буенча). Ләкин, моңа бәйсез рәвештә, милли дәүләтләр үсешендә бары рәсми телдә укытуга басым ясала. Франция, Испания, Россия һ.б. илләрдә милли азчылыкны тәшкил иткән халыкларның телләре кимсетелгән, аларны мәктәптә куллану тыелган, туган телдә сөйләшкән балаларга җәза бирелгән һәм ата-аналардан өйдә дә балалары белән рәсми телдә генә сөйләшү таләп ителгән. Әмма 1970 елларда, икътисадның постиндустриаль үсеше белән бәрәттән, җәмгыятьтә мөһим социаль үзгәрешләр дә була һәм тел процессларына игътибар арта. Күп илләрдә туган телләргә яңадан игътибар көчәя, ике телле – туган һәм рәсми телләрдә, яисә өч телле – туган, рәсми һәм бер чит телдә укыту тарала башлый.

## 1. Мәгариф һәм тел сәясәте

Мәгариф, һичшиксез, тел сәясәтенең фундаменталь өлкәләреннән берсе булып тора. Б. Спольски әйткәнчә [Spolsky ВБ 2009], «Мәгариф системасында кабул ителгән тел сәясәте – һичшиксез, телләр менеджментында иң тәэсирле көчләрнең берсе. Мәчет, чиркәү, синагога кебек дини институтлардан тыш, бу – телнең өйдә кулланылышын расларгамы, кире кагаргамы икәнен исбатларга иң зур мөмкинлек

бирүче...». Һәм бөтен дөньяда, телләрнең җәмгыятьтәге урынын үзгәртергә кирәк булса, мәгариф системасында тиешле реформа үткәрелгән. СССРда, мәсәлән, 1920 елларда дистәләрчә тел мәгариф системасына кертелгән яисә аларның функцияләре киңәйтелгән, ә 1930, 1940, һәм бигрәк тә 1958–1959 елларда аларда укыту чикләнгән.

Хәзерге вакытта татар зыялыларының һәм җитәкчелекнең шактый өлешендә, бигрәк тә өлкән буын вәкилләрендә, татар телен укыту теле буларак башлангыч классларда гына куллану, ә аннары татар телен генә татарча укыту зарурлыгы турында фикер хөкем сөрә. Бу аларның «Без русча белмичә шәһәргә килдек, шуның аркасында күп газаплар күрдек, балаларыбыз аны күрмәсен», дигән псевдоигелекле тезисына нигезләнә. Шул ук вакытта мондый фикердәге кешеләрнең хәзерге тел процессларын, нигездә, аңламауларын, аңласалар да, татар телен махсус чикләргә, һәм, ниһаять, бетерергә тырышуларын күрәбез.

Икетелле мәгариф өлкәсендә эшләүче авторлар исә, телне предмет буларак укытуның мөһимлеген генә түгел, ә мәктәптә коммуникация чарасы итеп файдалануның фундаменталь кыйммәтен ассызыклый, ә бу телне үзләштерү өчен башка – төгәл фәннәрне дә туган телдә укытуны күздә тота. Күзәтүләр шуны күрсәтә: әгәр өйдәге аралашу теле гаиләдән тыш көнкүрештә файдаланылмый, ә мәктәптә укыту теле җәмгыятьтәге доминант тел икән (хәзерге вакытта Россиядә ул – рус теле), ул чагында мәктәптәге укыту теле өйдә аралашуда да кулланыла башлый һәм беренчел аралашу телен – туган телне алыштыра. Т.Л. Маккарти, Т. Скутнаб-Кангас һәм О.Н. Магга әйткәнчә [McCarty, 2010], «бер мәктәп кенә югалу алдында торган телне коткарып кала алмый, ләкин аны берничә буын эчендә, мөстәкыйль рәвештә диярлек, бетерә ала». Мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында информатика һәм информацион технологияләр белән бәйле фәннәрне туган телдә – татарча укыту аеруча мөһим, чөнки информацион технологияләр кеше эшчәнлегенең барлык даирәләренә үтеп керде һәм компьютер белән туган телдә аралашу, бигрәк тә Интернет аша татарча аралашу туган телне саклау һәм үстерүнең мөһим шартларыннан берсенә, хәтта иң мөһименә әверелде.

## 2. Икетеллелек: классификация һәм тәҗрибәләр

Билингваль укыту турында Россиядә фундаменталь тикшеренүләр юк диярлек. Әгәр алар булса һәм классификацияләнсә, хәзерге заман мәгарифенең ассимиляциягә алып баруы күренеп торачак. Европа классификациясен файдаланыйк.

Икетелле мәгарифнең иң төпле типологиясе, безнеңчә, К. Бейкер хезмәтләрендә [Baker, 2007] китерелгән. Кыскача гына ул типологиягә карап китик.

«Билингвлар өчен бер телле мәгариф формасы», «Икетелле мәгарифнең йомшак формасы», «икетелле мәгарифнең билингвизм һәм билингваль грамоталык өчен көчле формасы» төшенчәләре бар.

Беренче типка «мейнстрим укыту» (ингл. «mainstream», «submersion») керә, ягъни доминант тел милли азчылыкны укыту өчен файдаланыла. Икенче тип формалары арасында «арадаш» программалар (ингл. «transitional») аерылып тора, аларда азчылыкка «вакытлыча туган телне файдаланырга рөхсәт ителә. Алар аз вакыт, күпчелек теленә ия булганчы, туган телдә укыйлар, һәм, ниһаять, мейнстрим укытуга күчә алалар». К. Бейкер аныклаганча ([Baker, 2007] не кара), «икетелле мәгарифнең йомшак формаларының төп максаты – милли азчылыкны ассимиляцияләү, һич кенә дә азчылык телен өйдә аралашу теле итеп саклау һәм мәдәни плюрализм түгел».

Шушы ук автор икетелле мәгарифнең дүрт көчле формасын күрсәтә: «ярдәм», «күмелү», «икеләтә күмелү», «икетелле мейнстрим укыту». «Ярдәм» методында (ингл. «maintenance», «heritage language») азчылык вәкилләре барлык уку дәвамында туган телләрендә дә, күпчелек телендә дә укыйлар. «Икеләтә күмелү» методында (шулай ук «ике юнәлеш» дип тә атала (ингл. «dual language», «two way»)) укучыларның катнаш коллективын укытуда азчылык теле дә, күпчелек теле дә файдаланыла. Азчылык теле вәкилләре күпчелек теленә «күмелә», ә күпчелек теле вәкилләре азчылык теленә «күмелә». Ике төркем дә шулай ук туган телләрендә бергә укый, шуңа күрә туган тел буенча сегрегация юк. «Күмелү» методында (ингл. «immersion») күпчелек вәкилләре азчылык телендә укый. «Икетелле мейнстрим укыту» вакытында (ингл. «mainstream bilingual») күпчелек вәкилләре чит һәм туган телләрендә белем ала. Укытуның каралган методларыннан аермалы буларак, бу очракта чит тел статусы югары һәм анда күп кенә дидактик материаллар (дәреслек, аудиовизуаль чаралар һ.б.) була.

Һәр типтагы программалар арасында да аермалар бар. Мәсәлән, күмелү методы буенча программалар яшь буенча, сәгатьләр саны буенча аерыла ала. Күмелү һәм мейнстрим укыту методларының фундаменталь аерымлыгы шунда ки, күмелү методы буенча укучылар – җәмгыятьтәге доминант тел вәкилләре һәм алар үзләренең туган тел статусы өчен кимсенү тоймыйлар һәм аны көнкүрештә актив кулланалар. Укытучылар шулай ук күпчелек телен белә, ә мейнстрим укытуда алай түгел.

Өлгерешкә килгәндә, икетелле мәгарифнең көчле формасында укучылар азчылык телен яисә чит телне аны предмет кебек кенә укучыларга караганда яхшырак беләләр. Иң мөһиме шунда ки, алар күпчелек телен һәм башка предметларны да күпчелек телендә генә укучы балалардан яхшырак үзләштерә. Европада бу статистик тикшеренүләр белән исбатланган. Безнең үз тикшеренүләребез дә шуны раслый.

Югары уку йортларында төгәл фәннәрне татарча укыту омтылышлары беркайчан да тукталмаган диярлек. Сүзлекләр һәм дәреслекләр дә басылып торган. Системалы рәвештә бу эшкә 1990 еллардан керешелде. Шуңа күрә хәзерге вакытта төгәл фәннәрне югары

уку йортларында татар телендә укыту буенча кимендә утыз еллык тәҗрибә бар дип әйтергә була. Баштарак беренче курс студентлары татарча укып киләләр иде. Шуңа күрә алар өчен татар теле танып белү һәм коммуникация чарасы да булып торды. Соңгы елларда исә, илдәге гомуми тел сәясәте аркасында, предметларны өйрәткәндә татарчага да өйрәтергә туры килә. Гомумән алганда, бу үзенең нәтиҗәләрен бирә, беренче курста татарча начаррак белсәләр дә, өченче курска инде без татарча камил белгән һәм татар телендә математика, информатика һәм физиканы укытырга сәләтле белгечләр әзерләүгә ирешәбез.

**Әдәбият**

*Baker C.* A Parents' and Teachers' Guide to Bilingualism. Clevedon: Multilingual Matters, 2007. Вып. 3. С. 34–36.

Le bilinguisme et l'éducation / Bureau International de l'Éducation. Genève, 1929. [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://fr-academic.com/dic.nsf/frwiki/249015

*McCarty T.L., Skutnabb-Kangas T., Magga O.H.* Education for Speakers of Endangered Languages // The Handbook of Educational Linguistics / ed. B. Spolsky, F.M. Hult. Oxford; Malden, MA: Wiley-Blackwell, 2010. C. 300.

*Spolsky B.* Language Management. Cambridge: Cambridge University Press, 2009. C. 90.

*Мәкалә «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Галимҗанов Әнис Фоат улы,***
*физика-математика фәннәре кандидаты,*
*Казан федераль университетының*
*функцияләр теориясе һәм якынайтулар кафедрасы доценты*

УДК 371.32

***А.Г. Гыйлемшина***

# МЕДИЦИНА УНИВЕРСИТЕТЫ СТУДЕНТЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУ

Статья рассматривает проблему формирования коммуникативных компетенций у студентов медицинского вуза на татарском языке. Разработка и систематизация медицинской терминологии, сбор анамнеза у пациентов на татарском литературном языке для будущих врачей остается актуальным вопросом на сегодняшний день.

**Ключевые слова:** татарский язык, коммуникативная культура, медицинская терминология, методика обучения, диалог.

The article examines the problem of the formation of communicative competencies among students of a medical university in the Tatar language. The development and systematization of medical terminology, the collection of anamnesis from patients in the Tatar literary language for future doctors remains an urgent issue today.

**Keywords:** Tatar language, communicative culture, medical terminology, teaching methods, dialogue.

Медицина университетында укучы студентларның татар телендә авырулар белән аралашу тәҗрибәсе бөтенләй юк диярлек. Татар теле дәресләрендә шул юнәлештә студентларның коммуникатив күнекмәләрен үстерү өлкәсендә максатчан эш алып барыла.

Соңгы елларда югары һөнәри белем бирү системасында җитди үзгәрешләр күзәтелә. Югары медицина уку йортларының медицина учреждениеләре – поликлиникалар, хастаханәләр белән элемтәләре киңәю күзәтелә. Бу медицина юнәлеше белән бәйле өстәмә белем бирүче көллиятләргә дә, махсус уку йортларына да кагыла.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: сәламәтлек саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә укыту рус телендә алып барыла. Колледжлар һәм югары уку йортларын тәмамлаучылар рус телен, рус терминологиясен яхшы беләләр, Татарстан Республикасының дәүләт телләренең берсе – татар телендә медицина терминологиясен өйрәтү бары тик бер семестр күләмендә генә каралган. Бу проблема медицина оешмасында практика узучы студентларның авырулар белән рус һәм татар телләрендәге әңгәмәсе яки сораштыруы вакытында аеруча сизелә, аларның махсус медицина терминологиясен белмәүләре күзәтелә.

Әлеге проблеманы хәл итү максатыннан һөнәри терминологияне өйрәтү юнәлешендә студентлар өчен заманча укыту һәм методик әсбаплар булдыру зарурлыгы көн тәртибенә чыкты. Газета-журнал битләрендә урын алган материалларда медицина терминнарының русча-татарча вариатларын куллану очраклары күзәтелә, ләкин алар

теге яки бу мәкалә, монография контекстында гына бирелә. Шуннан чыгып, медицина вузлары, көллиятләр студентлары, яшь табиблар өчен, әлеге терминнарны өйрәтү максатыннан, методик кулланма булдыру ихтыяҗы барлыкка килде.

Татар медицина терминологиясенә борынгы чорларда ук нигез салына башлый. Р.Р. Шәмсетдинова үзенең «Татар телендә медицина терминологиясе» дип аталган хезмәтендә татар медицина терминологиясенең үсешен түбәндәге чорларга бүлеп карый: 1) Беренче этап – X гасырдан XIX гасырның икенче яртысына кадәр; 2) икенче этап – XIX гасырның икенче яртысыннан алып 1920 елга кадәр; 3) өченче этап – 1920 елдан алып 1950 елга кадәр; 4) дүртенче этап – 1950 елдан алып 1980 еллар ахырына кадәр; 5) бишенче этап – 1990 еллар башыннан алып бүгенге көнгә кадәр [Шамсутдинова, б. 10]. Бу өлкәдә татар галиме һәм мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның роле бик зур. Ул беренче булып татар телендәге медицина терминологиясенә нигез сала. Гади халыкка аңлаешлы булмаган күп кенә гарәп-фарсы терминнарын татарчага тәрҗемә итә [Шамсутдинова, б. 7].

Татарстан Республикасында фәнни-педагогик кадрлар белән тәэмин итү ихтыяҗы арткан чорда, татар телендә дәреслекләр, уку ярдәмлекләре һәм белешмә әдәбият булдыруның объектив зарурлыгы туа. Аерым тармаклар, шул исәптән медицина буенча да терминологиянең фәнни нигезләнгән системасын эшләү бурычы куела. Шул максаттан Казан дәүләт медицина университеты укытучылары көче белән рус телле студентлар өчен «Рус-татар медицина сөйләшмәлеге» – уку әсбабы (Л.М. Мөхәррәмова, Л.И. Фидаева), «Клиник практикага әзерлек: югары һәм урта медицина уку йортларының татар телен камилләштерүче төркем студентлары өчен уку-укыту кулланмасы» (Р.М. Әмирова, В.Т. Балтаева), «Медицина терминнарының кыска рус-татар мәгънәле сүзлеге» (М.М. Миңнебаев), «Сәламәтлек саклау хезмәткәрләре өчен кыска рус-татар сүзлеге» дөнья күрә.

Югары медицина уку йортын тәмамлаучы яшь табибның коммуникатив культурасы югары дәрәҗәдә булу аның һөнәри эшчәнлек системасында үз урынын билгеләүдә зур роль уйный. Табиб эшчәнлегендә коммуникатив культура ни өчен әһәмиятле соң? Чөнки аның нигезендә врач белән пациент арасындагы диалог рәвешендә аралашу ята. Әмма, тәҗрибә киресен күрсәтә: пациентның ярты шикаяте әйтелми, еш кына табиб пациентның авыруы турында тиешле дәрәҗәдә мәгълүмат ала алмый. Татар телен гадәти сөйләм теле дәрәҗәсендә начар белү, медицина терминологиясен начар үзләштерү һәм башка факторлар яшь табибка профессиональ юнәлештә ышанычлы хәрәкәт итәргә, авыруга дөрес диагноз куярга мөмкинлек бирми.

Шуңа күрә башлангыч курсларда студент-медикларның коммуникатив культурасын формалаштыру, сөйләм күнекмәләрен булдыру аеруча актуаль, чөнки нәкъ менә шушы чорда гуманитар дисциплиналарны, шул исәптән чит тел буларак, татар телен өйрәнү процессында гомуммәдәни әзерлек алып барыла, студентларның белем даирәсе

киңәя, ә бу, үз чиратында, аларның коммуникатив күнекмәләрен үстерүгә уңай йогынты ясый.

Моннан тыш, «Авыру белән әңгәмә (Диалог с больным)» татар телендә «Дәвалау эше» югары белем бирү программасы буенча белем алучы медицина югары уку йортлары студентлары өчен төзелгән методик әсбап түбәндәге актуаль проблемаларны хәл итәргә мөмкинлек бирә: югары уку йортлары студентлары өчен татар телендә профессиональ медицина терминологиясен системалаштыру, медицина терминологиясен өйрәнүдә студентлар очрашкан кыенлыкларны ачыклау, татар әдәби телендә заманча медицина терминологиясен гамәли кулланугa өйрәтүнең оптималь программасын билгеләү, югары һөнәри белем бирү системасында татар теле дәресләренең нәтиҗәлелеген күтәрү кебек актуаль мәсьәләләрне хәл итәргә ярдәм итә.

Безнең игътибар медицина терминологиясен булдыру һәм системалаштыруга, татар телен начар белгән студентлар һәм булачак табибларга анамнез җыю вакытында дөрес диагноз кую өчен тиешле күнекмәләр булдыруга юнәлдерелгән иде.

Булачак табиб пациент белән аның туган телендә аралашырга, аңа хөрмәт белән карарга тиеш.

Югарыда санап үтелгән нигезләр күрсәткәнчә, студентларны медицина терминологиясе өлкәсендә татар әдәби теле мөмкинлекләрен дөрес файдаланырга өйрәтү методологиясен эшләү үзенең актуальлеген югалтмый. Мәсьәләне югары һөнәри белем бирү медицина учреждениесендә татар телен өйрәнә башлаучыларны укыту контекстында өйрәнгәндә, проблеманың актуальлеге тагын да көчәя.

«Авыру белән әңгәмә (Диалог с больным)» татар әдәби телендә югары белем бирү программасы буенча белем алучы медицина югары уку йортлары студентлары өчен төзелгән «Дәвалау эше» методик әсбабы студентларга төгәл диагноз кую һәм дәвалау өчен дөрес анамнез җыярга өйрәтүне төп максат итеп куя. Ул үз эченә авыру тарихы, пациент тормышы тарихы, социаль анамнез, хезмәт анамнезы, зарарлы гадәтләр, һәм башка – йөрәк-кан тамырлары авырулары, ашказаны-эчәк тракты авырулары, нерв авырулары, пульмонология авырулары, борын һәм колак авырулары кебек юнәлешләрне алачак.

Анамнез җыю диалог формасында үткәрелә – табибның пациент белән әңгәмәсе, күрсәтелгән тема буенча төп медицина терминнары (көндәлек тормышта кулланыла торган сүзләр һәм гыйбарәләр, сораулар) каралачак. Булачак уку әсбабы студентларның мөстәкыйль эше кысаларында практик күнекмәләрне үзләштерүне, шул рәвешле, академик «авыру тарихы»н язу тәҗрибәсен үзләштерүне дә үз эченә алачак.

Мәсәлән, «Ашказаны авыруы анамнезы» бүлегендә авыру тарихында (История болезни) авыруның барлыкка килүе һәм барышы тасвирланачак: «Авыруның ашказаны авырта башлый. Бер көн элек майлы, авыр ризыклар ашаган булган икән. Шуннан соң ашказаны авырта башлаган, төнлә саруы кайнаган, укшыган, коскан, күз аллары

караңгыланган, эче киткән, хәлсезлек пәйда булган» кебек тасвирламалар урын алачак.

Практикада катнашучы студентларга ярдәм өчен уку әсбабында үрнәк сораулар китереләчәк: *«Нәрсә ашадыгыз?»; «Күптән авыртамы?; «Аппетитыгыз әйбәтме?»; «Беренче өянәк кайчан булды?»; «Көненә ничә мәртәбә тәрәт итәсез?» («Көн саен тышка чыгасызмы?»); «Тәрәтегез нинди төстә, нинди куелыкта?»; «Ашказаныгыз кайчан авырта башлады?»; «Ашказаныгыз ничек авырта?»; «Авырту башка җиргә таралamы?»; «Саруыгыз кайныймы, кикерәсезме, косасыгыз киләме?»; «Эчегез өреләме?»* һ.б. сораулар урын алачак.

Зарарлы гадәтләр турындагы бүлектә булачак табибларның сөйләм осталыгын баету максатыннан түбәндәге сораулар тәкъдим ителәчәк: *«Тәмәкене ничә яшьтән тартасыз?»; «Алкогольле эчемлекләр кулланасызмы?»; «Алкогольле эчемлекләрне аена ничә тапкыр кулланасыз?»; «Көчле алкогольле эчемлекләрне яратасызмы, әллә сыра, шәраб кебек эчемлекләрне кулайрак күрәсезме?»; « Алкогольле эчемлекләр кулланганнан соң иртә белән үзегезне ничек хис итәсез?»; «Баш авырту, күңел болгану күренешләре буламы?»; «Хәлегез авыр булганда, нәрсәләр эчәсез?»; «Алкогольле эчемлекләрдән агулану очраклары булдымы?»* һ.б.

Шулай итеп, әлеге уку әсбабы студентларга барлык дисциплиналар буенча авыруны тикшерүнең практик күнекмәләрен ныгытырга, диагностика процессын системалаштырырга, өстенлек итүче симптомнарны билгеләргә, логик нәтиҗәләр ясарга ярдәм итәчәк, бу үз чиратында, авыруга дөрес диагноз куярга мөмкинлек бирәчәк.

**Әдәбият**

*Амирова Р.М., Гилемшина А.Г.* Материалы для практических занятий к курсу «Татарский язык в деятельности провизора»: учебно-методическое пособие для студентов фармацевтических факультетов высших и средних медицинских учебных заведений. Казань: КГМУ, 2017. 96 с.

*Әмирова Р.М., Балтаева В.Т.* Клиник практикага әзерлек [Электронный ресурс: югары һәм урта медицина уку йортларының татар телен камилләштерүче төркем студентлары өчен уку-укыту кулланмасы / Россия Федерациясенең сәламәтлек саклау министрлыгы, Казан дәүләт медицина ун-ты, Рус һәм татар телләре кафедрасы; Электрон.текстовые дан. (0,97 МБ). Казан: КДМУ, 2016. 103 б. Пер. изд.: Подготовка к клинической практике: учебно-методическое пособие для студентов высших и средних медицинских учебных заведений, изучающих татарский язык в продолжающих группах. Казань: КГМУ, 2016. 103 с.

*Миннебаев М.М.* Краткий русско-татарский толковый словарь медицинских терминов (с эквивалентами на английском, немецком, французском и латинском языках). Казань: Медицина. 1994. 260 с.

Русско-татарский медицинский разговорник [Текст]: учебное пособие / Мед. страховая компания «Эгида»; сост.: Л.М. Мухарямова, Л.И. Фидаева. Казань: Книжный дом, 1993. 64 с.

Русско-татарский словарь гигиенических терминов / под ред. М.М. Гимадеева. Казань: Магариф, 1999. 297 с.

Русско-татарский словарь-минимум для работников здравоохранения / сост. Р.Р. Шамсутдинова Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. 75 с.

*Фидаева Л.И.* Учим татарский язык [Электронный ресурс]: грамматический минимум и контрольно-тренировочные упражнения для студентов высш. и средних медицинских учеб. заведений, начинающих изучать татар. яз. / Казан. гос. мед. ун-т М-ва здравоохранения Рос. Федерации, каф. рус. и татар. яз.; Электрон. текстовые дан. (621 КБ). Казань: КГМУ, 2015. 40 с.

Химический русско-татарский толковый словарь / под ред. Г.Г. Хисамеева. Казань: Магариф, 2004. 344 с.

*Шамсутдинова Р.Р.* Медицинская терминология в татарском языке: автореферат дис. ... канд. филол. наук: 10.02.06. Казань, 2000. 21 с.

*Мәкалә «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Гыйлемшина Айсылу Габделҗәмил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан дәүләт медицина университетының рус һәм татар телләре кафедрасы доценты*

УДК 78:01

*Н.Ю. Әлмиева*

# В.А. МОШКОВНЫҢ ИДЕЛ-УРАЛ ТӨБӘГЕ МУЗЫКАЛЬ ТЮРКОЛОГИЯСЕНӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ

В статье освещается и анализируется новаторский для своего времени научный труд В.А. Мошкова «Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края. I. Музыка чувашских песен. 1893; II. Мелодии ногайских и оренбургских татар. 1897; III. Мелодии астраханских и оренбургских ногайцев и киргиз. 1901.», переизданный с современными комментариями и реконструкциями («Мелодии Волго-Камья, 2011»). Первый опыт объемных изданий и научного осмысления песенного фольклора тюркоязычных народов Поволжья/Приуралья, масштабный многогранный охват традиционных культур, обусловили актуальность и непреходящую научную ценность этого труда.

**Ключевые слова:** Валентин Александрович Мошков; чувашский, татарский, ногайский, казахский фольклор Астраханского края.

The article highlights and analyzes the innovative for its time scientific work of V.A. Moshkov «Materials for the characteristics of musical creativity of foreigners of the Volga-Kama region. I. The Music of Chuvash songs. 1893; II. Melodies of Nogai and Tatars in Orenburg. 1897; III. Melodies of Orenburg and Astrakhan Nogai and Kirghiz. 1901», reissued with modern commentary and reenactments («Melodies of the Volga-Kama, 2011»). The first experience of volume publications and scientific understanding of the song folklore of the Turkic peoples of the Volga-Ural region, large-scale multi-faceted coverage of traditional cultures, have caused the relevance and enduring scientific value of this work.

**Key words:** Valentin Alexandrovich Moshkov; Chuvash, Tatar, Nogai, Kazakh folklore of the Astrakhan region.

Валентин Александрович Мошков (1852–1922)[1] – рус дворяны, тумышы белән Кострома губернасыннан, Петербургның Михайловский артиллерия училищесын тәмамлаган. В.А. Мошков – башкалардан аерылып торган, әмма эшчәнлеге ахыргача өйрәнелмәгән тарихи шәхес. Профессиональ хәрби – патша армиясе офицеры, карьерасы ахырында – артиллерия подполковнигы (икенче чыганакта – генерал-лейтенант [Решетов]), хәрби хезмәтне 19 да поручик булып башлаган, 54 яшендә генерал-лейтенант дәрәҗәсендә тәмамлаган. Илебезнең берничә хәрби округында хезмәт вазифаларын үтәгән вакытта, ул Россия империясендә яшәүче төрле халыкларның җыр фольклорын язып алу һәм өйрәнү, аларның халык театрлары, этнографиясе, мифологиясе турында мәгълүматлар туплау белән дә

[1] 2017 елда РИИИның фольклор секторы, тууына 165 ел тулуга багышлап, «Научное наследие Валентина Александровича Мошкова в свете современности» дигән конференция үткәрде.

шөгыльләнгән. Экспедицияләр барышында ул туплаган әйберләрнең этнографик коллекцияләре Кунсткамерада саклана [Лаврентьева].

Аның антропологиягә, этнографиягә, музыка белеменә кагылышлы очерк һәм мәкаләләре, ул нотага төшергән халык җырлары этнологларда һәм фольклорчыларда һичшиксез зур кызыксыну уята. XX гасыр дәвамында тикшеренүчеләр әледән-әле шушы чыганакларга таяна, һәм фәнни әйләнештә ихтыяҗ булу аларның үз фәнни кыйммәтен югалтмавы турында сөйли. Валентин Александрович Мошковның тормышы һәм эшчәнлеге турындагы күзаллаулар әле формалашып кына килә.

Озак вакытлар дәвамында белешмә басмаларда аның турында өзек-өзек кенә мәгълүматлар бирелде һәм алары да төгәл түгел иде. Мәсәлән, үлеменең датасы ачык түгел иде һәм аның 1914 елда Беренче бөтендөнья сугышында һәлак булуы турындагы фаразларга ышанырга туры килде. Музыкаль белешмәлекләрдәге мәгълүмат буенча, ул якынча 1920 елда вафат булган [Бернандт.., 1974, с. 220].

Соңрак, 2011 елда мин интернет аша аның үлгән вакытын төгәл белдем: Мошковның 1922 елда Болгариядә дөньялыктан китүе һәм шунда җирләнүе турындагы мәгълүматка юлыктым. Болгариядә аның турында китап та басылып чыккан икән[1]. Шунда ук бик начар сыйфатлы фоторәсеме дә бирелгән иде, анда хәрби мундир кигән өлкән яшьтәге бик тә талчыккан бер кеше сурәтләнгән, һәм аның Валентин Александрович булуы бик мөмкин. Көтмәгәндә һәм серле рәвештә пәйда булган бу мәгълүмат В.А. Мошковның Идел буендагы төрки халыклар буенча кабаттан бастырыласы материалларын да кертеп матбугатка әзерләнүче китабында (фоторәсемнән күчереп эшләнгән фотопортреты белән) урын алды. Әлеге мәкалә нәкъ менә шушы китап турында.

В.А. Мошковның тормышы һәм фәнни эшчәнлеге хакында кайбер мәгълүматларны үз эченә алган басма чыганаклар бик аз.

Уникаль галимнең биографиясе белән РФАнең Бөек Пётр исемендәге Антропология һәм этнография музеенда (Кунсткамера) ярты гасырдан артык эшләгән галим-этнограф А.М. Решетов махсус шөгыльләнгән. Ул архив мәгълүматлары һәм махсус хәрби басмалардагы белешмәләргә таянып, В.А. Мошков хәрби карьерасының төп этапларын һәм туган көнен (20) билгели алган [Решетов].

С.А. Токаревның «История русской этнографии» китабында В.А. Мошков исеме ике тапкыр шактый тыйнак итеп кенә телгә алына. Беренчесе – Казан университеты каршындагы Тарих, археология һәм этнография җәмгыяте турында сүз барганда (1878) – бу исем өтер аша И.Н. Смирнов, В.К. Магницкий, М. Веске, Е.А. Малов, Г. Әхмәров, И.В. Яковлев, М.Е. Евсевьев, Н.Ф. Катанов һ. б. исемнәре

---

[1] Интернет-ресурста В.А. Мошков турында болай диелгән: «Генерал-лейтенант. Участвовал в Освободительной русско-турецкой войне 1877–1878 гг. В Болгарии с 1921 г.» [Гаристов, 20208, с. 56].

белән янәшә атала. Икенчесендә В.А. Мошков бары тик астөшермәдә – «Живая старина» журналының «иң эчтәлекле мәкалә» авторлары арасында [Токарев, 1966, с. 585]. Бары шул гына.

Гагауз телен ачу тюркологлар даирәсендә В.А. Мошковның фәнни казанышы булып санала. Гагауз фольклор текстлары һәм этнография буенча белешмәләр беренче тапкыр аның тарафыннан аерым китап итеп бастырыла [Мошков, 1900, 1901, 1904]. Аның гагаузларга багышланган хезмәтләрен Россия тюркологлары да таныды. Лингвистлар В.А. Мошковны Петербург тюркологлар мәктәбе вәкиле дип атыйлар. «Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов» дигән китапта аның турында түбәндәге белешмә бирелә: «Этнограф, антрополог, тарихчы... моңарчы фәнгә аз билгеле гагауз телен ачты... Балкан ярымутравы гагауз һәм төрекләре тарихы һәм этнографиясе буенча кыйммәтле тикшеренүләр авторы. Аның кайбер хезмәтләре нугайларның һәм казакъларның музыкаль иҗатына багышланган» [Биобиблиогр. словарь .., с. 219–220].

Әлбәттә, тарихчы һәм филологларның шәрехләмәләрендә күпкырлы тикшеренүченең фольклор әсәрләрен ноталары белән бергә биргән хезмәтләре тиешенчә бәяләнмәгән. Әмма этномузыка белгечләре дөньясында В.А. Мошковның хезмәтләре үз вакытын бик озак көтеп ятты. Хәзер исә игътибарны нәкъ менә ул туплаган музыкаль фольклор мирасына юнәлткән фәнни хезмәтләрнең исемлеге акрынлап барлана башлады дияргә мөмкин. В.А. Мошков рус фольклористикасының фундаменталь тарихи-теоретик күзәтүләрендә дә телгә алына [Земцовский, 1972, с. 29; Вульфиус, 1979, с. 62]. Валентин Александровичның биографиясе һәм фәнни эшчәнлеге турындагы очерклар аның XXI гасырда яңадан басылган нота материалларына кереш мәкаләләр сыйфатында дөнья күрә. Аларда галимнең музыкаль-фольклор эшчәнлеге җентекләбрәк карала [Фольклористическое наследие В.А. Мошкова, 2003, с. 5–21; Мошков, 2011, с. 5–23].

Чабаксар тикшеренүчесе М.Г. Кондратьев В.А. Мошков турындагы биографик очеркны берничә вариантта язган [Родителева, 2003, с. 142–149; Кондратьев, 2011, с. 149–162]. Аларның берсе «Мелодии Волго-Камья» дигән яңа басмада кереш мәкалә итеп бирелгән, анда автор В.А. Мошковның биографиясен дә, фәнни – шул исәптән, музыкаль-фольклористик эшчәнлеген дә яктырта, шулай ук хезмәтләренең бүгенге көндә иң тулы саналган библиографиясен дә [Мошков, 2011, с. 355–358] бастыра. Бу мәкалә аша уникаль галимнең фәнни кызыксыну өлкәләре бик күп булуы турында белергә мөмкин, аларны тулаем антропологик дип атап була. Ул кешенең рухи һәм матди культура күренешләрен генә түгел, ә аның тормыш һәм иҗат шартларын да, хәтта кешелекнең килеп чыгышы һәм тарихта яшәү юллары турындагы трактатларны да колачлый[1]. Бу библиографик

[1] Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, бу трактатлар аерым мәдәниятләрнең аның тарафыннан эшләнгән фәнни тасвирламаларыннан башка яссылыкта тора, кешенең килеп чыгышы темасына ниндидер эссе буларак, алар белән бер рәттә була алмый.

исемлекнең өчтән берен (35 публикация) музыка белеме буенча хезмәтләр тәшкил итә.

В.А. Мошковның эшчәнлеге белән кызыксыну Европада XIX гасырда ук билгеләнгән этник мәдәниятләргә, этник музыкага игътибар арткач башлана. Россиядә бу тенденция «Могучая кучка» төркеменә кергән рус композиторларының рус халык җырлары җыентыкларын төзү, аларның үз иҗатларында гамәлгә ашыру өстендә бәяләп бетергесез хезмәт куюында, Кавказ, Кырым музыкаль жанрларына һәм яңгырашына таянып, композиторлар иҗатында рус Шәркы образларын гәүдәләндерү тәҗрибәсендә ачык чагыла. Шул ук илле ел эчендә С.Г. Рыбаковның да (1867–1921) Уралда һәм Үзәк Азиядә бөтенләй таныш булмаган мәдәниятләрне өйрәнүгә юнәлдерелгән (фольклор) җыю эше һәм фәнни эшчәнлек алып баруын искә төшерик. Чынлыкта В.А. Мошковның һәм С.Г. Рыбаковның яшәгән еллары да, Идел һәм Урал буе төркиләренең җыр фольклорын язып алу һәм бастыру даталары да туры килә (1889 елдан алып 1905 елга кадәрге чор).

В.А. Мошков җыр фольклоры өлкәсендәге күзәтүләрен рус һәм башка славян халыкларыныкын өйрәнүдән башлый. Аннан соң аның фәнни кызыксынулары төрки мәдәниятләргә күчә, һәм ул рус, белорус, поляк, гагауз, татар, нугай, кыргыз, казакъ, чуваш халыкларының җыр традицияләре турында яза[1]. Хәтта шул заман тенденцияләрен исәпкә алсак, В.А.Мошковның туган халкының фольклорыннан тыш, башка күпсанлы халыкларныкы белән дә шөгыльләнергә сәләтле булуына гаҗәпләнмичә мөмкин түгел. Ул башка җыр культураларына үтеп керә, чит көйләрнең ноталарын терки, ә текстларын латин хәрефләре белән яза. Болар барысы да, мөгаен, аның менә дигән музыкаль сәләткә ия булуын гына түгел, ә музыкага шәхсән тартылуын да раслый. Шундый кызыксынучан иҗади эшчәнлек нәтиҗәсе буларак, Россиядә яшәүче төрле халыкларның традицион җырлары тупланган җыентыклар һәм киңәйтелгән этнографик очерклар басылып чыккан. В.А. Мошков Петербургта «Живая старина», «Нива», «Баян» кебек махсуслаштырылган журналларда; Мәскәү университеты каршында чыгып килгән «Этнографическое обозрение» журналында, «Варшавские губернские ведомости» газетасында, ниһаять, Казан университеты каршындагы «Археология, Тарих һәм Этнография җәмгыяте хәбәрләре»ндә басыла. Бу – укучылар өчен өр-яңа материаллар була һәм аларга тормышның бөтенләй таныш булмаган өлкәсен ача. Бу – *вертеп* халык театры, халык уеннары һәм сынамышларның тасвирламалары. Ул һәрвакыт фәнни тасвирлау предметын антропологик яктан тулырак итеп колачларга омтыла. Ул халык җырларының (мәсәлән, Олонецкий губернасында) нинди интонация белән җырлануы турында яза һәм шунда ук үзе экспедициядә язып алган йола җырларын нотага төшереп бирә. Аның рус халкының трубасы һәм чуваш

[1] В.А. Мошковның Урта Иделдә яшәгән фин-угорларның да (мари, удмуртлар) фольклорын язып алганлыгы билгеле, әмма әлеге язмалар (белорусларныкы белән бергә) югалган [Иванов-Ехвет, 1987].

гөсләләре турындагы язмалары әлеге уен коралларының рәсемнәре белән дә баетыла. В.А. Мошков сөйләмә традиция музыкасы һәм этнография өлкәсендә махсуслашып, Рус География җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы санала. Соңыннан Казан университеты каршындагы «Археология, Тарих һәм Этнография җәмгыяте хәбәрләре»ндә [Мошков, 1897, т. 14, вып. 3, с. 265–291], басылган «Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края. II. Мелодии ногайских и оренбургских татар [Песни и комментарии]» дигән хезмәтендә ул үзен «Җәмгыятьнең хакыйкый әгъзасы» дип күрсәтә.

Әлеге хезмәт («Материалы для характеристики...») – аның фәнни мирасында аерым бер күренеш. Нәтиҗәдә Үзәк Россиянең төрки телле халыклары мәдәниятләре фәнни киңлеккә чыга.

Казан университеты каршындагы «Археология, Тарих һәм Этнография җәмгыяте хәбәрләре»ндә аерым «дәфтәрләр» булып, әмма «Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края» дигән бердәм баш астында чыккан серияләр турында сүз бара (I. Музыка чувашских песен; II. Мелодии ногайских и оренбургских татар; III. Мелодии астраханских и оренбургских ногайцев и киргиз; «Этнографические данные о ногайских и оренбургских татарах» очеркы тагын аерым гына да нәшер ителә) [Мошков, 1893; Мошков, 1897; Мошков, 1901]. Бу язмаларның, барыннан да элек, рим цифрлары белән номерлануы аларның В.А. Мошков тарафыннан серия буларак эшләнүен күрсәтә, шулай ук әлеге материаллар барысы да Идел-Кама бассейнына карый, төзүче моны аларның исемнәрендә дә ассызыклый. Күренеп тора, В.А. Мошков аларны Урта Идел буе (чувашлар һәм татар-мишәрләр) һәм Түбән Идел буе (Әстерхан татарлары, Әстерхан һәм Урал аръягы нугайлары, нугай татарлары, Әстерхан крае казакълары) төркиләрен колачлаган бердәм хезмәт итеп күз алдына китергән.

Аерым басмалар барысы бергә «комплект» барлыкка китерә. Аны барыбер дә өлешчә генә ареаль тикшеренү дип атарга мөмкин. Нота бүлекләренә багышланган тикшеренүләрнең дә тышкы күренеше бердәй түгел. Мошков тарафыннан формалаштырылган өч бүлекнең һәрберсе алдыннан этнографик очерк та бирелмәгән (ул бары тик Нугай һәм Оренбург татарлары турындагы II басма алдыннан гына бар), яисә көй-ритмика үзенчәлекләрен анализлау, шулай ук нинди дә булса музыкаль инструментның рәсеме һәм тасвирламасы да юк (соңгысы I басмада гына бар). III басмада (нугайлар, кыргызлар) тегесе дә, бусы да юк, бары тик ике астөшермәдә генә җыр текстларының аерым моментлары аныклана яки аларның килеп чыгышы аңлатыла. Аның каравы, III басма алдыннан урнаштырылган «Редакциядән» дип исемләнгән керештә мөхәррирләр тарафыннан В.А. Мошков, В.В. Радлов һәм С.Г. Рыбаков язмаларындагы төрки текстларга лингвистик чагыштырулар үткәрелә. Әмма I һәм II басмага кергән материалларга мондый чагыштыру бирелми. Ниһаять, барлык этнофорларның

исемнәре һәм фамилияләре бары тик I (чуваш) бүлектә генә күрсәтелгән. В.А. Мошков II басманың астөшермәсендә җырчы татарның туган урынын күрсәтә, әмма исемен атамый. Һичшиксез, югарыда санап үтелгән алымнар барлык этнофорларга карата һәм хезмәтнең барлык бүлекләрендә дә файдаланылса, җыр традицияләренең гаҗәеп бай картинасын тудырыр иде, аны бердәм, саллы һәм сыйфатлы итәр иде. Аларның һәрберсе бүгенге көнгә кадәр әһәмиятен югалтмый һәм һаман актуаль.

Шулай итеп, безнең алдыбыздаербөтен фәнни хезмәт. Үз заманы өчен новаторлык үрнәге булган әлеге хезмәтнең үзенчәлекләрен тикшергәндә, без иң элек аның төрки телле халыкларның (төрки текстларны да үз эченә алган) шактый күләмле ноталар җыентыгы булуын билгеләп үтәбез. В.А. Мошков текстларны латинча язуда биргән. I басма ахырындагы соңгы астөшермәдә редакция исеменнән болай дип язылган: «Редакция приносит В.А. Мошкову сердечнейшую благодарность за доставление ей такого ценного и редкого этнографического материала, как песни и мелодии татар Волжско-Камского края». Әмма каширләр өчен бу материаллар шулкадәр яңа һәм чит була ки, «Мелодии астраханских и оренбургских ногайцев и киргиз» дип аталган III басма алдыннан куелган «От редакции Известий ОАИЭ» язмасында, В.А. Мошковны бик нык ихтирам иткән нәүбәттә дә, нәзакәтле итеп кенә күрсәтмә бирелә: «Было бы крайне желательно, чтобы со временем тексты и мелодии В.А. Мошкова кем-нибудь на месте были тщательно проверены и изданы вполне научно, с соблюдением всех фонетических и музыкальных тонкостей, тем более что до сих пор астраханские и оренбургские тексты и мелодии в печати почти никогда не появлялись […]» [Мошков, 1901, т. 17, вып. 1, с. 5]. Шуңа да карамастан, алар басылып чыга, чөнки социум Россия империясе халыкларын өйрәнүгә ихтыяҗ кичерә. В.А. Мошков үзе дә чуваш язмаларын түбәндәге искәрмә белән бастыруны кирәк дип таба: «Само собой разумеется, что изданием настоящего выпуска моих материалов я не исчерпал и тысячной доли того, что заключает в себе поучительного для науки народная музыка чуваш, а потому я смотрю на свой труд только как на почин в деле изучения этой музыки, за которым желательно было бы видеть в печати ряд новых исследований того же предмета, – более обстоятельных, чем мое, а главное – проведенных людьми, более меня компетентными в знании чувашской жизни, чувашского языка и вообще духа чувашского народа. Желательно, чтобы изучение чувашской музыки было начато на месте знатоками чувашского народа из местных жителей. А пока, в ожидании таких изучений, было бы весьма полезно, если бы знатоки чувашской этнографии теперь уже указали и исправили невольные и неизбежные ошибки моего настоящего труда» [Мошков, 1901, с. 23].

Бу абзацта бәян ителгән позицияләрне чуваш фольклорына аерым мөнәсәбәт итеп кенә кабул итәргә ярамый. Бу – үзе өйрәнә торган теләсә кайсы мәдәниятккә карата В.А. Мошковның шөбһәсез кредосы.



Матеріалы для характеристики музыкальнаго творчества инородцевъ Волжско-Камскаго края.

II. Мелодіи ногайскихъ и оренбургскихъ татаръ [1].

№ 1 [2].

mm. ♩= 92.

Ба-ды-јан сін-тім јо-ру-ҕан јо-луң-ҕ'ай,
Чіш бі-ліҥ-ді, кі-рә-јім коі-нуң-ҕ'ай,

јо-ру-ҕан јо-луң-ҕ'ай. Ай ҕай
кі-рә-јім коі-нуң-ҕ'ай. Ҹә-нім

[1] Введеніе къ этой статьѣ см. въ XII т. «Извѣстій», на стр. 1—67. Въ редакцію «Извѣстій» В. А. Мошковымъ доставлено всего 53 мелодіи, которыя, по мѣрѣ провѣрки, и будутъ издаваться въ свѣтъ. Въ настоящей статьѣ помѣщаются лишь тѣ изъ вышеупомянутыхъ 53 мелодій, которыя уже провѣрены. Статья эта (именно текстъ) провѣрена членами Общества С. М. Матвѣевымъ и Н. Ѳ. Катановымъ. *Ред.*

[2] Эта мелодія въ принадлежащемъ Обществу рукописномъ собраніи В. А. Мошкова значится подъ № 13, въ числѣ пѣсенъ ногайцевъ кундровскихъ, Красноярск. у., Астрахан. губ. *Ред.*

1*



Пѣсни Астраханскихъ ногайцевъ.

А) Мѣщанъ города Астрахани.

№ 1.

mm ♩= 69.

І-ран-ба-һын да-мі-ус-тем Са-ба је-лі ті-кі-мыс-тым Јі-рө-кем баһ-ра-мы ӱз-дем А-ја ҹә-ным са-ны уј-лап.

| | |
|---|---|
| Іранбаһын даміустем | . . . . . . . . } По пер- |
| Сабајелі тікімыстым | . . . . . . . . } сидски. |
| Јірөкем баһрамы ӱздем | Оторвалъ печень отъ сердца своего, |
| Аја ҹәным саны ујлап | Думавши о тебѣ, о милая! |
| — | — |
| Кашын кара карамыштыр | Брови твои черныя чернѣются |
| Дішін інҗӱ дезелмыштыр | Зубы твои подобно жемчугу нанизанному! |

1**

В.А. Мошковның «Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края» китабының (II чыгарылыш) бер бите

В.А. Мошковның «Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края» китабының (III чыгарылыш) бер бите

Чуваш һәм татар фольклорын өйрәнүчеләр бу хезмәтне, үз фәне тарихының бер этабы буларак, әлбәттә игътибарсыз калдырмадылар.

Чуваш җырын җыю тарихына күзәтү ясап һәм А.Ф. Риттих хезмәтендәге чуваш җырларының текстсыз нота язмаларын искә алып, чуваш тикшеренүчесе С.М. Максимов «чуваш халык җырларын һәм музыкасын» җыю һәм өйрәнү нәкъ менә В.А. Мошков эшчәнлегеннән башланды дип саный [Максимов, с. 12–13]. Аның «Материаллар...»ының чуваш өлешен кыскача анализлап, ул чуваш көйләренең (язмаларны уңышлы дип булмаса да [Максимов, с. 13]), ритмик үзенчәлекләрен кабул итүдә җыючының үтә нык сизгер булуын билгеләп үтә [Максимов, с. 33–34]; Мошков яздырган җырларны (мөгаен, концерт вариантын) чуваш халкы белми, дигән сәер нәтиҗәгә килә; ниһаять, Мошков теркәгән җыр текстларында төгәлсезлекләр булуын ассызыклый. Чуваш бүлегенең органологик өлеше (Мошков анда чувашларның шлемсыман гөсләләре турында яза) С.М. Максимовның күзәтүендә берничек тә бәяләнми. Ләкин чуваш фольклорчысы Мошков язмаларының чуваш фольклор фәне өчен әһәмиятен төшенеп, хөрмәт белән бәяли: «В лице Мошкова русская наука положила начало изучению чувашской музыки» [Максимов, с. 13]. Алга таба укыйбыз: «Записи Мошкова являются единственной работой русских музыкантов-этнографов в части собирания материалов чувашской музыки в дооктябрьский период. Надо при этом учесть то

обстоятельство, что свою работу Мошков провел без знания языка чуваш и вдали от чувашской деревни, воспринимая картины музыкального быта чуваш лишь по рассказам тех восьми солдат, которые были исполнителями записанных им песен и образцов инструментальной музыки. В ином случае Мошков мог бы дать еще более ценный материал по чувашской музыке» [Максимов, с. 14].

Татар фольклористикасында В.А. Мошковның «Материаллар...»ы шулай ук зур ихтирам белән телгә алынган, әмма бу хезмәт материалны язып алуда әллә ни уңышлы тәҗрибә буларак бәяләнми. М.Н. Нигъмәтҗанов болай дип яза: «В работе В. Мошкова около 50 образцов народных татарских песен. Многие из них, сохранившиеся до сегодняшнего дня, являются ценным материалом для современного исследователя. Однако протяжные песни со сложной орнаментикой записаны упрощенно, и по ним трудно восстановить подлинное звучание песни» [Нигмедзянов, с. 6]. Хезмәтнең этнографиягә, музыкага багышланган өлеше бу очракта берничек тә бәяләнмәгән. Нәтиҗәдә В.А. Мошков тарафыннан җыелган, нотага төшерелгән һәм төзеп тупланган сөйләмә традициягә ия татар музыкасы әсәрләре музыкаль-аналитикларның да, башкаручыларның да игътибарын җәлеп итми. Чынлыкта исә алар «күзгә күренми». Чынбарлыкта булсалар да, алар күләгәдә кала.

Бүген «Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края» хезмәте – В.А. Мошковның музыкаль тюркологиягә зур өлеш керткән җитлеккән күләмле язмасы. Үз заманы өчен новаторлык үрнәге булган бу хезмәттә оригинал телләрдәге текстлар белән нотировкалар гына тәкъдим ителеп калмый. Анда без этномузыкологик һәм этнологик язмаларны һәм күзәтүләрне күрәбез, ә алар инде фәнни тикшерену тәҗрибәсе булып тора.

Идел буенда яшәүче төрки халыкларның җырларын һәм алар турындагы этнографик мәгълүматларны В.А. Мошков Варшава хәрби округы солдатлары арасында туплаган. Автор чуваш һәм татар материалларын тәкъдим итәр алдыннан иң элек этнопсихологик темага кагыла: патриархаль авыл общинасы вәкилләренең чит телле һәм чит мәдәни тирәлектә җайлашуы турында яза. Рус солдатларының чуваш җырларын «ихлас күңелдән һәм ихтыярсыз» кабул итмәүләрен тасвирлап һәм моның сәбәбен төшенергә тырышып, ул бу хәлне башка халыклардагы вазгыять белән чагыштырып аңлата: «...неудержимо смеялись китайцы, услышав впервые европейскую музыку, построенную на иной гамме, чем китайская. Поэтому солдаты из наших восточных инородцев не собираются для пения больше чем по два, по три человека и выбирают для этого самые уединенные и укромные места»[1]: [Мошков, 1901, с. 2]. Ягъни армиядәге үзара мөнәсәбәтләр темасыннан В.А. Мошковта традицион патриархаль формация кешесенең чит төбәк традициясе музыкасын кабул итүе темасы килеп

[1] Чыганакның орфографиясе сакланган.

чыга. Бу фикерне дәвам итеп, шунысын да өстәргә кирәк: күрәсең, хикмәт биредә башка солдатларның чуваш җырларының пентатоник ладлы нигезен кабул итмәвендә генә түгел, бәлки бу җырларның формулалы лад-ритмикага корылган табигатендә дә. «Совершенно иначе относится русский солдатик к пению западных инородцев: молдаван, эстонцев и латышей» [Мошков, 1901, с. 2], – дип дәвам итә Мошков. Алар, мөгаен, гомумевропа формаларына якын җырларны башкарган. Шуңа күрә бу җырларга мөнәсәбәт тә башка булган.

Хезмәтне күбрәк укыган саен, башкалардан аерылып торган бу затның кеше факторына зур әһәмият бирүе ачыграк күренә бара. Очеркның башыннан ук В.А.Мошков чувашларның музыкаль гореф-гадәтләрен антропологик якын килеп тасвирлый, аның рәсемнәре терелеге белән шаккатыра. Ул чувашларның музыка уен коралы «ясау әмәлен табулары» һәм «ял иткәндә шуңарда уйнаулары» турында яратып яза. В.А. Мошков аермачык эмпатия белән Кешене хиссиятле итеп тасвирлый («Чувашлар – иң музыкаль һәм музыканы яратучы халык»), информантларның сөйләмен («Үз җырларыңны ничек белмисең ди инде!») китерә, һәм шуңа күрә текстны укыганда, аларның да катнашуын тоясың.

Чуваш җырларын традицион башкару В.А. Мошков тикшеренүләренең һәрвакыт игътибар үзәгендә, һәм ул кешеләрдән сорашып, чувашларның хор белән җырлавын белә, шул ук юл белән башкаручы коллективларның төрле типларын билгеләүче терминнарны ачыклый һәм язып бара. Бу текстны яңадан бастырганда, М.Г. Кондратьев (терминлы абзацка шәрехләмәләрендә) Иделнең югары һәм түбән агымнарында яшәүче чувашларда (верховые и низовые чуваши) хор төшенчәләрен бүлеп караган өчен авторны тәнкыйтьли [Мошков, 2011, с. 44, комм. 6], шул ук вакытта бу этнографик төркемнәрдә бер үк терминнарның кулланылу-кулланылмавы белән кызыксынмый. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, В.А. Мошков, күрәсең, терминнарны да (өстәвенә, тәүге тапкыр ишеткәннәрен ничек ишетсә – шулай), һәм төрле урында яшәгән чувашлардан алган мәгълүматларны да язып барган, әмма ул моны мәдәниятнең гомуми картинасын күз алдына китерми генә, экзо-тикшеренүче буларак, ничек әйтсәләр, шулай теркәгән. Әмма ансамбль белән җырлауның төрләрен санап чыгуы белән җырлауның шартларын күрсәтә һәм хәтта картиналарын да сурәтли. Алар М.Г. Кондратьев чуваш терминнарының тәрҗемәләренә төгәллек керткән вакытта ачыла: *маярибэ* (*майрипе*)[1] – «хатыны белән», «гаиләдә, гаилә ансамбле белән»; *ошканибэ* (*ушкăнĕпе*) – барысы бергә, ягъни төркем белән; *пуһанзаларна* (*пухăнса ларнă*) – «утыру [мәсәлән, кич утыру], бергә җыелып утыру».

Шундый ук (экзо-тикшеренү) сәбәпләр В.А. Мошков китергән башка этник терминнарның язылыш характерын да билгеләргә

[1] Беренче чуваш термины В.А. Мошков язганча бирелгән, икенчесе (җәяләр эчендәгесе) – язылышына М.Г. Кондратьев тарафыннан аныклык кертелгән термин, куштырнаклар эчендә – шуның тәрҗемәсе.

мөмкин (мәсәлән, М.Г. Кондратьев шәрехләмәсендә В.А. Мошков тарафыннан бирелгән марича *вик* терминының тәрҗемәсе (ул, янәсе, сүзсез җырны аңлата) тәнкыйтьләнә. М.Г. Кондратьев фикеренчә, мари сүзе *вик* көйне генә белдерә. Монда хикмәт этнофорның – җыючы соравын, ә җыючының – аның җавабы ни дәрәҗәдә аңлавында).

В.А. Мошков барлык яңгыраш үзенчәлекләре арасыннан чуваш ритмикасының ике иҗекле ямб фигураларын аерып чыгара (аның фикеренчә, чуваш җырлары русларныкыннан шуның белән аерыла да). Хәер, аның бу фигурада басымның беренче өлешкә төшүе турындагы ялгыш фикерен С.М. Максимов тәнкыйтьли.

Икенче үзгә сыйфатны – чуваш җырларының ладлы пентатоникага корылуны – В.А. Мошков шулай ук игътибарсыз калдырмый. А.С. Фаминцын һәм П.П. Сокальскийның заманча лад теорияләрен искә алып, ул борынгы кешелек дөньясының аны диатоникага кадәр киңәйтүнең акустик сәбәпләргә бәйле юлларын «билгеләү» мөмкинлеге; чуваш җырларында пентатониканың ни рәвешле җәелеп китүе, җырчыларның «кардәш кытай гаммаларын яки аларның кисәкләрен бер үк көйдә бергә үрү» сәләте турында фикер йөртергә батырчылык итә. [Мошков, 1894, т. 17, вып. 1, с. 10]. Соңгы цитата аның аналитик ишетү сәләтенә ия булуын дәлилли.

Мәкаләнең чуваш инструменталь традициясенә багышланган соңгы өлеше аеруча яхшы язылган. В.А. Мошков, ишеткән буенча, аларның этник исемнәрен шактый төгәл язып алырга тырышкан, шул ук вакытта рус терминын да биргән. Бу – укучыга инструмент тибын аңларга мөмкинлек бирә. Бары тик гөсләләргә генә анык тасвирлама бирелә. В.А. Мошков үзе аңлатканча, аның информантларының берсе үзе ясаган уен коралларында уйнаучы гөсләче оста булып чыга. Галим, җыючы буларак, инструмент турында җентекләп сорашу гына түгел, гөсләдә уйнаганны ишетү мөмкинлеге дә ала. В.А. Мошков гөсләнең төзелешен, кыллары һәм корпусы нинди материалдан эшләнүен (состав өлешләрдәге агач җепселләренең юнәлешенә кадәр), бөтен деталь конструкциясен һәм хәтта (астөшермәдә) эшләү өчен файдаланылган агач остасы коралларын һ. б. тасвирлый. Әлбәттә, гөсләләрнең уйнагандагы торышы һәм ике куллап уйнау ысулы натурадан алып тасвирланган. Шунда ук ике юлда гөсләдә уйналган халык көйләренең ике кул өчен дә партияләре белән ноталары китерелгән (ә нота корпусында, мәкаләдән аермалы буларак, ул барлык инструменталь көйләрне бер юлда гына биргән). Гөсләләрнең өч планда бирелгән график рәсемнәре әлеге уен коралы турындагы кечкенә генә этюдны бик яхшы тулыландыра. Бу очракта В.А. Мошков чын этноорганолог буларак чыгыш ясый. Әмма чуваш музыкантларының һөнәри статусы мәсьәләсен автор репликаларыннан чыгып кына ачыклап булмый.

Чуваш гөсләләрен ясаучы һәм аларда уйнаучы останың үзе белән аралашып, В.А. Мошков чуваш традицион инструментларының тулы исемлеген китерә. Аның шәрехләмәләрендә кайвакыт мәгълүматның

житенкерәмәве дә сизелә. Бердән, ул, чуваш инструментлары Идел буе һәм дөнья халыклары инструментларына типологик яктан кардәш булсалар да, тагын кемдәдер мондый күләмдә инструментлар табылуына шикләнә. Икенчедән, ул барлык чуваш инструментлары да русларныкыннан килеп чыккан, яисә чувашлар $4^3$+3 шигырь формуласын руслардан алмаганнармы дип, фактларны руссоцентристик рухта күзаллавын күрсәтә (1 нче кушымтаны карагыз).

Үзе исән чакта дөнья күргән басмада В.А. Мошков чуваш җырларының жанрларын һәр нотировкада түгел, ә исеме аша билгели. Чуваш галимнәренең җырларны жанрлар буенча идентификацияләве нәтиҗәсендә (бу турыда түбәндәрәк карагыз), 2011 елгы яңа басмада без В.А. Мошковның чуваш көйләре җыентыгында бу халыкның күпчелек традицион жанр үрнәкләре бирелүен зур канәгатьләнү хисе белән раслый алабыз. Болар – әйлән-бәйлән, туй (гомуми җырлар, кияү дусларының җырлары, кәләш дус кызларының җырлары һәм хәтта кәләш такмаклары), кунак-табын, рекрут, бишек, яшьләрнең шаян җырлары, сүзсез җырлар (70 язма берәмлек, шулай ук 5 инструменталь көй). Шул ук вакытта С.М. Максимов чуваш ритмнарының В.А. Мошков тарафыннан эшләнгән тасвирламалары камил түгел, дип тәнкыйтьләсә дә, шуны билгеләп үтәргә кирәк: чит җыр культурасы белән беренче очрашу өчен аның язмалары һәм шәрехләмәләре җитәрлек дәрәҗәдә адекват.

Үзенең «По поводу юбилея Оскара Кольберга» дигән һәм поляк мәдәният эшлеклесенең җыю һәм фәнни эшчәнлегенә 50 ел тулу уңаеннан язылган мәкаләсендә В.А. Мошков аның экспедиция сәфәрләрендә традицион мәдәниятне масштаблы колачлавын (бәйрәмнәр, гореф-гадәт һәм йолаларны тасвирлау, милли кием рәсемнәре, җыр нотировкалары) югары бәяли, шунда ук, үкенеч хисе белән, Россиядә мондый этнографик кызыксынуның әле формалашып кына килүен билгеләп үтә. Үзе дә нәкъ менә шушы тарихи фәнни процессның бер өлешен тәшкил итеп, һәм «Когда-то будет у нас что-нибудь подобное?» [Мошков, 1889. № 21, с. 171] дигән мәкаләсен язып, безнең ватандашыбыз акрынлап үзенең кумирына якыная, һәм бу – бәян ителгән хезмәтнең «Мелодии ногайских и оренбургских татар. Введение» дип аталган II басмасында чынга аша.

Сериянең бу кисәге – ике өлештән торган зур мәкалә белән ачылган бердәнбер бүлек. Әлеге күләмле мәкаләнең беренче өлешендә автор ике мәсьәләне яктыртуны кирәк саный. Беренчесе – үзенең тел һәм мәдәни мохитеннән читкә чыккан солдатның – «Шәрык кешесе»-нең психологик статусы темасы. Икенчесе – Россия халыкларының фольклор һәм этнографик материалын тиз арада җыю мәсьәләсе.

Мәкаләнең калган өлешен Әстерхан нугайларының традицион тормышы турында төрле-төрле этнографик мәгълүматлар тәшкил итә.

Күчмә экспедицияләр тәҗрибәсенә ия җыючы буларак, В.А. Мошков информант-этнофорлар сыйфатында Варшава хәрби округы солдатлары чыгыш ясаган үзгә шартларда фольклор

материалын туплауның үзенчәлеген аңлата. Алынган материалларның дөреслеген раслау/дәлилләү өчен, бу очеркның беренче битләрендә В.А. Мошков әлеге мәгълүматлар язып алынган кешеләр турында (чуваш материаллары кебек үк) үпкәләтмичә хәбәр итәргә кирәк дип саный. Бу очракта ул җырлар һәм этнографик материаллар туплау белән дә кызыксынучы этнопсихолог буларак чыгыш ясый. Алдагы зур өзек фольклор җыючы Мошковның «чит ил солдатлары»на эмоциональ мөнәсәбәтен күрсәтә һәм информантлар белән аралашуда аның кеше факторын өстен куюы әлеге мөнәсәбәтләргә ихласлык өстәвенә, димәк, язмаларның дөреслегенә укучыны да ышандыра. Мошков аутентиклык проблемасын тирәнтен аңлый. Алай гына да түгел: әлеге сүзләр һәм аннан соңгы ике бит – фольклорчы-кыр тикшеренүчеләре өчен практик кулланма булып тора, ул фольклор җыю эшенең никадәр кешелекле булуын һәм В.А. Мошковның үз шәхесендә (аталарча) эмпатиянең ни дәрәҗәдә көчле чагылыш табуын күрсәтә: «[…] певцы мои без всякого принуждения с моей стороны, лишь видя во мне человека, серьезно интересующегося их жизнью, в разговорах со мною о песнях, с величайшей охотой передавали мне различные подробности и эпизоды из своей домашней жизни. Делали они это с каким-то особенным восторгом и наслаждением, которые вполне понятны, если поставить себя в положение несчастного полудикаря инородца, оторванного силою судьбы от всего дорогого его сердцу и перенесенного за тысячи верст в совершенно чуждую ему обстановку, среди чуждых, не понятных ему и не понимающих его людей. Если прибавить к этому суровый режим военной службы, пред лицом которого солдат только номер, только один из многочисленных атомов сложной организации, то станет понятно, как дорого для такого атома всякое теплое к нему обращенное слово, как ценит он внимание, с которым выслушиваются его воспоминания о дорогой родине, не интересные ни для кого из его окружающих. Какой радостью светятся глаза такого дикаря в эти дорогие и редкие для него минуты, с какой готовностью он отвечает вашему любопытству, как он увлекается своими рассказами, как забывает в это время все его окружающее, – все это надо видеть, чтобы понять и перечувствовать. Если вы человек с сердцем, о в такие минуты у вас просто, как говорится, рука не поднимется оборвать человека, облить его холодной водой, прервать на полуслове […]» [Мошков, 1894, с. 265–266][1].

Үзе җыйган материалның фәнни кыйммәтен билгеләп, В.А. Мошков, форсаттан файдаланып калырга ашыга: тарих барышына үткен акыл белән бәя биреп, фольклорның юкка чыгу процессы уңаеннан ихлас борчылуын белдерә («нельзя же сидеть сложа руки и ждать, когда сами собой народятся между нами Морганы и Миклухи-Маклаи. Нельзя, потому что время не ждет, а вместе с ним не ждет и

[1] Чыганакның орфографиясе сакланган.

народная жизнь, которая идет своим чередом, бросая старые формы жизни и переходя к новым [...]» [Мошков, 1897, с. 270]).

Татар һәм нугай көйләренең тулы комплектының Кереш өлешендә В.А. Мошков нугай һәм Оренбург татарларының традицион тормышы турында киңәйтелгән, бай мәгълүматлы этнографик очеркын урнаштыра. Ул бүген дә этнологлар өчен үзенең фәнни кыйммәтен югалтмады. Традицион мәдәният терминнары белән чуарланган бу очеркта халыкның таралып урнашуы, торагы, кием-салымы, ризыгы, һөнәрчелеге, диндарлыгы, уеннары, легендалары һәм мифлары турында тулы мәгълүматлар китерелгән. Һәм бу бүлекчәләрнең һәрберсендә авторның тере каләме белән традицион тормыш картиналары торгызыла.

Идел һәм Урал буе төркиләрендә фольклорның ничек эшләве турында В.А. Мошков тарафыннан китерелгән мәгълүматларны гасырлар чигендә яңадан бәяләү авыр, чөнки XX гасыр дәвамында традицион яшәү рәвеше шактый үзгәреш кичергән һәм бу традицион йола һәм уен культурасы өлкәсендә дә котылгысыз югалтуларга китергән. В.А. Мошковның ярдәме белән бездә әлеге кире кайтарып булмый торган күренешләр һәм шул заман халыкларының музыкаль традицияләре турында кабатланмас һәм кыйммәтле мәгълүматлар бар. Галим фольклорны аңлауның иң мөһим контекстуаль факторын теркәгән. Бүгенге көндә ул традицион көнкүреш, йолалар, шулай ук сөйләмә мәдәниятнең борынгы катламнарын саклаган кешеләр белән бергә юкка чыгып бара.

Туй йоласы турындагы кечкенә генә бүлек тә тәфсилле мәгълүмат белән тулы. Яучылау; кәләш өчен калым түләү һәм аның төрләре; бирнәнең эчтәлеге; туйда катнашучылар арасындагы ритуаль бүләкләр; туйга кадәрге кичәләр; кешенең җәмгыятьтә традицион үз-үзен тотышы. Туй үзе, өч көнлек тантана буларак, чагыштырма таблицада чагылдырылган, анда Урал һәм Түбән Идел буйларында яшәүче татарларда һәм нугайларда туйга кадәрге, туй һәм туйдан соңгы этапларның локаль «сценарийлары» чагыштырылган[1]. Ул шулай ук традицион костюмнарны да тәфсилләп тасвирлаган.

Нәкъ менә шушы бүлектә этномәдәни контекстта традицион музыка уен коралларында уйнау тәҗрибәсе турында белешмәләр бар. Нугай татарлары туй йоласының өч көнлек циклында булган вакыйгаларны тасвирлап (хәтта тәүлекнең кайсы вакытында булуын, сыйларның төгәл менюын ачыклап), Мошков, аерым алганда, Оренбург татарлары һәм нугайларның туйларында бәетләрне (ул аларны «байды» дип атый) мәҗбүри башкару тәҗрибәсе турында кыйммәтле хәбәрләр китерә. Алар аша без бүген ялгыз башкарудан алып бу жанрны тудыручыларның ярышуына кадәр күптөрле башкару формаларның юкка чыкканлыгын беләбез. Ул нугайларның бәетләрне думбрага кушылып башкаруларын бәян итә. Бу – бәетләрне башкару рәвеше

[1] В.А. Мошков Кундрау, Юрт һәм Оренбург нугайлары турында җыелма мәгълүмат бирә.

һәм контексты турында иң кыйммәтле мәгълүмат. В.А. Мошков хаклы рәвештә аларның язма мәдәният белән бәйләнешенә ишарәли һәм бәетләрне башкаручыларның махсуслашуын билгеләп үтә. Соңгысы, билгеле булганча, Идел буе татарлары традицияләренә хас.

В.А. Мошков – үткен интервью алучы. «Отношение между полами» бүлекчәсендә ул, традицион яшьләр уеннарын һәм биюләрен, соңгыларының исемлеген, шулай ук алардагы көйләрне, берөзлексез традицион җырлауга корылган өмәләрне тәфсилләп тасвирлап, Оренбург татарларының, Оренбург крае нугайлары һәм татар-казакларының (нагайбәкләрнең?) җәмгыятьтә традицион үз-үзен тотышларындагы аермаларны күрсәтә. Ул җирле Әстерхан татарларының һәм Урта Иделдән күченеп килгән татарларның (Казан татарлары һәм мишәрләр) килеп чыгышындагы, гореф-гадәтләрендәге специфик аерымлыкларны күрә. Ул күчмә һәм утрак тормышлы этнографик төркемнәргә исламның төрле дәрәҗәдә үтеп керүе турында яза.

Ниһаять, галим музыканың лад үзенчәлекләре өчен характерлы нечкә аерымлыкларны да ишетә. В.А. Мошков шәрехләмәләренә караганда, ул Урта Идел буе һәм Әстерхан татарларының музыкаль культураларына хас локаль үзенчәлекләрне яхшы белә, Оренбург һәм Әстерхан нугайларының телләрендәге генә түгел, ә шигырь төзелешендәге аермаларны да билгеләп үтә, Әстерхан нугайлары һәм татарларының, локаль төркемнәрне дә (Оренбург татарларының пентатоникасын һәм Әстерхан нугайларының диатоникасын) кертеп, лад аермаларын аныклый: «Тогда как музыка оренбургских ногайцев, на мой взгляд, почти ничем не отличается от музыки остальных татар, музыка астраханских ногайцев резко разнится от них и приближается по своему характеру скорее к музыке арийских народов» [Мошков, 1897, с. 273].

Этнография һәм музыкаль фольклор буенча тикшеренү текстларын язу процессында В.А. Мошков еш кына төрле мәдәниятләрдәге фольклор күренешләрен чагыштыра башлый. Нәтиҗәдә, монографик хезмәтләрдә компаратив фрагмент-чигенешләр, төрле этник мәдәниятләрнең гореф-гадәт яки музыкаль күренешләрен чагыштырып тасвирлау эпизодлары пәйда була. Әйтик, этнографик очеркның «Состязательные скачки» бүлекчәсендә автор нугайларның туй көннәрендәге ат чабышлары турындагы мәгълүматларны Дунай болгарлары, гагаузлардагы ат чабышлары белән янәшә куя, аларның христиан диненә кадәрге күзаллауларын удмурт һәм мариларныкы белән чагыштырып карый. Үз материалын Евразия контекстында биргәндә, автор Идел/Урал буе халыклары турында да сөйләп, борынгы уңдырышлылык культының чишмә башына ук барып чыга.

«Мелодии ногайских и оренбургских татар» очеркының II чыгарылышында тәкъдим ителгән сөйләмә традиция музыкасы үрнәкләре татар фольклорының үзенчәлекле әсәрләре булып тора. Аларның да лад, ритмика, структура һәм вербаль текстларга (20 язма берәмлек) хас таныш билгеләре бар.

«Песни астраханских и оренбургских ногайцев и киргиз» дигән III басмада (35 язма берәмлек) берничә этник төркемнең нотировкалары бирелгән. Солдатлар белән җыючы буларак эшләгәндә, ул татар һәм нугай лирикасын һәм ир-атлар репертуарындагы такмакларның текстларын, сирәк кенә бишек, кунак, туй, рекрут җырларын һәм казакъ айтысын теркәгән.

В.А. Мошковның музыкаль мөмкинлекләре турында чамалап кына әйтеп була, әмма тәкъдим ителә торган хезмәт аның музыкага искиткеч сәләтлелеге һәм нотага төшерү күнекмәсенә ия булуы турында сөйли. Музыканы нечкә тоемлавы[1], мөгаен, аңа, яздыру техникасы булмаганда да, нотага төшерүдә һәм төрки телләрне теркәүдә ярдәм иткәндер. Җырларны, җитмәсә, гадәти булмаган көйле, үзенчәлекле артикуляцияле җырларны ишеткәнчә язып алу, һичшиксез, бик авыр эш. В.А. Мошков, күрәсең, җырларны кабатлауларын сорагандыр, әмма кабатлаулар, әлбәттә, берсүзсез бер-берсеннән аерылып торганнардыр. Татар җырына хас булган мелизмнар, җырулар, glissando булмаганда, көйләрне беркадәр схемалаштыру шуның белән аңлатыла. Ул, күрәсең, аларның кайберләрен (бигрәк тә озын көйләрне) танымаслык үзгәртелгән дип санарга мөмкинлек бирә.

XXI гасырда В.А. Мошковның хезмәтләре, беренче чиратта, этнографиягә багышланган мәкаләләре яңадан нәшер ителә башлады. Ниһаять, аның фольклор мирасының да яңа басмалары дөнья күрә. 1980 елларда Ленинград дәүләт театр, музыка һәм кинематография институты фольклор секторының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, сәнгать фәннәре докторы И.И. Земцовский, фәндә тиешле бәясен алмаган авторның раритет басмаларын фәнни кулланылышка кертү максатыннан, сектор планына В.А. Мошковның музыкаль-фольклористик хезмәтләрен яңадан бастырып чыгаруны да кертергә тәкъдим итте[2].

Аның хезмәтләреннән теләгән һәркем файдалана алырга тиеш. В.А. Мошковның бу хезмәтен чыгарган редакциянең «От редакции Известий ОАИЭ» дигән язмасында әйтелгән теләк нәкъ менә бердәм хезмәт рәвешендә гамәлгә ашырылды. «Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края»-ның аерым басмалары бер тышлык белән, «Мелодии Волго-Камья» [Мошков, 2011] дигән исем астында заманча шәрехләмәләр белән басылып чыккан.

[1] С. Решетов В.А. Мошковның абсолют ишетү сәләтенә ия булуы турындагы нәтиҗәгә килә.

[2] ЛГИТМиК/РИИИ фольклор секторы хезмәткәрләре шәрехләмәләре белән бирелгән мәкалә һәм материалларны кабат бастыру эше нәкъ менә шулай башланды. Кара: [Токарев, 1966]. Бу китапта В.А. Мошковның славян мәдәниятләре буенча хезмәтләре тупланган; Идел һәм Урал буе төрки мәдәниятләре буенча хезмәтләре тупланган [Мошков, 2011]. Икенче китапны әзерләгәндә РИИИ фольклор секторы планнарының М.Г. Кондратьевның В.А. Мошков әзерләгән чуваш материалларын чыгару нияте белән туры килүе ачыкланды.

Бу китапта Мошков үзе исән вакытта дөнья күргән өч басма да төшереп алып (факсимиле рәвешендә) басылган, параллель хәзерге редакциясе дә бирелгән. Хезмәтнең чуваш өлешендә нәкъ менә җырларның вербаль текстлары яңартылган. Әдәбиятта «бик нык үзгәртелгән» дип бәяләнгәннәре 2011 елгы яңа басмада чуваш белгечләре тарафыннан төзәтелгән яки тулыландырылган[1].

Моннан тыш, аларның русчага тәрҗемәләре дә өстәлә. Китапның татар/нугай/казакъ өлешендә җырлар төркичә һәм русча вербаль текстлары белән бирелә. Аларга нибары бераз төзәтүләр генә кертелә[2].

Яңа басманың (II һәм III бүлекләр) татар өлешендә татар/нугай/казакъ вербаль текстларына һәм аларның рус теленә тәрҗемәләренә кечкенә генә төзәтүләр (төгәл яздырылмаган текстларны яңадан торгызу һәм, димәк, тәрҗемәләрне дә төзәтү) кертелгән, шулай ук көйләрнең ноталары да шактый реконструкцияләнгән.

Һәр җырга редакторның шәрехләмәсе бар. Яңа китапның ике яртысындагы нота материалларының редактурасы аерыла, чөнки һәрберсе аерым-аерым редакцияләнгән.

Яңа басмада чувашларга караган нота материаллары М.Г. Кондратьев тарафыннан җентекләп шәрехләнгән.

Әлбәттә, В.А. Мошков нотировкаларны ишеткән буенча эшләгән. Татар халык көйләрен яздырганда бер-ике, хәтта ике-өч тапкыр тыңлап кына, интонациянең бөтен борылышларын тотып алу мөмкин түгел. Әмма бу әлеге язмаларны чагыштырып карап тану мөмкинлеген чикләми. Аларның барысын да Идел буе татарларының җыр мирасы призмасы аша үткәреп реконструкцияләп була[3]. Алар арасында билгеле җыр текстлары һәм көйләр бик күп.

В.А. Мошков нотаның озынлыгын төгәл кабатлаганга күрә, җырның ритмик нигезе (ритмик клише[4]) күренә башласын өчен, кайчак ул куйган такт сызыгын күчерү яки иҗек эчендәге ритмик бүленешне бер озынлыкка салу да җитә.

Җырларның вербаль текстларына һәм аларның рус теленә тәрҗемәләренә төгәллек кертелде. Тик яткан «күзгә күренми торган» нота материалларын билгеле бер музыкаль-аналитик гамәлләр

---

[1] Чуваш җыр текстларын филолог, ЧГИГН өлкән фәнни хезмәткәре Г.Ф. Юмарт коррекцияләгән. Кайбер туй көйләренә шәрехләмәләрдә музыкаль структура редактор М.Г. Кондратьевның идентификация критерие булып тора, ә җырларның шигъри тексты бу сыйфатта катнашмый. Ирексездән 25 нче җыр тексты туй җыры була аламы дигән сорау туа.

[2] Татарча текстларны, шулай ук аларның русчага тәрҗемәләрен Н.Ю. Әлмиева редакцияләде, нугай текстларын – Л.Ш. Арсланов (консультант – сәнгать фәннәре кандидаты Г.М. Макаров), казакъныкыларны А.Б. Кунанбаева эшләде.

[3] Реконструкция квантитатив ритмикалы җырларга кагыла. Квадрат структуралы кыска җырларга ул таләп ителми.

[4] Ритмик клише – әлеге мәкаләнең авторы тарафыннан тәкъдим ителгән [Альмеева, 1986, с. 54–61], татар фольклорының мелодикасын анализлау өчен кулланыла торган термин.

ярдәмендә «күренерлек» итү мөмкин булды[1]. Нәтиҗәдә көйләрнең «үз йөзе» барлыкка килде. Ә ноталарның реконструкциясе буенча шулай ук аларның яңгырашын да торгызып була. Татар фольклористикасында яшәп килгән татар җырларының В.М. Мошков тарафыннан гадиләштереп язылган нотировкалары буенча кайбер җырларның чын яңгырашын күзаллап булмый, дигән фикерне хупларга ашыкмыйк.

Хәтта фәнни кулланылышка кертелсә дә, әлеге хезмәтнең яңа басмасы тагын да тирәнрәк тикшеренүчеләрен көтә. Олуг рәхмәт хисләре белән, Валентин Александрович Мошковның исеме – һичшиксез, Россия этнологиясе һәм фольклористикасы өчен дә, Идел-Кама музыкаль тюркологиясе өчен дә иң мөһимнәрдән берсе, дип билгеләп үтәсе килә.

**Әдәбият**

*Альмеева Н.Ю.* Песенная культура татар-кряшен: жанровая система и многоголосие: дис. … канд. искусствоведения. Л., 1986. 152 с.+ 75 с. нотн. прил.

*Бернандт Г.Б., Ямпольский И.М.* Кто писал о музыке: Биобиблиографический словарь музыкальных критиков и лиц, писавших о музыке в дореволюционной России и СССР. В 3-х томах. Т. 2. М.: Советский композитор, 1974. 313 с.

Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов. Дооктябрьский период. Мошков В.А. М., 1974. 342 с.

*Вульфиус П.А.* К истории русской музыкальной фольклористики. Русская мысль о музыкальном фольклоре / под общ. ред. О.И. Соколовой. М.: Музыка, 1979. 366 с. С. 10–72.

*Гаристов, Владимир П.* Не намъ, не намъ, а Имени Твоему. София, 2008. 171 с.

*Земцовский И.И.* Фольклористика как наука // Славянский музыкальный фольклор. Статьи и материалы. М.: Музыка, 1972. С. 9–79.

*Иванов-Ехвет А.И.* Музы ищут приют. Чебоксары: Чуваш. кн. изд-во, 1987. 350 с.: ил., нот.

*Кондратьев М. Г.* Первопроходец // Журнал Музыкальная академия. 2002. № 3. С. 142–149.

*Кондратьев М.Г.* Парадокс Валентина Мошкова // Из истории татарской музыкальной культуры. Сб. ст. / сост. В.Р. Дулат-Алеев. Казань, 2010. 184 с. (Науч. труды Казанской консерватории; Вып. 2. С. 149–162).

*Лаврентьева Л.С.* «Говорить по-арабски. Из гагаузских коллекций полковника В.А. Мошкова» // Электронная библиотека Музея антропологии и этнографии им. Петра Великого (Кунсткамера) РАН. URL: http://www.kunstkamera.ru/files/lib/978-5-02-038267-1/978-5-02-038267-1_05.pdf (Дата обращения 04.08.2018).

*Максимов С.М.* Чувашские народные песни. Редакция В. Беляева. М.: Музыка, 1964. 399 с.

*Мошков В.А.* По поводу юбилея Оскара Кольберга // Баян [СПб]. 1889. №20. С. 163–164;

*Мошков В.А.* По поводу юбилея Оскара Кольберга // Баян [СПб]. 1889. №21. С. 170–171.

[1] Музыкаль структураны торгызу максаты белән һәр көйне реконструкцияләү процессының әлеге юлларның авторы тарафыннан эшләнгән тулы тасвирламасы һәр җырның шәрехләмәсендә бар.

*Мошков В.А.* Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края. I. Музыка чувашских песен // Известия ОАИЭ при Имп. Казанском ун-те. 1894. Т. 17. Вып. 1. С. 31–64, 167–182, 261–276, 369–376. Имеется отд. оттиск.

*Мошков В.А.* Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края. II. Мелодии ногайских и оренбургских татар. [2. Песни и комментарии] // Известия ОАИЭ при Имп. Казанском ун-те. 1897. Т. 14. Вып. 3. С. 265–291. Имеется отд. оттиск.

*Мошков В.А.* Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края. III. Мелодии астраханских и оренбургских ногайцев и киргиз // Известия ОАИЭ при Имп. Казанском ун-те. 1901. Т. 17. Вып. 1. С. 1–41. Имеется отд. оттиск.

*Мошков В.А.* Гагаузы Бендерского уезда. Этнографическое обозрение, 1900/ № 1. С. 1–90 (4–91); 1901. № 2. С. 1–50 (203–253).

*Мошков В.А.* Мелодии Волго-Камья / под ред. М.Г. Кондратьева и Н.Ю. Альмеевой). Чебоксары: Чуваш. кн. изд-во, 2011. 366 с.

Наречия бессарабских гагаузов / Тексты собраны и переведены В. Мошковым // Образцы народной литературы тюркских племен, изданные В. Радловым. СПб., 1904. Ч. 10.

*Нигмедзянов М.Н.* Народные песни волжских татар. Исследование. М.: Сов. композитор. 1982. 135 с.

*Решетов А.М.* В.А. Мошков как учёный. Информационно-аналитический вестник Serin Su. Интернет-ресурс: http://serin.su/publ/a_m_reshetov_v_a_moshkov_kak_uchenyj/1-1-0-18. Дата обращения 25.11. 2021.

*Рыбаков С.Г.* Музыка и песни уральских мусульман с очерком их быта. СПб., 1897. 340 с.: нот.

*Родителева М. И.* Вступительная статья в книге: Фольклористическое наследие В.А. Мошкова: Антология / Сост. М.И. Родителева. СПб.: Изд-во С.-Петерб. ун-та, 2003. 164 с. (Наследие петербургских ученых): с нот.

*Токарев С.А.* История русской этнографии. М., 1966. 456 с.

***Әлмиева Наилә Юныс кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты,*
*Россия сәнгать тарихы институты (Санкт-Петербург)*

УДК 76.02

***О.Л. Улемнова***

# Д.Л. НӘҮРУЗОВАНЫҢ КИТАП ГРАФИКАСЫ (советтан соңгы чор Татарстан сәнгатендә яңа тенденцияләр чагылышы)

Статья посвящена одному из ведущих художников-графиков современного Татарстана Диляре Ленаровне Наврозовой. Автор представляет ее творческий путь, начиная с истоков – профессионального художественного образования, полученного в Казани и Москве, отмечает основные графические жанры, в которых работает художник: книжная и журнальная графика, графический дизайн, станковая графика, выявляет особенности индивидуальной манеры, вклад в татарское изобразительное искусство.

**Ключевые слова:** иллюстрация, станковый рисунок, графический дизайн, национальное искусство.

The article is dedicated to one of the leading graphic artists of modern Tatarstan, Dilyara Lenarovna Navrozova. The author presents her creative career, starting from the origins – professional art education received in Kazan and Moscow, notes the main graphic genres in which the artist works: book and magazine graphics, graphic design, easel graphics, reveals the features of individual manner, contribution to the Tatar visual art.

**Keywords:** illustration, easel drawing, graphic design, national art.

Диләрә Ленар кызы Нәүрузова – хәзерге вакытта Татарстанда әйдәп баручы китап бизәүче рәссамнарның берсе. Республикабызның китап һәм журнал нәшриятларында аның иҗатына ихтыяҗ зур. Ул – иҗатка Татарстан рәссамнарының 1990 елларда илебезне чолгап алган катлаулы «үзгәрешләр чоры»нда килгән буыны вәкиле. Без күнеккән дөнья җимерелгән, рәссам һәм социум арасында яңа бәйләнешләр һәм яңа ихтыяҗлар туган заман иде бу. Мөгаен, яңа эшли башлаган яшь рәссамга базар шартларына күнегү, бер яктан, җиңелрәк тә булгандыр – чөнки аның хезмәттәшлек итү шаблоннары әле эшләнмәгән була, икенче яктан, катлаулырак – чөнки яшьләрнең иҗат турындагы идеалистик күзаллаулары тупас чынбарлык белән очраша.

Нәкъ менә шундый шартларда Д.Л. Нәүрузованың иҗат юлы башланып китә. Ул 1970 елның 27 декабрендә Казанда туа, 1990 елда «рәссам-декоратор» белгечлеге буенча Казан сәнгать училищесын тәмамлый, «Казанские ведомости» газетасы, «Идел», «Салават купере» журналлары кебек Казан басмаларында эшли, аларны иллюстрацияләү һәм бизәү белән шөгыльләнә, ә 1992 елдан китап нәшриятлары белән хезмәттәшлек итә башлый.

Яңа иҗат эшчәнлеге белән мавыгып, 1994 елда Д.Л. Нәүрузова Мәскәү дәүләт матбугат университетына укырга керә. 2000 елда аны,

«рәссам-график» белгечлеге алып, уңышлы тәмамлый. Университетта ул совет балалар китабын бизәү өлкәсендә иң күренекле осталарның берсе, РСФСРның атказанган рәссамы (1978), Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе (2002), профессор Владимир Валерьевич Перцов остаханәсендә укый.

В.В. Перцов кул астында Д.Л. Нәүрузова менә дигән һөнәри осталык мәктәбе уза: графикадагы бөтен материал һәм техникаларның куллану үзенчәлекләренә төшенә; күптөрле сәнгати эзләнүләрнең нигезендә яткан натурадан ясауның китапчы рәссам өчен аеруча мөһим булуын үзләштерә; китапка бердәм ансамбль итеп карарга өйрәнә, чөнки аның барлык элементлары үзара тыгыз бәйләнгән, бер идеягә һәм бердәм график чишелешкә буйсындырылган.

Диплом эшендә үк – Л. Кэроллның «Алиса могҗизалар илендә» әкиятенә иллюстрацияләр сериясендә, – Д.Л. Нәүрузова үзен үтә сизгер рәссам-график буларак күрсәтә. Н.Х. Кумысникова сүзләре белән әйткәндә, «мавыктыргыч та, матур да, җиңел дә» [Кумысникова, с. 78] итеп ясалган бу рәсемнәрдә рәссам, инглиз җәмгыятенең нәзакәтлелеген һәм Кэролл текстының мантыйкка сыешмавын җиткерү өчен, реалистик сурәтләнгән предметларны һәм фигураларны тиешле дәрәҗәдә деформацияләп һәм стильләштереп бирә, стандарт булмаган композицион чишелешләр таба.

Һөнәри югары уку йортын тәмамлаган дипломлы белгеч Д.Л. Нәүрузова 2000–2010 елларда Татарстанда, график-дизайнер буларак, зур популярлык казанды. Эш дәверендә рәссам Татарстан китап нәшрияты, «Мәгариф», «Рухият», «Идел-Пресс» нәшриятлары өчен Н. Әхмәдиев, К. Булатова, Р. Бохараев, Р. Вәлиев, Т. Миңнуллин, Г. Тукай, Р. Фәйзуллина, Ф. Яруллин һ. б. кебек күренекле татар язучылары һәм шагыйрьләренең 100 гә якын китабын бизәде.

1990–2000 елларда Д.Л. Нәүрузова «Мәгариф» нәшрияты белән актив хезмәттәшлек итә. Сәнгати формалар белән экспериментлар үткәрү мөмкинлеге бирелгәнгә, яшь рәссамнар өчен «Мәгариф»тә эшләү кызыклы була. Бу нәшриятта татар язучыларының (Н. Әхмәдиев, Р. Вәлиев, Р. Гыйззәтуллин, Р. Фәйзуллин һ.б.) китаплары, шулай ук чит ил классикларының (Г. Андерсен, Р. Киплинг, А. Конан Дойл) татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре Д.Л. Нәүрузова бизәлешендә нәшер ителә. Аларда «тасвирый рәт әдәби текстны гәүдәләндереп кенә калмый, ә бәлки яңа нәфис, синтетик әсәр – китап иҗат итүнең тулы бер факторына әверелә бара» [Улемнова, с. 6–7].

Татарстан китап нәшрияты өчен ул татар мәдәнияте әһелләренә – актер, җырчы, язучы һәм шагыйрьләргә (Шәриф Хөсәеновка (2006), Әзһәр Шакировка (2007, 2013), Ринат Таҗетдиновка (2008), Нәҗибә Ихсановага (2009), Зифа Басыйровага (2011), Зөһрә Сәхәбиевага (2016)) багышланган китаплар сериясенең бизәлешен эшләде. Д. Нәүрузовага еш кына республиканың җаваплы юбилей басмаларын бизәү эше дә тапшырыла. Күп кенә дәүләт, җәмәгать эшлеклеләренең, язучы, музыкантларның юбилейлары уңаеннан чыгарылган

альбом-китаплар аның тарафыннан эшләнгән: «Балкыш. Шамил Закировка бер дога» (2017); «Разил Вәлиев» (2017), «Равил Фәйзуллин. Гомер калейдоскобы « (2018), «Хәйдәр Бигичев» (2019). 2010 елда, Актаныш районы хакимияте заказы буенча, Актаныш авылының – 300, Актаныш районының 80 еллыгына багышлап, ТР Язучылар берлеге һәм ТР Фәннәр академиясе белән берлектә әзерләнгән «Актанышым – ак илем» дигән китап-альбомны һәм «Актаныш басмалары» җырлар җыентыгын да ул бизәде. Киң җәмәгатьчелек тарафыннан әлеге басмалар бик яратып кабул ителде. Басмаларны әзерләү барышында рәссамга төрле дәверләргә караган, төрле характердагы материаллар – текстлар, фоторәсемнәр, архив документлары белән эшләргә туры килә. Ул аларны китапның битләре һәм тышлыгының эчке яклары бизәлешендә, заман таләпләренә туры китереп, бик оста файдалана.

2014–2016 елларда Д.Л. Нәүрузова «Мәгариф – Вакыт» нәшриятына Ә. Мотыйгуллинаның 5, 6, 7, 8 һәм 9 сыйныфлар өчен татар әдәбияты буенча дәреслекләр сериясенең бизәлешен эшли. Хәзерге вакытта ул, А.Б. Шляпкин белән берлектә, төп гомуми белем бирү оешмалары өчен ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан әзерләнә торган татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре өстендә эшли [Сафиуллина, б. 25]. Д.Л. Нәүрузова бизәлеш редакторы һәм техник мөхәррир буларак зур эш башкара. Мәсәлән, М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина һәм О.Р. Хисамов язган 2 нче сыйныф «Туган тел (татар теле) дәреслеге өчен ул балаларга ана телен өйрәнү генә түгел, ә татар мәдәнияте белән танышырга да ярдәм итүче искиткеч матур рәсемнәр ясаган.

1990 елларда «Идел» һәм «Салават күпере» кебек татар журналларын иллюстрацияләп, Д.Л. Нәүрузова, журнал графикасында да күп эшләде. 2010 елларда ул журнал дизайны өлкәсендә хезмәт куйды, татар журналына заманча графика идеяләрен кертүдә аның да өлеше зур. «Сәхнә» (2010–2013), «Чын Мирас» (2012–2013), «Безнең мирас» (2014) басмалары еллар дәвамында ул эшләгән бизәлештә басылды.

Әмма Д.Л. Нәүрузова үз иҗатында төрле рәсем техникаларында эшләнә торган китап графикасына өстенлек бирә. Һәм бу яктан Татарстанда аннан да нәзакәтлерәк һәм зәвыклырак рәссам-графикны табуы кыен. Бер китапның бизәлеш стиле эшләнеп, аның график чишелеше шулкадәр уңыш казану һәм укучыларның игътибарын җәлеп итү нәтиҗәсендә, берничә мәртәбә бөтен бер серияләр барлыкка килгән. «Ай юрганы» әкиятләр җыентыгы – моның ачык мисалы. Ул Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Дөнья халыклары әкиятләре» сериясен башлап җибәрә. Бу сериядә Д.Л. Нәүрузова «Ак бүре» татар халык әкиятләре (2012), «Мең дә бер кичә» гарәп әкиятләре (2013), «Казлар-аккошлар» рус әкиятләре (2014) җыентыкларын бизәгән. Һәр китапта рәссам текст белән параллель рәвештә мавыктыргыч вакыйгаларга, кызыклы персонажларга, төрле предмет-атрибутларга бай

әкият дөньясы тудыра. Укучы аларны карап туймый. Милли әкият китапларының график чишелеше шул халыкларның һәм илләрнең мәдәни һәм географик үзенчәлекләрен ачуга юнәлтелгән: кабатланмас пейзажлар, архитектура, костюмнар һәм геройларның тышкы кыяфәте, орнаментлар һәм төсләр – барысы да шуңа хезмәт итә. Шул ук вакытта аерым бер линеарлык, үзенчәлекле композицион корылышлар, нәфис колорит авторның үз манерасы булуга ишарәли.

Д.Л. Нәүрузованың милли характерны чагылдыру өчен сәнгати форма табарга омтылуы, татар тарихы белән кызыксынуы Равил Бохараевның 2016 елда «Kazan-Казан» нәшриятында чыккан ике китабының бизәлешендә ачык күренә: «Тень Тамерлана» һәм «Пьесы-сказки». Бу очракта, күрәсең, рәссамга сәнгать чараларын сайлауда тулы ирек бирелә, ул график тәҗрибәләр ясау мөмкинлеге ала, һәм китап рәссамы буларак, бөтен осталыгын күрсәтә: тематик якынлыкны ассызыклаган бердәм график манерада башкарылган гармонияле китап ансамбльләре пәйда була. Рәссам һәр басманы бизәгәндә, тышлыклар, форзацлар, титуллар, шмуцтитуллар, иллюстрацияләр, заставкалар һәм концовкалар өчен үзенчәлекле композицияләр иҗат итә. Аның буй сызык иллюстрацияләре – катлаулы күп фигуралы композицияләр, аларда тарихи детальләрнең дөреслеге күпкатлы сюжет һәм бормалы-сырмалы пространство-вакыт бәйләнешләре белән яраша, аларның мәгънә һәм символикаларына төшенү җиңел түгел. Шул ук вакытта китапларның бизәлеше бер дә артык чуар булып тоелмый – нәзек-нәфис сызыклы рәсемнәр, нәзакәтле колористик чишелешләр, автор сүзе белән параллель бирелгән «акыллы» иллюстрацияләр рәссамга текстның һәм декоратив элементларның балансын булдырырга ярдәм итә.

Китап-журналларда эшләү белән бергә, Д.Л. Нәүрузова станлы картиналар язу өчен дә вакыт таба. «Ел фасыллары» (2003) – аның иң кызыклы серияләренең берсе. Иҗатына хас бөтен сыйфатлар: теманы ачуга фәлсәфи якын килү, сюжет коллизияләренең символик мәгънәсе, детальнең ышандырырлык сурәтен шартлы пространстволы чишелеш белән тоташтыру, төрле график фактуралар – барысы да ярылып ята. Серия графит карандаш белән эшләнгән, рәссам кулында ул көмеш төсләр белән балкыган графика материалына әверелә. Җиңелчә акварель буяулар ел фасылларына хас төсләрне ассызыклау өчен кирәк.

«Шагыйрьнең соңгы көзе» (2006) картинасында Д.Л. Нәүрузова яраткан графит карандаш сызыклары әле ачык, әле куе төстә, әле якты һәм җиңел, әле еш итеп сызылган нечкә сызыкларга әйләнә, әле бармак бите белән таратылган нәфис томанны хәтерләтә. Болар барысы да шәһәр пейзажы аша чагылдырылган фаҗиганы тоемларга ярдәм итә. Композициядә герой сурәте юк, әмма без сүзнең бөек татар шагыйре, хәзерге татар әдәби теленә нигез салган Габдулла Тукай турында баруын аңлыйбыз. Ул 1913 елда 27 яшендә вафат булды. Рәссам конкрет җирлекнең топографиясен бирми, әмма архитектура

корылмаларыннан һәм хөкем сөргән гомуми атмосферадан Казандагы Г. Тукай гомеренең соңгы көннәре узган Татар бистәсе образы танышла. Ул шәһәр пейзажын символик детальләр белән баета: стихия басымы астында бөгелеп төшкән куәтле агачлар, яралы сугышчылар кебек, бау белән бәйләнгән; төшкән тәгәрмәч юлның бетүен кисәтә; кара каргалар афәт килүен җиткерә; елгадагы ялгыз көймә, Лета елгасындагы Харон көймәсе күк, соңгы юлга озату өчен үз пассажирын көтә...

Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең әдәби-хореографик композициясенә иллюстрацияләрдән торган «Җиде энҗе» (2009) сериясендә (серия басылып чыкмый һәм хәзер станлы әсәр буларак кабул ителә), Д.Л. Нәүрузова, милли көнкүрешкә һәм халык гореф-гадәтләренә хас нечкәлекләрне сәнгати манералар шартлылыгы белән тоташтырып, традицион татар мәдәнияте дөньясын торгыза. Бу рәсемнәрдә рәссам, геройларның хискә бирелүчәнлеген ассызыклау өчен, пастельне сайлый. Ә кәгазь төсе, образлы чишелешләрне һәм эмоциональ эчтәлекне көчәйтеп, һәр күренештә буяуларны бер-берсенә яраштыра: төп геройның юлчылар белән очрашуында яшел төс үләнне һәм агач ябалдашларын белдерә; күк төс – яшь ананың бишектә сабый баланы тирбәтү күренешендә төнге серлелекне куәтли; ә кызгылт-көрән төс авыл йортындагы җылылыкны күрсәтә, анда дуслары чолганышындагы яшь гармунчы егетнең уйнавына кушылып, кызлар җырлый-җырлый йон эрлиләр...

Әгәр укучылар Д.Л. Нәүрузованың китап-журнал графикасы белән бөтен республика һәм аннан читтә таратыла торган китаплар һәм журналлар аша танышсалар, аның станлы әсәрләрен күргәзмәләрдә күрергә мөмкин. Рәссам 1990 елдан бирле төрле (төркем, республика, зона, бөтенроссия, халыкара) күргәзмәләрдә даими катнашып килә. Д.Л. Нәүрузова – «Ел китабы» дип исемләнгән укучылар конкурсында Р.И. Вәлиевнең «Гөрләвек» (2005) китабы бизәлеше өчен «Тамашачылар симпатиясе призы» лауреаты, «Шаян әфлисун» («Заводной апельсин») төрү материаллары дизайны өлкәсендә Студентлар эшләре халыкара конкурсының «Татлы ашамлыклар өчен төрү материаллары» («Упаковка для кондитерских изделий») категориясендә беренче премия лауреаты (Мәскәү, 2008). 2001 елдан ул – Татарстан Рәссамнар берлеге, 2002 елдан Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы. Д.Л. Нәүрузованың әсәрләре Татарстан Республикасы дәүләт сынлы сәнгать музее, «Казан Кремле» Дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы, Чуваш дәүләт сәнгать музее тупламаларында саклана.

Д.Л. Нәүрузова – үз иҗат манерасы булган рәссам, аны башкалар белән бутау мөмкин түгел. Аның иҗатында Көнчыгыш һәм Европа сәнгати традицияләренең тыгыз бәйләнешләре чагыла. Татарстанның тасвирый сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән өчен рәссам зур хөкүмәт бүләгенә лаек булды – 2021 елның мартында аңа «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы

исем бирелде. Д.Л. Нәүрузованың иҗат потенциалы гаять зур, аның фантазиясе армый-талмый яңа образлар тудыра, аның һөнәри тоемлау сәләте куелган бурычларны хәл итү өчен яңа сәнгати чаралар табарга мөмкинлек бирә. Болар барысы да рәссамның милли характерны чагылдыру юнәлешендәге эзләнүләре яңадан-яңа ачышларга китерер, дип өметләнергә мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

*Кумысникова Н.* Матур дә, җиңел дә // Идел. 2004. № 10. Б. 78.

*Сафиуллина Р.* Татар телен башкача да өйрәтергә мөмкин // Идел. 2020. № 7. Б. 20–25.

*Улемнова О.Л.* [Вступительная статья] // Искусство книги Татарстана. Первая Республиканская выставка. 8–20 апреля 2008 года, Национальный музей РТ. Каталог / авт. вст. ст. и сост. каталога О.Л. Улемнова. Казань: Отечество, 2013. С. 5–8.

*Мәкалә «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасының 3.19 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Улемнова Ольга Львовна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге әйдәп баручы хезмәткәре*

УДК 069.44

***Губина Т.А.***

# ТАТАРСТАН МУЗЕЙЛАРЫНДАГЫ РЕСТАВРАЦИЯ ОСТАХАНӘЛӘРЕ

В статье впервые дается обзор реставрационного дела в Татарстане. Кратко раскрывается деятельность ведущих реставрационных мастерских. Выявлены основные этапы работы мастерских, рассмотрены проблемы обеспечения мастерских кадрами, оборудованием, материалами.

**Ключевые слова:** искусство, музей, реставрация, мастерская, реставратор, живопись, декоративно-прикладное искусство.

The article reveals the features of restoration activities in Tatarstan on the example of works of fine and decorative-applied art. The author drawing on the results of a sociological survey identifies the main stages of restoration work in the museums of the republic, raising the problem of providing workshops with equipment, materials and personnel issues.

**Keywords:** art, museum, restoration, workshop, restorer, painting, arts and crafts.

Мәдәни мирасны саклау өлкәсендә реставрация музей эшенең аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Кешелек дөньясы тарихи үткәннең әһәмиятенә төшенгәннән соң, хәзерге заманда барган процессларны аңлау өчен музейлар төзи башлаганнар. Казанда алар XIX гасырда ук төрле уку йортлары, Казан университеты каршында барлыкка килә. 1895 елда киң җәмәгатьчелек өчен Шәһәр фән-сәнәгать музее ачыла. XIX–XX гасырда музейлар республикабыз шәһәрләрендә дә, районнарында да оештырыла.

Музейлар коллекцияләрне саклау урыны булып хезмәт итә, узган гасырның башында моңарга мәдәни агарту вазифасы да өстәлә. Әмма 1970 елларда гына Татарстанда музей базасында беренче реставрация остаханәсе барлыкка килә. Моңа кадәр СССРда экспонатларны төп реставрация үзәкләренә тапшыру һәм белгечләрне чакыртып китерү гамәлдә була.

Мәкаләдә без Татарстан дәүләт музейларындагы реставрация остаханәләрен ачыкларбыз һәм аларның эшчәнлегенә кыскача күзәтү ясарбыз.

Татарстанда 120 дән артык музей эшли. Алар арасында дәүләт музейлары да, шәхси музейлар да бар. Дүрт реставрация остаханәсе булуы ачыкланды: өчесе – дәүләт музейлары структурасында (ТР Милли музее, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее, «Зөя утрау-шәһәрчеге» музей-тыюлыгы), берсе – фәнни учреждение каршында (ТР Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты музее).

Учреждениеләрнең коллекцияләрендә бер музейга чама белән 12000 саклау берәмлеге туры килә һәм бу сан елдан-ел арта бара. Эре музейларда предметлар саны 60000 гә, хәтта 946000 гә җитә. Музейлар эшчәнлегенең төп эчтәлеге коллекцияләрне саклаудан гыйбарәт. Реставрация әлеге процессларның әһәмиятле өлеше булып тора һәм, предметның яшәүгә сәләтен тәэмин итү өчен, бу эш белән даими шөгыльләнү сорала.

Татарстан Республикасы Милли музеена 1894 елда Казан тау фән-сәнәгать музее буларак нигез салына [8]. Хәзерге этапта музей коллекцияләрендә якынча 946000 саклау берәмлеге исәпләнә. Бу – Татарстан Республикасының иң зур музее. Ул тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать предметларын, табигать фәннәре коллекцияләрен һәм башкаларны үз эченә ала. Әлбәттә, мондый фондларны реставрация остаханәсеннән мәхрүм итеп булмый. 1997 елда музейда шундый остаханә булдырыла. Коллективта тугыз музей хезмәткәре эшли. Хәзерге вакытта тукыма әйберләр, металл, агач, керамика һәм архив материаллары юнәлешләрендә эш алып барыла. Остаханәләр музейның төп бинасында урнашкан. Әлбәттә, мондый зур музейда реставраторлар күп булырга тиеш.  Реставрация эшләренең күләме бик зур булганга, музей «Зөя утрау-шәһәрчеге» музей-тыюлыгы, Дәүләт сынлы сәнгать музее, ТР Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты кебек чит оешмалар белән дә шартнамәләр төзергә мәҗбүр була.

ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее 1958 елда ТАССР Дәүләт музееның сәнгать коллекцияләре базасында гамәлгә куела [Новицкий]. 1964 елда музейга Казан хәрби округы гаскәрләре командующие резиденциясе бинасы бирелә. Реставрация үткәрелгәннән соң, 1967 елда музей тамашачылар өчен үз ишекләрен ача. Комплекс төп бинаны (анда администрация бүлмәләре, XVI – XX гасыр башы чит ил һәм рус сәнгате экспозицияләре заллары), аның янәшәсендә реставрация остаханәләре, саклау урыны – фондлар урнашкан корылманы үз эченә ала. 2005 елда Казан Кремле территориясендәге бинаның бер өлеше дә музейга тапшырыла һәм анда «Хәзинә» милли сәнгать галереясы ачыла. Тамашачылар аның  экспозицияләрендә декоратив-гамәли сәнгать, нәкыш, графика һәм скульптура әсәрләрен күрә ала. Шул ук бинада картиналар коллекциясен реставрацияләү остаханәләре дә эшли.

Россиядә реставрация өлкәсендә билгеле бер тәҗрибә эзгә салынган: нигездә, экспонатлар илнең төп реставрация үзәкләренә – Дәүләт фәнни-тикшеренү реставрация институтына һәм И.Э. Грабарь исемендәге Бөтенроссия сәнгать фәнни-реставрация үзәгенә җибәрелә. Сынлы сәнгать музее озак еллар дәвамында нәкъ менә соңгысы белән эшләде дә инде.

1970 елда артефактларны үзебезнең хезмәткәрләр көче белән реставрацияли башладылар. Бу эштә беренчеләрдән булып Ширяева Алла Германовна юл яра: ул майлы буяу белән ясалган картиналарны

реставрацияли. Ширяева А.Г. Илья Репин исемендәге Санкт-Петербург сәнгать академиясендә укыган. Соңрак ул И.Э. Грабарь исемендәге Бөтенроссия сәнгать фәнни-реставрация үзәгендә стажировкалар узган. Аның тарафыннан реставрацияләнгән әсәрләр Яр Чаллы Картиналар галереясында, Алабугада И.И. Шишкинның музей-йортында һәм Дәүләт сынлы сәнгать музееның рус һәм Көнбатыш Европа сәнгате экспозициясендә күрсәтелә. 2002 елда аңа әлеге эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

1976 елда музейга Махсус фәнни-реставрация җитештерү остаханәсендә һәм башка предприятиеләрдә эшләгән һәм станлы темпералы нәкыш өлкәсендә зур тәҗрибә туплап өлгергән реставратор Романова Наталья Леонидовна килә. Эшләү дәверендә ул Зөя соборларындагы, Казан шәһәренең иске йола чиркәвендәге, музей фондларындагы һәм даими экспозицияләрдәге күпсанлы борынгы иконаларны торгыза. 1992 елда Яр Чаллы Картиналар галереясында «Яңа заман рус иконасы» күргәзмәсе булды. Н.Л. Романова укучысы Михайлина Наталья Евгеньевнага остаз да булды, аны да темпера техникасында иҗат ителгән картиналар реставраторы итеп әзерләүгә күп көч куйды (соңрак ул темпералы нәкышне реставрацияләү бүлегенә мөдирлек итте).

1980 еллар башында реставрация остаханәләре эше өчен кирәкле таләпләрне исәпкә алып, махсус бина төзелә.

Ә 1981 елда Дәүләт сынлы сәнгать музее коллективына Савельева Надежда Михайловна килеп кушыла. Реставрация эшенең ни дәрәҗәдә күркәм булуы белән мавыгып, ул 1983 елда остаханәләргә күчә һәм хәзерге вакытта да майлы буяу белән ясалган картиналар реставраторы һәм ТР ДССМ майлы буяулы нәкышне реставрацияләү бүлеге җитәкчесе булып эшли. Аның көче белән XVII–XVIII гасырлардагы Италия, Франция һәм Голландия, XVIII гасыр һәм XX гасыр башы Россия рәссамнарының әсәрләре реставрацияләнә. 2010 елда аңа «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

Нәкъ менә алар – А.Г. Ширяева, Н.Л. Романова, Н.М. Савельева ТР ДССМда реставрация эшенең нигез ташларын салалар, майлы буяулы һәм темпералы нәкышне реставрацияләү остаханәләрендә ару-талуны белми хезмәт куялар. Бары тик 2000 елларда гына майлы буяулы һәм темпералы нәкыш бүлекләре киңәйтелә. 2010 елларда ниһаять күптән көтелгән яңа юнәлешләр ачыла. Хәзер музейда полихром скульптура, металл, фарфор һәм пыяла, тукыма әйберләр, таш һәм гипстан скульптура, графика реставрацияләнә. Соңгы елларда төп бинаның реставрация остаханәләрендә ремонт булды, климат-контроль урнаштырылды, заманча реставрация һәм башка җиһазлар сатып алынды.

«Зөя утрау-шәһәрчеге» музей-тыюлыгы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән 2009 елда төзелә. 2010 елда

аның территориясендә археологик тикшеренүләр үткәрелә башлый. Бик күп предметлар табыла һәм 2013 елда агач археологиясе музее булдыру турында карар кабул ителә. Предметларны саклау максатында 2014 елда реставрация остаханәсе ачыла. 2019 елның гыйнварында музей структурасында реставрация бүлеге барлыкка килә. Хәзерге вакытта түбәндәге юнәлешләр буенча эш алып барыла: графика һәм китапларны реставрацияләү, темпералы һәм майлы буяулы нәкыш, керамика һәм тукыма әйберләрне реставрацияләү.

Гомуми фонда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты структурасына керүче ТР археология музееның реставрация остаханәсе материалның үзенчәлекле булуы белән беркадәр аерылып тора. Археология музеена 2005 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе буенча нигез салына. 2019 елда ул РФ Музей фондының дәүләт өлешенә кертелә. Музей коллекциясендә 400 000 нән артык археологик предмет исәпләнә, ел саен ул якынча 10 000 данәгә артып бара.

2006 елда оештырылган бүлек структурасында эш өч юнәлештә алып барыла: металлдан ясалган әйберләрне реставрацияләү, археологик керамиканы реставрацияләү һәм органик материалларны реставрацияләү. Музейда Богатова Лина Феликсовна, Каплан Полина Юрьевна, Котов Роман Владимирович, Федан Павел Владимирович кебек аттестация узган рәссам-реставраторлар эшли. Алар фәнни хезмәткәрләр булып санала, барысы да профильле белемгә ия. Дәүләт фәнни-тикшеренү реставрация институтында, Дәүләт Эрмитажында, И.Э. Грабарь исемендәге Бөтенроссия сәнгать фәнни-реставрация үзәгендә, Мәдәни мирас институтында әледән-әле стажировкалар узалар. Реставрация-аналитика бүлеге хезмәткәрләре, реставрация эшләреннән тыш, шулай ук тикшеренү эшчәнлеге белән дә актив шөгыльләнәләр.

Ел саен реставраторлар 1000 нән артык предметны торгызуга алыналар. ТР Милли музее, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы, Агач археологиясе музее («Зөя утрау-шәһәрчеге» музей-тыюлыгы), Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы һәм республиканың башка музейлары үз экспонатларын аларга ышанып тапшыра.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, без Татарстан Республикасында мәдәниятне саклауда реставрация эшен үстерүнең мөһим фактор булуын ассызыклый алабыз. Җиһазларның кыйммәт һәм кечкенә торак пунктларда кадрлар белән тәэмин итүнең катлаулы булуы аркасында, республиканың һәр музеенда реставрация остаханәсе булдырырга мөмкин түгел. Шуңа күрә республика территориясен колачлый алырлык өч филиаллы төп реставрация үзәге төзү иң кулай вариант булыр иде. Вакытлар узу белән, мөгаен, илнең көнчыгыш төбәкләреннән экспонатларны реставрациягә нәкъ менә Татарстанга җибәрерләр.

**Әдәбият**

*Губина Т.А.* Опыт подготовки реставраторов музейных коллекций в рамках магистратуры «Реставрация историко-культурного наследия»« ИМО К(П)ФУ / А.Г. Ситдиков, С.Г. Буршнева, Т.А. Губина // Актуальные вопросы охраны и использования культурного наследия Крыма: материалы VI Всерос. науч.-практической конф., Евпатория, 30–31 мая 2019 г. / гл. ред. В.Е. Науменко. Симферополь : ИТ «АРИАЛ«, 2019. С. 232–239.

*Зверев О.В.* Об основных понятиях научной реставрации // Художественное наследие. М., 1989. С. 44–61.

*Муханов Г.С., Назипова Г.Р.* Национальный музей Республики Татарстан / Татарская энциклопедия: В 6 т. / гл. ред. М.Х. Хасанов, отв. ред. Г.С. Сабирзянов. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2008. Т. 4: М – П. 768 с., илл., карты.

*Новицкий А.И.* Музей изобразительных искусств Республики Татарстан / Татарская энциклопедия: в 6 т. / гл. ред. М.Х. Хасанов, отв. ред. Г.С. Сабирзянов. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2008. Т. 4: М –П. 768 с., илл., карты.

Министерство культуры Российской Федерации: [сайт]. URL: https://culture.gov.ru/about/departments/departament_gosudarstvennoy_okhrany_kulturnogo_naslediya/activities/attestation/ (дата обращения 19.02.2021).

Министерство культуры Российской Федерации: [сайт]. URL: https://culture.gov.ru/upload/medialibrary/89f/89fcb14aa228c00c6c2dc880513fab1e.pdf (дата обращения 19.02.2021).

Приказ Министерства культуры РФ № 474 от 05 мая 2012г. «Об утверждении Порядка проведения аттестации специалистов в области сохранения объектов культурного наследия (за исключением спасательных археологических полевых работ), в области реставрации иных культурных ценностей» // СЗ РФ. 2002. № 25. ст. 2519.

Приказ Минкультуры СССР от 17.07.1985 № 290 «Об утверждении Инструкции по учету и хранению музейных ценностей, находящихся в государственных музеях СССР» // https://base.garant.ru/70889800/

Приказ Министерства культуры РФ от 23 июля 2020 г. N 827 «Об утверждении Единых правил организации комплектования, учета, хранения и использования музейных предметов и музейных коллекций» // «Официальном интернет-портале правовой информации» (www.pravo.gov.ru) 6 ноября 2020 г. № 0001202011060011

Федеральный закон 54-ФЗ от 26.05.1996 г. «О Музейном фонде Российской Федерации и музеях в Российской Федерации» // «Собрание законодательства РФ», 27.05.1996, № 22, ст. 2591.

Федеральный закон 73-ФЗ от 25.06.2002 г. «Об объектах культурного наследия (памятниках истории и культуры) народов Российской Федерации» // «Собрание законодательства РФ», 01.07.2002, № 26, ст. 2519.

***Губина Татьяна Анатольевна,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты аспиранты*

УДК 801.8

*Ә.Т. Сибгатуллина*

# ТАТАР ГАЛИМНӘРЕНЕҢ ӘНКАРАДАГЫ МИРАСЫ ИГЪТИБАР СОРЫЙ

В Анкаре существует Институт исследования тюркских культур (ТКАЕ), учрежденный в 1961 году тремя видными учеными. Один из них татарский ученый профессор Ахмет Тимер (1913–2003) возглавлял институт с 1962 по 1975 годы, казанские и крымские татары входили в учредительный совет Института, финансовую помощь оказывал видный татарский благотворитель Ахмет Вели Менгер (1891–1978). Институт занимался изучением языка, литературы, истории, искусства тюркоязычных народов мира, выпускал журналы по этому профилю, проводил научные конференции и симпозиумы, готовил и издавал научные труды и сборники статей, посвященные известным тюркологам. Здесь были опубликованы книги многих видных татарских ученых, а также факсимильное издание книги Ш. Марджани, переводы на турецком языке прозведений Г. Тукая. В хранилище Института находится наследие татарских ученых, проживших в Анкаре большую часть жизни и завещавших свои библиотеки и архивы ТКАЕ. К сожалению, это наследие из-за финансовых проблем многие годы лежит в неописанном виде и хранится в коробках и мешках на третьем этаже неотапливаемого здания института.

**Ключевые слова:** татарские ученые за рубежом, Институт изучения тюркских культур, Ахмет Тимер, татароведение.

Ankara hosts the Institute for the Study of Turkic Cultures (TKAE), established in 1961 by three prominent scientists. One of them, Tatar Professor Akhmet Timer (1913–2003), headed the Institute from 1962 to 1975. Many Kazan and Crimean Tatars were members of the founding council, whereas financial assistance was provided by a prominent Tatar benefactor, Akhmet Veli Menger (1891–1978). The Institute engaged in the study of languages, works of literature, history and art by the Turkic-speaking peoples of the world; the Institute also published scientific journals, organised scientific conferences and symposia, as well as prepared and published scientific works and collections of articles dedicated to famous Turkologists. In particular, the Institute published books of many prominent Tatar scientists, as well as a facsimile edition of Sh. Mardzhani's book and translations of G. Tukay's works into Turkish. Today the repository of the Institute contains the heritage of Tatar scientists who lived in Ankara most of their lives and who bequeathed their libraries and archives to the TKAE. Unfortunately due to financial problems of the Institute this legacy has not been studied for many years; archival materials are currently stored in boxes and bags on the third floor of the unheated building of the Institute which poses a serious risk to the preservation of the documents.

**Keywords:** Tatar scientists abroad, Institute for the Study of Turkic Cultures, Akhmet Timer, Tatar studies.

Төркиянең башкаласы Әнкарада Төрек тарих курумы, Төрек тел курумы, Әнкара университеты тел, әдәбият, тарих һәм география факультеты кебек рәсми оешмалар Казан татар галимнәре белән

бәйләнешле истәлекләрне саклый, шәһәрнең Каршыйака муниципалитетына караган зиратта гына да никадәр мөһаҗир татар зыялысы күмелгән: монда Уганнар, Акышлар, Кошайлар, Дәүләтшаһлар, Өзәрләр, Одарлар һ.б. гаиләләрнең каберлекләре бар. Бүгенге көндә башкалада яшәгән татарлар, Г. Тукай урамында урнашкан Казан культура һәм ярдәмләшү дәрнәге (җитәкчесе Фуат Тениш) бу каберлекләрне чистартып-карап тора. Шактый актив иҗтимагый тормыш алып баручы дәрнәк әһелләренең дә бик белеп бетермәгән (бәлки дә белеп тә, ишеген ачтырып керә алмаган) татар мирасы тупланган тагын бер гаҗәеп оешма бар Әнкарада, ул Төрки культураны өйрәнү институты исемен йөртә, төрекчәсе: Türk Kültürünü Araştırma Enstitüsü (ТКАЕ – алга таба шулай биреләчәк). Бу оешмага нигез салучы һәм дистәләрчә еллар анда эшчәнлек алып баручылар арасында безнең якташларыбыз, күренекле тюрколог галимнәребез булган һәм күбесенең китапханәсе яки архивы да шушы институтта саклана, тик, ни кызганыч, әлегә кадәр ул мирас тәртипкә китерелмичә, өйрәнелмичә төргәкләрдә, капчыкларда ята бирә. Татарстандагы рәсми һәм иҗтимагый оешмаларның әлеге мәсьәләгә игътибарын җәлеп итү максатында, бу язмада кыскача ТКАЕның тарихы, эшчәнлеге һәм хәзерге халәте турында мәгълүмат[1] бирүне кирәк таптым.

Институт 1961 елда өч зур галимнең инициативасы белән җәмгыять файдасына гыйльми хезмәтләр башкару максатында төзелә: мөдир булып азәрбәйҗан профессоры Абидин Итил (1910–1980), мөдир ярдәмчесе итеп профессор Осман Нәдим Туна (1923–2001), генераль секретарь итеп Казан татары профессор Әхмәт Тимер (1913–2003) билгеләнә. Бу өч шәхеснең тырышлыгы белән фәнни-эзләнү институты ачарга дәүләттән рөхсәт алына һәм 1961 елның 1 ноябрендә чыккан карар нигезендә ТКАЕ рәсми рәвештә теркәлә. Оешма төрки халыкларның теле, әдәбияты, тарихы, этнографиясе, сәнгате белән бәйле булган эзләнүләр алып бару, гыйльми хезмәтләр бастыру, конференцияләр оештыру белән шөгыльләнергә, ул вакытта әле бер хыял гына булган СССР да яшәгән төрки халыклар вәкилләре белән фәнни багланышлар булдырырга планлаштыра. Институтның шигаре исә Мостафа Кәмал Ататөрекнең «Тормышта иң ышанычлы ориентир – фән», дигән сүзләре була.

1962 елда ТКАЕ оештыручыларыннан санскрит белгече Абидин Итил белән шумеролог Осман Н. Туна, башка җиргә күчү сәбәпле (мәсәлән, О.Н. Туна Америкага эшкә/укырга китә), институт җитәкчелегеннән аерылалар, мөдир булып Әхмәт Тимер кала һәм 1974 елның ахырына кадәр әлеге вазифаны башкара. Бу еллар институтның иң уңышлы эшләгән чоры дип әйтергә була. ТКАЕ әгъзалары арасында Казан татарлары, башкортлар, Кырым татарлары арасыннан чыккан галимнәр дә мөһим роль уйный: башкорт Габделкадыйр Инан (1889–1976), кырым татарларыннан Хәниф Алтан (1905–1963), Хәлил Иналҗык (1916–2016), Кәмал Ортайлы (1909–1963), татарлардан

[1] Бу мәгълүматның күпчелеген ТКАЕның элеккеге мөдире профессор Дурсун Йылдырымнан алдым һәм моның өчен аңа үземнең тирән рәхмәтемне белдерәм.

Хәмит Зөбәер Кошай (1897–1984), Әкъдәс Нигъмәт Курат (1903–1971), Надир Дәүләт (1944–2021) һ.б. Әгъза-корреспондентлар арасында исә Казан һәм Кырым татар зыялыларыннан Сәгадәт Чагатай-Исхакый, Абдулла Баттал Таймас, Мәхмүт Таһир, Тамурбәк Дәүләтшин, Әдигәй Кырымал, Осман Баубәк һ.б. шәхесләр бар.

Үз бинасы булмаганга, институт башта дәүләттән килгән аз гына акчага Тунис урамындагы бинага аренда түләп яши, бу акча җитми башлагач, татар хәйриячесе Әхмәт Вәли Мәңгәр (1891–1978) матди ярдәм күрсәтә. Әхмәт Тимерне Гамбург университетына эшкә чакыргач, 1975 елдан институт мөдирлегенә күренекле тюрколог профессор Шөкрю Әлчин (1912–2008) килә. Бина арендасы даими үскәнгә, институт Әнкараның Бахчелиевләр мәхәлләсендәге бер йортка күченә. Бу бакчалы йортның хуҗалары бертуган укытучы ханымнар, үзләренә квартира алып бирү шарты белән, әлеге йортны институтка бирәләр. Басылган китап-журналларны, ул елларда эшләгән Зыя Гёкальп медальонын саткан акчага ТКАЕ шулай итеп үзенең мөстәкыйль бинасына һәм хәтта кечкенә генә бер китап кибетенә ия була. Бүген дә институт ошбу адреста эшли: Bahçelievler, 69. Sokak, № 38. Институт җитәкчелеге, кулындагы матди мөмкинлекләрен туплап, яңа бина салу эшенә керешә һәм 2006 елда офислары, китапханәсе, уку залы, конференцияләр уздыру өчен 110 кеше сыйдырышлы зур салоны һ.б. мөмкинлекләре булган бер фәнни-тикшеренү үзәге төзелә.

2000 елларга кадәр институт азмы-күпме дәүләттән матди ярдәм алган булса, аннан соң бу ярдәм дә бетә, шуңа күрә үз хәлен үзе күрергә мәҗбүр булган оешма китап сатудан, бинаның бер өлешен арендага бирүдән һәм ТКАЕ әгъзаларыннан кергән взнослар хисабына яши. 2006 елдан 2021 елның августына кадәр ТКАЕны Рәшид Рәхмәти Аратның укучыларыннан берсе – профессор Дурсун Йылдырым җитәкли. 1980 еллар башында Казанга килеп, Ә. Кәримуллин, И. Надировлар белән танышып-дуслашып калган Д. Йылдырым, Әбрар абыйның үтенече белән, Ш. Мәрҗанинең ике томлык «Мөстафад әл-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар» әсәренең факсимиле басмасын ТКАЕ да нәшер итү мөмкинлеген таба (1992). Бу төр факсимиле китап бастыру башка булмаганга, Мәрҗани әсәре институт эшчәнлегендә бердәнбер очрак булып тарихка кереп кала.

Институт ачылган елны ук *Төрки культура* (Türk Kültürü Dergisi) исемле айлык журнал чыгара башлый һәм бу эш 2007 ел азагына кадәр туктамый. Аның дәвамы булып *«Төрки культураны өйрәнү»* (Türk Kültürü Araştırmaları) журналы оеша. Өченче журнал «*Cultura Turcica»,* инглиз, алман һәм француз телләрендә мәкаләр бастырып, тюркология өлкәсендәге яңалыкларны, табышларны гыйлем дөньясына танытуны максат итеп куйса да, озын гомерле булмый, берничә саннан соң чыгудан туктый. Финанслау бик авыр булганлыктан, *Türk Kültürü Araştırmaları* дә, кызганычка каршы, инде чыгудан туктаган.

ТКАЕның иң мөһим гамәле итеп нәшрият өлкәсендәге эшчәнлеген, А һм Б серияләрендә чыккан фәнни һәм фәнни-популяр хезмәт-

ләрне күрсәтергә кирәк. Аеруча әһәмиятле А сериясендә Төркиядән читтә яшәгән төрки халыклар хакында 150 ләп китап бастыру институтның гаять җитди казанышын дәлилли, А сериясендә нәшер ителгән китаплар арасында якташларыбыздан Абдулла Баттал Таймас, Әкъдәс Нигъмәт Курат, Рәшит Рәхмәти Арат, Адилә Айда, Хәмит Зөбәер Кошай, Надир Дәүләт кебек татар галимнәренең хезмәтләре бар. Шулай ук профессор Фатма Өзкан тарафыннан әзерләнгән Габдулла Тукай әсәрләренең төрекчә тәрҗемәләре җыентыгы да татар белеме өлкәсенә кертелгән кыйммәтле өлеш булып тора. В сериясендә чыккан китаплар иллегә якын булып, Төркия төрекләренең фәнни проблемаларына кагылышлы темаларга багышланган.

Институтта басылган мөһим китаплар арасында дүрт томлы «Төрки дөнья» исемле белешмәлекне күрсәтергә кирәк. Хезмәтнең 1972 елда бер китап рәвешендә генә чыккан тәүге басмасы, 1992 елгы икенче басмасында киңәйтелә. Беренче томы – төрки халыкларның географиясе һәм тарихы, икенче томы – теле, мәдәнияте, сәнгате, өченче томы – төрек әдәбияты, дүртенче томы Төркиядән читтә яшәгән төрки халыкларның әдәбияты турында язылган материалларны үз эченә ала. Икенче томдагы тел өлкәсендә язылган мәкаләләрнең авторлары арасында, мәсәлән, Әхмәт Тимер һәм Рәшит Рәхмәти Арат исемнәре бар [Türk Dünyası El Kitabı, 1992].

Институт китапханәсендә илле меңнән артык китап тупланган. Бу китаплар бары тик төрки халыкларның мәдәнияте, теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате хакында булып, алар арасында дөньядагы төрки телдә сөйләшүче төрле халыклардан килгән китап-журналлар да саклана. Аларның бер өлешен Әхмәт Вәли Мәңгәр кемнәрдәндер сатып алып, институтка биреп калдырган булырга тиеш. Рәшит Рәхмәт Аратның шәхси әйберләре: эш өстәле, скрипкасы, тавла уенының да институтка калуы билгеле. Моннан тыш, Рәшит Рәхмәти Арат белән Хәмит Зөбәер Кошайдан калган китаплыклар да ТКАЕда саклана, бүгенгә кадәр ул мирас тасниф ителмәгән (опись ясалмаган) хәлдә. Бу китапханә һәм архивның төп «хуҗасы» булып, институт корылган еллардан башлап секретарь да булып эшләгән татар ханымы Сәйдә апа Арсланбәк санала. Кызганычка каршы, соңгы елларда Альцгеймер авыруына юлыккан Сәйдә ападан инде бу рухи байлык турында бернинди мәгълүмат та алып булмый.

Китапханәнең уку залы булса да, бүген файдаланылмый. Мәдәният министрлыгыннан ярдәм булмаганлыктан, китапханә ачык түгел. Гомумән, институт үзе дә елына бер-ике тапкыр уздырыла торган гомуми җыелышлар һәм конференцияләр вакытында гына ачыла кебек, чөнки бина ягылмый, җыештырып-карап торучы хезмәткәрләргә түләргә акча юк, җитәкчелек һәм әгъзалар, нигездә, пенсиядәге тюркологлар. Ягылмаган бинага, кышын түгел, җәен дә килеп эшләп утыру җиңел түгел. Иң кызганычы – югары катта саклана торган архив: монда төрле магнитофон язмалары, кулъязмалар, истәлекләр, шигырь дәфтәрләре, көндәлекләр булып, җитәкчелек беркемне дә кертми һәм күрсәтми,

сәбәбе – материалларның рәсми рәвештә теркәлмәве, монда эшләргә риза булырдай архивариусның юклыгы, аңа түләрлек хезмәт хакының табылмавы. Архивта төрле җирләрдән килгән, бүләк ителгән шәхси коллекция дип атарга мөмкин булган чыганаклар саклана, тик кемнән нәрсә килгәнен дә инде җитәкчелек хәтерләми. Бу язманы әзерләгән вакытта Д. Йылдырым-бәйгә архив турында тулырак мәгълүмат сорап мөрәҗәгать иткән идем, ул институт хезмәткәре Али Җандәмир белән берлектә архив саклана торган катка кергән, ягылмаган бинада коточкыч суык булганга, бары тик ике тартмадагы кәгазьләрне генә карап чыга алган. Кулына беренче эләккән язмаларның (Мәхмүт Таһирның архивыннан булса кирәк) бер шигырь дәфтәре, иске хәрефләр белән язылган кулдан караламалар, Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» әсәрен алып карый алган. Картон тартманың тышына «Казанлы хәйрияче эшкуар Әхмәт Вәли Мәңгәрдән (Аллаһ рәхмәт әйләсен)» дип язылган булуын әйтте. Кыскасы, бу төргәк һәм тартмаларда татар халкының газиз мирасы саклануында шөбһә юк.

ТКАЕ белән бәйле тагын бер татар шәхесен искә алырга телим: ул – Себер татарларыннан чыккан шагыйрь Әсфәндияр Чынбай (Исфәндияр Ишгай) (1908–1992). Бөек Ватан сугышы чорында әсирлектә калып, «Идел-Урал» легионына кергән, төрле михнәтләр күргәннән соң, Әсфәндияр әфәнде 1949 елда Төркиягә килеп урнашкан. Тәүфикъ Әйди 1990 еллар башында аның белән күрешкән һәм үзенең китабында бу турыда телгә алган иде [Әйди, 1994, б. 35–40]. Әсфәндияр Чынбай Төркиядә өч китап бастырган, Сәйдә ханым Арсланбәкнең хәбәр итүенә караганда, үлгәнче дүртенче китабын да басмага хәзерләп бетерергә тырышкан булган, ләкин җитешә алмый калган. Гомеренең соңгы елларында аның ТКАЕда эшләве һәм үз китапларын да шул архивка калдыруы билгеле. Әсфәндияр Чынбай 1992 елның 16 июнендә Әнкарада вафат булган. Бу турыда матбугатта хәбәр бастырган Сәйдә апа Арысланбәк аны «һәрвакыт сабыр, иманлы һәм Төркиядә яшәве өчен бик бәхетле иде», дип искә ала [Арысланбәк, 1992].

Хәзерге вакытта ТКАЕ белән күренекле профессор Әхмәт Биҗан Эрҗиласун идарә итә. Күптән түгел генә институтның интернет сайты барлыкка килде: https://turkkulturu.org.tr

**Әдәбият**

*Арысланбәк С.* Әсфәндияр Чынбай // Шәһри Казан. 1992. 3 октябрь.

*Әйди Тәүфикъ.* Кардәшләр кочагында. Сәяхәтнамә // Казан утлары. 1994. № 9. Б. 3–84.

Türk Dünyası El Kitabı. İkinci Cilt. Dil, Kültür, Sanat. Ankara, İkinci Baskı. 1992.

*Мәкалә «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасының 3.19 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Сибгатуллина Әлфинә Таһир кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, Росссия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 801.83

# «ХАЛКЫМ ҖЫЛЫСЫН ТОЕП...»
## *(Гаяз Исхакыйның соңгы көндәлек дәфтәрләреннән)*

В сентябре 2018 года, к 140-летию со дня рождения классика татарской литературы Гаяза Исхаки, организатором фонда «Аяз Тахир (Туркестан Идель-Урал)» доктором Туляй Дуран (Турция) были переданы в дар ЦПМН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ богатое наследие писателя, в том числе и дневники. Вниманию читателей предлагается одна из его последних работ. Рукопись датирована «Октябрь, 1953 г.» и подписана самим автором как «18-ая тетрадь из «Стамбульского дневника воспоминаний». Заметки сделаны из больницы, куда писателю приходилось многократно обращаться в связи с ухудшением своего здоровья. Представленная публикация впервые вводится в научный оборот.

**Ключевые слова:** Г. Исхаки, Турция, дневники, история, биография.

In September 2018, on the occasion of the 140th anniversary of the birth of the classic of Tatar literature Gayaz Iskhaki, the organizer of the Ayaz Takhir (Turkestan Idel-Ural) fund, Dr. Tulyai Duran (Turkey), donated a rich writer's legacy, including the diaries. One of his latest works is offered to the attention of the readers. The manuscript is dated «October 1953» and signed by the author himself as «the 18th notebook from the Istanbul Diary of Memories». The notes were taken from the hospital where the writer had to go repeatedly due to the deterioration of his health. The presented publication is introduced into scientific circulation for the first time.

**Keywords:** G. Iskhaki, Turkey, diaries, history, biography.

13 октябрь көнне миннән аз-аз булса да кан алдылар. Шуңарга күрә хасталыгымның нигезе канымда булырга кирәк дигән бер фикергә килдем. Докторлар чынлап та шулай икәнне сөйләделәр. 5 октябрь беренче мәртәбә канымны алып тәхлил итдекләре[1] вакыт минем канымдагы кызыл хөҗрәләр[2] ике миллион тукыз йөз мең күрелгән. Вә халәнки[3], исән-сау кешедә ул дүрт миллион булырга кирәк икән, димәк, минем канымның дүрттән берсе җитешми – андый хәлдә ак хөҗрәләр куәтләнеп китәләр дә, кызылларын ашарга тотыналар вә кан, табигый хәленнән чыгып, үлемгә сәбәп буладыр. 13 октябрьдәге кан тәхлилендә[4] бу кызыл хөҗрәләрнең өч миллион йөз илле меңгә җитүе күренгән. Димәк ки, бер атнада хастаханәдә ике йөз илле мең яңа кызыл хөҗрәләр яратылган. Бу бер казаныш, затән[5], үз-үземне хәсән[6] итүдән бераз җиңеллек сизә идем, аз булса да иштиһам[7] да вә арткан иде. Шул көнне өемә китеп килдем, өйдә тавык чорбасын[8] сөеп ашадым, өстенә ике канат, бер муен да кимердем, һичбер авырлык сизмәдем. Бик тәмле иттереп карбыз да ашадым, каһвә дә эчтем,

[1] Тәхлил итдекләре – анализ ясаулары.
[2] Хөҗрә – күзәнәк, бу очракта тәнчек.
[3] Халәнки – чынлыкта.
[4] Тәхлил – анализ.
[5] Затән – нигездә.
[6] Хәсән – яхшы.
[7] Иштиһам – ашыйсы килү теләгем.
[8] Тавык чорбасы – тавык ашы.

сәгать 4 тә чәй дә эчтем. Күңелем ачылып, хастаханәгә төшеп яттым. Сеңерләрем дә, Аллага шөкер, ятышып килә.

*Октябрь, 1953, хастаханә*



Г. Исхакый көндәлегеннән. 18 нче санлы Истанбул хатирә дәфтәренең беренче бите

Бүген руслар тарафыннан Казан алынуның 401 ел тулган көне – безнең милли кайгы көнемез. Мин хаста булганга, дуслар-иптәшләр бу матәм көненә тупланып, милли шәһидләрнең рухына бер дога кыла алмадылар. Гомумән, мин төртеп-тартып йөретмәгәндә, милли эшләремез бик авыр бара.

Доктор Исмәгыйль Зыя[1] килеп, күңелемне күтәрә торган сүзләр сөйләде. Үземез монда тәшхыйсләр[2] тәмам булгач, Бакыркөйдәге үзе хезмәт итә торган хастаханәсенә чакырды. Хәл алырсың, диде. Китәрменме-юкмы – чакыруы зур эштер. Хәмид Зөбәер[3] бәктән мәктүб алдым. Кәмал Локман[4] бәктән дә гайне рәвештә хат алдым. Бик күп һәмшәһриләр[5] килде-китте, мине ялгыз үз башым калдырмадылар. Халыкның җылы дустлыгы безнең кебек халык юлында хаста булганнарга мәгънән шифалы дару кебек буладыр. Ашау-эчүне генә юлга куя алмыйм.

*15 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

Көнем бик авыр кичте. Докторым бүген рентген алачак булганга – кичтән йомшартыр өчен бер дару бирде, иртә берлә карынны юарга кушты, шул әмерен һәмширәгә дә сөйләде. Иртә берлә миңа каһвә бирмәделәр. Мин дә, мигъдәм[6] бераз йомшарганны күреп, һәмширәгә һәм тизрәк инәләремне ясарга һәм дә карын юуны ашыктырырга үтендем. Вакытында боларның берсе дә эшләнмәгәнгә, карын юучы хезмәтчене эзләдем. Беркем дә килмәде. Менә мине рентгенга чакырдылар. Лаваҗ[7] дә ясамаенча, инәләремне дә алмаенча, рентген

[1] Доктор Исмәгыйль – Исмәгыйль Зыя Терегул.
[2] Тәшхыйсләр – анализлар.
[3] Хәмид Зөбәер – Хәмид Зөбәер Кошай (1897–1978).
[4] Кәмал Локман – (1899–1976), югары нефть инженеры.
[5] Һәмшәһри – якын, якташ.
[6] Мигъдәм – ашказаны.
[7] Лаваҗ – эчәкләрне юдырту.

бүлмәсенә мендем. Анда дүрт-биш доктор, берничә читтән килгән танышлары – докторлык берлә һичбер мөнәсәбәте булмаган – коры сөйләп торалар, бертуктамаенча ишек ачылып, берсе арты берсе – әле бер хатын, бер ир кеше – кереп, сүзгә кереште. Кайберләре ишек төбендә тупланып торалар, алар янына әллә кемнәр керә. Һәмширә керә яки доктор килә, бер доктор чыга иде. Рентген бүлмәсе бер хан бүлмәсе хәлен ала иде, ул да булмады, берсе керде, докторлардан берсе берлә күреште, күрешкән доктор да үзе башка докторлар берлә таныштыру вә бу кешедә корчаңгы булуын сөйләде. Ике доктор безне утырган йиребездән калдырып, корчаңгыны карадылар, аңа рецепт биреп чыгардылар, бер хатын биш-алты яшьлек баласын алып керде. Баланы рентгенга алдылар, рәсмияне яздылар, чыгардылар. Тагын бер хатын килде. Халык кереп торды. Биш-алты доктор. Өч-дүрте һаман лыкырдып, шаулашып сөйләшеп тордылар. Берәр сәгать вакыт кичте. Миңа сира[1] килде. Тишендем, рентгенга кердем. Тәмсез ак нәрсә эчәргә бирделәр. Бинийая куе ясалган. Тегеләргә караганда бик авыр эчелә иде. Мең бәла берлә көчкә генә бер стакан эчтем. Шуны бетәрбетермәс рентген алуы кирәк иде. Доктор иптәшләре берлә мәгънәсез сүзләргә тотынды. Биш-ун дәкыйка[2] вакытны бушка йибәрде. Рентген алырга кирәклеге хәтеренә төште. Ак нәрсә агып беткән икән, тагы стакан эчерттер, диде. Мең бәла берлә эчтем. Агып йитүеннән элек рентген фильмасы чикте. Тагын лыгырдарга тотынды, тагы теге зыкым агып бетте, өченче стакан тагын китерделәр. Тагын эч. «Бу юлы сезнең тотышыңыз бетсен дип көтәм. Моннан элек ике стаканда һәрбер аш бетә иде һәм дә зыкым бу кадәр авыр булмый иде. Сез, сүзгә мавыгып, мине онытасыз, – дидем. Доктор бераз оялды булырга кирәк. Бу юлы берсе арттан берсе бер-ике-өч фильма чәкде[3]. Биш-ун дәкыйкадән соң тагы бер стакан эчереп, фильма алды. Тәмам, диде, китимме, дидем. Китегез, диде. Киттем. Мин һеморроемны карарга башка бер доктор көтеп тора икән, ул мине туктатып, әлләниләр тыкты. Янындагы докторларга: «Эчтә бер каты нәрсә бар, тирән керергә манигъ була[4]. Икенче мәртәбә карарга кирәк, – диде. – Сәгать уникегә кил», – диде. Котылдым дип торсам, тагы рентгенга чакырдылар, бишенче стакан эчертеп, тагы берничә фильма чәкделәр. Аллага шөкер, котылдым, ләкин мәгъдәмдә биш стакан, ул тулган иде. Карынымны юдырырга теләдем. Чәй вакыты җитте. Чәй эчәр өчен хезмәтчегә чалам[5], килмәделәр, тагы чалам, тагы юк. Тагы чалам, тагы юк. Карасам, безнең зилне[6] бозып киткәннәр, сәгать дүрт ярым булды, биш булды. Кемне дә таба алмадым. Биш ярымнарда бер кызны табып,

[1] Сира – чират.

[2] Дәкыйка – минут.

[3] Фильма чәкде – рентгенга төшерү.

[4] Манигъ була – тыела.

[5] Чалам – дәшәм.

[6] Зилне – звонок.

мең бәлаләр берлә бер бардак[1] чәй китертә алдым. Шулай итеп, авыр көнем үтте, хәерле булсын.

*6 октябрь, 1953, Хасәкә хастаханәсе*

Фильмам хакында мәгълүмат бирмәделәр. Фильмалар мондагы докторларны канәгатьләндермәгән. Тагы бер мәтәбә чигәчәксез, диделәр. Ләкин мин Мөхлис исемендәге рентгенчыга ышанычым бик аз. Вазыйфаи-шинаслыгы да юк. Һеморрой хакында калын багырсакта[2] каты-каты сөял сыман кабырчыклар бар диелгән, алар да кан сызуга сәбәп булу ихтималлары булырга кирәк.

Рәсулзадәдән[3] безнең шивәләрдә сөйләшүгә каршы бер протест кәгазе килде. Шуңарга минем дә имзамны эстәгәннәр. Имзаны аттым. Шуны «Милли байрак»ка да җибәрергә булам. Ибраһимга озын хат яздым. Кәефем уртача, бүген Җәгъфәр углы берлә Октай[4], башка беркем килмәде. Сәгадәткә хат яздым.

*Октябрь, 1953, Хасәкә хастаханәсе*

Бүген базар мөнәсәбәте берлә зиярәтчеләрем шактый күп булды. Гайшә ханым тавык чорбасы китерергә булды. Гали Чистайлы Хәлимә ханымнан мәктүб берлә үзе пешергәнне китерде. Окай Әйналыларга мәктүб язарга кушкан идем, генерал әллә ниләр караштырып, Мюнихта калдырган кешеләремезе дә яманлап, бер нәрсә язып китерде. Моның рухында һәркемгә бер дошманлык бар. Мәктүбен җибәрмәдем. Үзем Ибраһимга бер озын хат яздым. Хәмид берлә Локманга икесенә бер хат күндереп, хәлем авырайса, васыятем буенча аларны тәгъйин итдекем[5] өчен, көнлек хатирә дәфтәрләремне тәслим[6] өчен, берсенең килүен риҗада[7] булындым. Сәгадәткә хат язып, ректорлыкыннан мондагы ректорга бер кәгазь яздырып, мине профессор кызның атасы булу сыйфаты илә хастаханә өчен түләтмәүләрен тәэмин итәргә тырыш, дидем. Көнем авыр, күңелсез кичте. Закир Кадыйриларга[8] хат яздым.

*18 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

Бүген шәһәргә чыгарга изен[9] алдым. Ун сәгатьтә чыгып, Сәдад бәк хастаханәсеннән рецепт язылган ике төрле алтышар ампуллары алдым. Сәдад бәк булмаганга, тулы бәясен, ун лира түләдем. Алардан Садри бәкләргә телефон әйтеп, сезгә ашка киләм, дидем. Алар да чакырдылар, 12 ләрдә аларга бардым. Гүзәл бер татар чорбасын,

---

[1] Бардак – чынаяк.

[2] Багырсакта – эчәктә.

[3] Мәхмәд Әмин Рәсулзадә – (1884-1955) – күренекле азәрбайҗан сәяси эшлеклесе, әдәбият галиме, язучы.

[4] Октай бәй – медицина докторы.

[5] Тәгъйин итдекем – билгеләвем.

[6] Тәслим – тапшыру.

[7] Риҗада – үтенү, сорау.

[8] Закир Кадыйри (1878–1954) – гарәп теле белгече, журналист, публицист, тәрҗемәче.

[9] Изен – рөхсәт.

бер табак солы, алты кечкенә көфтә[1], беразда булгур пылавы, аннан соң шактый күп йөзем ашадым, хастаханәгә кергәннән бирле бу кадәр иштиһа[2] илә бу чикле аш ашаганым юк. Аштан соң каһвә дә эчтем. Бу ашлар нә ашказанымда, нә дә эчемдә бер авыр ясамады. Сәгать өчләрдә алардан чыгып, иртәгә ясалачак рентген өчен фильмалар даруларын алдым, тугыз лира 60 грош түләдем. Аннан соң өемә кайтып чәй эчтем. Кирәкле әйберләремне алып, сәгать җидедә хастаханәгә дүндем. Өемдә «Париж блок»тан бер хат таптым. Көнем күңелле кичте. Иртәгә икенче мәртәбә рентген фильмасын алачаклар.

*19 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

Иртә берлә иртәнге каһвә бирмәделәр. Рентгенга кадәр ач калырга тиеш. Эчне юар өчен лаваҗ ясадылар, ләкин эчтән күп нәрсә чыкмады. Сәгать 12 яртыда гына рентгенга чакырдылар, рентген докторы: «Торыңыз, әүвәле эчеңез бушаганмы, шуны карыйм, – дидем. Рентген машинасының аркасына бастырды, эчне карады. 16 октябрьдә эчкән ак матдә эчәктә туп-тулы... Рентген алдыруым өченче мәртәбәгә кичектерелде. Ягъни ике атнада адәм гакыллы бер фильм ала алмадылар. Моңарга кәефем төште. Гайшә ханым бик тәмле тавык чорбасы, тавык канатлары, тавык муены китерде. Аны кайнарлата сөя-сөя ашадым. Көн күңелсез кичте. Беркем дә хәлемне белешергә дә килмәде. Иртәгә эчемне юачагымыз, диделәр. Бу эшне дә җаһил хезмәтчеләргә эшләткәнгә, әллә нинди яңа-яңа хасталыклар ашламасыннар диеп куркам да, Тәңре ярдәмчем булсын.

*20 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

Эчемне бик тирәннән юдырдым. Шактый бушанып калдым. Үземдә җиңеллек тойдым. Нияз Максудига,[3] Хәмид Рәшидкә[4] мәктүбләр язып, «Америка тавышы»ында төрек-татар ләһҗәләрендә сөйләүләр ник туктатылды дип җавап сорадым. Бүген зиярәтчеләр шактый күп килде. Фатих әфәнденең углы Гомәр килде. Шәһәр гайбәтләре юк икән. Сөйли алмады. Бер төрле даруымны китерергә булып китте, аннан соң Мәрьям ханым килеп чыкты. Аның өстенә Мәхмүд килеп чыкты. Аңарга «Америка тавышы»ның безнең телләрдә сөйләвен туктатуына хәзерләнгән протест язуы нөсхәләрен машинада арттырырга бирдем. Фатих бәкләргә барып чыгып, җомга иртәсе юынырга мөмкинме-түгелмене белешеп, хәбәр итәргә куштым. Акчасызлыктан зарланды да үзенә 10 лира сәдака бирдем. Аннан соң Нурулла бәк килеп чыкты. Ул да кәефсез икән. Аның берлә озын гына сөйләшеп утырдык, бергә чәй эчтек, шулай итеп көн үтеп китте. Әнкарага Хәлим агага хат яздым.

*21 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

---

[1] Көфтә – котлет.

[2] Иштиһа – ашау теләге.

[3] Нияз Максуди – Троицк каласында мәдрәсә мөдире.

[4] Хәмид Рәшит – (1912–1964) – Г. Исхакый белән бәйләнештә тора.

Бүген һичбер үзгәреш булмады. Өйләдән соң Хәбибнең абзасы почта-телеграф мөһәндисе Рәхми бәк килеп чыкды. Аның берлә озын гына сөйләшеп утырдык. Ахшам йиймәкенә[1] доктор Октай үзләренә килергә докторлардан рөхсәт алган иде. Сәгать 6 ларда аларга киттем. Барышлый Япониядәге Хөсәен Биглитсига һәм дә Әнкарадагы Хәлимә ханымга берәр хат салдым. Октайларда ашка диеп Төркестанлы Забит Нигъмәтне хатыны берлә чакырганнар иде. Озын сөйләшеп утырдык. Ашлары сәгать сигездә генә бирелде, бик һәйбәт бер табак чорба ашадым, аннан соң бер порцион итле-кишерле бер табак пылау, берничә кашык йогырт, ике уртача кисәк кавын йийдем[2]. Каһвә, ике стакан чәй эчтем. Һичбер авырлык хис итмәдем. Сәгать 10 да гына хастаханәгә кайтып яттым. Яхшы йокладым.

*22 октябрь, 1953. Хастаханә*

Һич яңа нәрсә юк. Фильмамны алмаслар микән дип көткән идем, булмады. «Париж блок»тан килгән блокның низамнамәсен укып тасдикъ иттек[3]. Генералдан кыска гына бер хат яздырдым. Уны күндерттем. Мостафадан бер хат килеп чыкты. Солтан бу вакытка кадәр һичбер мәкалә язмаган, димәк аңарга ышануымыз да бушка чыгачак. Мостафа хатта Мюних радиосына Габдулла Атласи[4] киләчәк имеш, дип яза, ул да үзенә бертөрле хафаланырга тотынырмы, белмим. Мөхәммәд килеп чыкты. Төрек ләһҗәләрендә сөйләүне тuktату хакында протест кәгазен шөбһәләндереп китерергә кушкан идем – шуны китерә алмаган... Иртәгә, насыйп булса, өемә кайтып китәм. Бүген ашлар бик начар булды, тәмамән ач калдым.

*23 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

Бүген шимбә көн. Тышка чыгарга рөхсәт бирделәр. Өйдә тавык чорбасы пешерергә кушкан идем, шуны ашадым. Һәйбәт булды. Аннары Садриларга барып чәй эчтем. Сәгать 7ләргә Касыйм бәкләргә барып чыктым. Алар да ахшам йиймәке йийдем һәм ваннага кердем. Шактый керләнгән икәнмен. Бик һәйбәт юындым. Мин хамамнан чыкканда, доктор Исмәгыйль Зыя берлә Һидаять бәк[5] килгәннәр иде. Алар берлә чәй эчтек. Һидаять яңа хәбәр китергән. «Идел-Урал ярдәмләшү җәмгыяте» хакында полиция килеп мәгълүмат эстәмеш. Кирәк Исмәгыйль, кирәк Һидаять, кирәк Мәрьям ханым булсын, тәхкыйкать берлә җәмгыятемез ябылачак булса, Ләбибтән аерылуны рәсмиләштерергә кирәк, диделәр. Исмәгыйль бәк базар көне Садри бәкне күреп, аннан бераз юлларын өйрәнеп, дүшәмбе көн тупланып катгый карарга багларга булдылар. Мин Касыйм бәкләрдә кунып калдым. Касыйм бәк бераз хаста. Иртә берлә өемә кайтып киттем. Анда

[1] Йиймәкенә – ашавына.
[2] Йийдем – ашадым.
[3] Тасдикъ иттек – расладык.
[4] Габдулла Атлас – Япониядән килгән Габдулла Гаффар-Атлас.
[5] Һидаять Яшен – укытучы һәм журналист.

аш хәзерләүче килгән иде. Шул арада Хәсән килеп чыкты, бергәләп аш ашадык, сәгать икенче яртыда хастаханәгә килеп яттым. Идел белән Галим килделәр. Идел алма бәлеше китергән. Алар киткәч, алма бәлеше берлә чәй эчеп ятканда, Билал Газиз бәк килеп чыкты. Ул хастаханәдән ашыгып чыкмаска димләде. Үзем бик туйдым. Гомумән, ашлары үзе тәмсез, үзе суык булганга, бик быкдырды[1]. Закир Кадыйрилардан[2] 2 сеннән дә хат алдым. Мюнихтан соң бераз бугаз авырта. Ангин-фәлән була күрмәсен.

*25 октябрь, 1953*

Сәгадәттән бу атна һичбер мәктүб ала алмадым. Октайга да телефон карадым. Анда да бер хәбәр юк. Мин юкта Мирза Бала[3] белән Ибраһим килеп киткәннәр.

*25 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

26–27 октябрь көннәре эсселегем 37 дән бераз артты, нәшьәм[4] дә кимеде. Иштиһам да азайды. Бераз суык алдырдыммы? Әллә өч-дүрт көннән бирле дәвам итә торган кабзым[5] моңарга сәбәпче булдымы.

Бу көннәрдә зиярәтче дә аз булды. Гайшә ханым гына тавык чорбасы пешереп китерде, ләкин иштиһам аз булганга, аны да бик ашый алмадым. Шәһәргә дә чыга алмадым. Мәхмүд кенә килде, утардан гыйлаҗларны[6] алдырдым. Сәгадәттән мәктүб килеп җитте. Хастаханәдә яту акчасын бирүдән котыла алмаячакмыз дип җавап язды. 12 көн элек фильма алганда эчкән зыкым һаман чыгып бетмәгәнгә, шул да эсселек артуга сәбәп булгандыр. Хастаханәнең тәрбиясеннән, дарулау ысулыннан бик беттем. Ике көн берсе аркылы берсе мөсһил[7] алып мәгъдәмне бераз тәмизләдем[8] дип уйлыйм, бакалым, ни булачак. Бүген шәһәргә чыгарга уйлыйм. Генерал килми, ди. Ул монда яңа бер уен уйнарга маташа ахрысы.

*28 октябрь, 1953 ел. Хасәкә хастаханәсе*

28 октябрь Садри бәкләргә ахшам йиймәкенә җай килмәгәнгә, өйләдән соң хастаханәдән чыгып, өемә килеп чәй эчтем, иртәгә Төркиядә җөмһүрият игъланының утызынчы елы тулганга, шул бәйрәмне каршылар өчен, бик зур хәзерлек алып бара. Урам буйлап меңле-меңле электрик лампалары тагыла иде. Үзем өемдә булганда Конихолумнан мәктүб, Хәмид Рәшидтән бер мәктүб килеп чыкты. Хәмид Рәшит мәктүбендә Нью-Йоркта әзерләнеп, Идел-Урал истикъляль тәшкиләтен коруларын, ләкин аңарга иске мөһаҗирләрнең бик

[1] Быкдырды – туйдырды.
[2] З.Кадыйри (1878–1954) – гарәп теле белгече, публицист, тәрҗемәче.
[3] Мирза Бала (1898–1959) – язучы, «Мөсават» партиясе рәисе.
[4] Нәшьәм – кәефем.
[5] Кабзым – эч кату.
[6] Гыйлаҗларны – даруларны.
[7] Мөсһил – эч җибәрүче.
[8] Тәмизләдем – чистарттым.

аз катнашуларын язадыр. «Америка тавышы»нда төрки ләһҗәләрендә сөйләүне туктатуның сәбәпләре хакында җәмигъ мәгълүмат бирмидер вә халәнки[1] без шуның асыл сәбәпләрен беләсемез килә иде, ялгыз Мюнихтагы борадәр өчен Нью-Йорктан берничә кешенең имзалы булуын белдерде. Америка комитеты Нияз Максудка да Мюнихка барырга тәклиф иткән[2]. Ул үзе генә барырга риза булмаган, Габдулла Атлас, тагы берсе бер Мюнихка барамыз диеп мөрәҗәгать иткәннәр, ләкин әле мәсьәләләре хәл ителмәгән. Хәмид Рәшит, [...] Мюнихка килергә теләмәгәннәр. Конихолумның мәктүбен алып Садриларга киттем. Анда Рәшид бәк, Мөхәммәд керәсе барлар иде. Рәшид бәктән Конихолумның мәктүбен тәрҗемә иттердем. Конихолум иске заляләтендә – мәҗмуганы гарәп хәрефләре берлә чыгармакны – Идел-Уралларыны берлә берләштерегез дип тәкъдимдә булына – мәҗмуга акча ярдәме соравымызга әле мәҗмугалар хакында финанс карары бирелми, ди, бирелү берлә сез читтә калмассыз, дип өмет бирә. Үзенең Истанбулга килүе кичегүе күзгә ташлана...

Безнең милли хәрәкәтемездә сәлби[3] роль уйнаган гонсырларын алга сөрүдән ваз кичә алмыйлар. Конихолумга тәфсилле изахлы бер мәктүб язарга карар бирдем, ләкин шуны я русчага, я инглизчәгә тәрҗемә иттерүдә зәхмәт чиктем. Генерал русчаны яхшы кавраган[4], ләкин язуларында тәхкыйк,[5] бер эшне боза торган, берәр зөмрәне хөрмәтсезләндерә торган үзеннән бер нәрсәләр гыйлавә итмәенчә[6] калмый, шуңарга күрә аңарга ышанычым аз. Рәшид бәк инглизчә гүзәл яза, әмма эше бик күп булганга, бик озын сөрә. Мәсьәләне актуаль итәсе гаиб булып китәдер, шул мөшкелләтем бик зур. Акча берлә эшләтү бер яктан сер чыгу ягыннан хәтәрле, бер яктан акчамыз юк, хасталыгым да манигъ[7]. Шуңарга авырлык хис иттем. Садри бәктә бик һәйбәт аш ашадык. Камилә ханым, фәүкылгадә тәмле пилмән пешергән иде. Табак ярым ашадым, аннан соң үзенә бер ысулда кәбестә пешергән иде. Аны да ашадым. Үзем дә йидем, ахырдан ике стакан чәй дә эчтем, һичбер авырлык хис итмәдем, сәгать 11 дә генә өемә киттем. Таксим мәйданына килдем. Таксим мәйданы нурга күмелгән.

*29 октябрь, 1953. Хасәкә хастаханәсе*

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре* ***Гарипова Ләйлә Шамил кызы*** *әзерләде*

[1] Халәнки – чынлыкта.
[2] Тәклиф иткән – кушкан.
[3] Сәлби – кире.
[4] Кавраган – аңлый.
[5] Тәхкыйк – һичшиксез.
[6] Гыйлавә итмәенчә – өстәмичә.
[7] Манигъ – киртә.

УДК 81´28

*И.Б. Бәширова*

# ДИАЛЕКТОЛОГ ГАЛИМӘ ТӘНЗИЛӘ ХӘСӘН КЫЗЫ ХӘЙРЕТДИНОВАНЫҢ ФӘННИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Статья посвящена 80-летнему юбилею со дня рождения известного татарского языковеда Т.Х. Хайрутдиновой. В ней автор знакомит с разносторенней научной деятельностью ученого, а также делится со своими воспоминаниями, связанными с совместной работой в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан.

**Ключевые слова:** татарский разговорный язык, диалекты, говоры, татарский литературный язык.

The article is dedicated to the 80th anniversary of the birth of the famous Tatar linguist T.Kh. Khairutdinova. In it the author acquaints with the diverse scientific activities of the scientist and also shares with her memories associated with joint work at the Institute of Language, Literature and Art. G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan.

**Keywords:** Tatar spoken language, dialects, Tatar literary language.

Күренекле татар тел галимәсе Тәнзилә Хәсән кызы Хәйретдинованың тууына 2021 елда 80 ел тулды. Кызганыч ки, авторга үзенең «Табигать концепты: үсемлекләр дөньясы» дигән соңгы затлы китабын күрү насыйп булмады. Бу хезмәтнең нәшер ителүе (Казан: ТӘҺСИ, 2017, 384 б.) уңаеннан 45 ел буе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләгән, ел саен диалектологик экспедицияләрдә катнашып, биш монография, күпсанлы мәкаләләр язган, «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»н (Казан, 2009) төзүчеләрнең һәм җаваплы мөхәррирләрнең берсе булган танылган диалектолог, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты, өлкән гыйльми хезмәткәр Тәнзилә Хәсән кызы Хәйретдинованы зур хөрмәт белән искә алдык. Бу – Тәнзилә Хәйретдинованың күпсанлы туганнары, якыннары, дуслары-хезмәттәшләре өчен аеруча куанычлы гамәл булды.

«Табигать концепты: үсемлекләр дөньясы» монографиясе, авторның «Говор златоустовских татар» (Казань, 1985. 186 с.), «Названия пищи в татарском языке»(Казань, 1993. 142 с.), «Краткий русско-татарский словарь для работников общественного питания» (1995), «Бытовая лексика татарского языка» (Казань: Фикер, 2000. 128 с.), «Названия растений в татарском языке» (Казань, Фикер, 2004. 224 с.) хезмәтләре һәм күпсанлы үзе язган һәм редакцияләгән мәкаләләре кебек үк, диалектология фәне таләп иткән методология, ысул-алымнарга нигезләнеп иҗат ителә.

Аларның нигезе XX гасыр урталарында танылган телче, әдәбиятчы, тәнкыйтьче, олуг педагог Латыйф Җәләй (1894–1966) җитәкчелегендә салына. Галим тарафыннан «Диалектологик сораулыклар», «Диалектологик сүзлек»ләр төзелә, «Татар диалектология»се дәреслеге басыла (1947), докторлык диссертациясе яклана. Латыйф Җәләйнең күпкырлы эшчәнлеге аның туына 110 ел тулу уңаеннан дөнья күргән җыентыкта яктыртылды [Актуальные вопросы..., 2005]. Диалекталь лексиканы аерым тематик төркемнәргә бүлеп тикшерү эше Җәләй аганың талантлы укучылары Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтова һәм Нажия Борһан кызы Борһанова хезмәтләреннән башлана. Бу юнәлештә алар җитәкчелегендә күпсанлы монографияләр языла. XX гасырның 70–90 нчы елларында Башкортстан, Казакъстан, Үзбәкстан, Азәрбайҗаннан һ.б. төрки республикалардан татар диалектологлары янына киңәшкә киләләр, чөнки татар галимнәре төрки дөньяда әйдәп баручылардан санала.

Бу мәкаләдә Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих/сәнгать институтында ярты гасыр буена дус һәм фикердәш булган хезмәттәшем Тәнзилә Хәйретдинованың күп еллык фәнни эшчәнлеген яктырту максаты куелды.

Һәр җан исәбе алу кампаниясе башлану белән, Россиядә татар халкының язмышы һәм теле турында капма-каршы фикерләр кузгала. Шушы вазгыятьтә татарның телче, тарихчы, әдәбиятчы галимнәренә, гомумән, барлык зыялыларыбызга объектив дөреслекне җиткерү бурычы йөкләнә.

Казан ханлыгы басып алынгач, XVI гасыр урталарыннан татар халкы Мәскәү/Русия дәүләте составында көн күрүгә мәҗбүр ителә. Шагыйрь тасвирлаганча: *«Чабатасын киеп / Юкә биштәр асып / Безнең бабай киткән / Чукынудан качып / Урал якларына / Себер даласына / Иркен җирләр эзләп / Бала-чагасына / Озак айлар барган / Озын юлдан атлап / Озын уйлар уйлап / Татарлыгын саклап»* (Г. Афзал, 1990). Зур галим М.З. Зәкиев билдергәнчә: «Казан ханлыгын руслар алгач, татарлар яшәү өчен җанлы урыннардан куылалар, яисә христианлаштырудан куркып качалар, нәтиҗәдә, күп кенә җирләрдә татарның төрле диалект вәкилләре бер авыл төзеп яши башлыйлар. Мондый авыллар бигрәк тә Җаек елгасы буйларында күп төзелә. Шул авылларда болгар-татар халкының урта (биләр-казан сөйләше), көнбатыш (болгар-мишәр сөйләше) һәм җирле төбәктәге башка төрки телләр чагылыш таба торган гомумхалык теле, ягъни авыл койнесе оеша. Хәзерге вакытта бу сөйләшләрнең үзенчәлеге диалектологлар тарафыннан тикшерелә. Төрле сөйләшләрдән уртак гомумхалык телендә фольклор теле барлыкка килә» [Зәкиев, 1998, б. 538–541].

Төрле төбәктәге җирле сөйләшләрнең билгеле бер уртак яисә үзенә генә хас үзенчәлекләре нигезендә диалект дигән категория хасил итүе мәгълүм. Сөйләш һәм диалект төшенчә-атамалары синоним буларак та кулланыла («диалект – совокупность однородных говоров, обладающих относительным единообразием» [Ахманова, 1969, с. 131]).

Диалектолог галимнәр раславынча, диалектларның бер-берсеннән сизелерлек аерымлануы, татар халкының каяндыр көченеп килмичә, болгар-угыз-кыпчак кабилә сөйләмә телләренә нигезләнеп, гомер бакый үз җирендә яшәгәнлеген аңлата. Димәк, галимнәр һич тә телне таркатмый, киресенчә, халыкның бергә яшәве өчен зарури булганга, төрле сөйләш /диалектлардан барлыкка килгән гомумхалык теленең табигатен һәм вазифасын өйрәнә булып чыга. Мәгълүм булганча, әлеге гомумсөйләм уртак нигезе, гасырлардан төрки язма традиция белән кушыла барып, барлык төрки-татарларны, милләт буларак берләштерү көченә ия булган төрки-татар язма әдәби телен формалаштыруда, аны баетуда һәм саклауда мөһим терәк булып әверелә [Татар әдәби теле..., 2015].

Төрле төбәк сөйләшләреннән барлыкка килгән гомумхалык теленең табигатен һәм вазифасын өйрәнү барышында галимнәр гаять катлаулы эш башкара. Т.Х. Хәйретдинова үзенең беренче хезмәтендә анализның ничек баруы хакында болай дип белдерә: «Системное исследование названий пищи татарского языка проводится в совокупности диалектного материала с литературным, что дает возможность представить развитие слова в пределах одного языка, расширение или сужение его семантики. Такой подход к изучению лексики пищи позволяет судить о богатстве словарного фонда языка» [Хайрутдинова, 1993, с. 3]. Авторның фикерен күзаллау максатыннан бер мисал китерик: «...Понятие еда, пища в татарском языке выражается несколькими синонимическими единицами. Для передачи данного понятия в литературном языке употребляются слова: *ашамлык, азык, ризык, тәгам,* хотя с точки зрения семантики они несколько отличаются друг от друга». ...Алга таба әлеге сүзләрнең һәркайсы аерып алынып анализлана, башта рус теленә тәрҗемәсе бирелә: «Ашамлык – пища, еда, кушанье, съестное, характерно для большинства говоров татарского языка. В говорах употребляются еще следующие варианты»... дип, уннан артык сөйләшләрдән төрле вариантлары санала һәм нәтиҗә ясала: «Все приведенные здесь слова образованы от общетюркского глагола *ашау-* ‘есть’ при помощи различных аффиксов. Кроме того, сам глагол *ашау* в мензеленском, нукратовском, пермском говорах выступает в качестве существительного и обозначает еду, а в ичкинском говоре бытует еще в значении пить. В татарском литературном языке слово *аш,* словосочетания *аш-су, ашау-эчү*, в хвалынском *азык-су* имеют собирательное значение еда, пища, питание. В этом значении в говоре пермских татар употребляется слово *дәм: бер җыл ун көн дәм капмый йатты»* [Хайрутдинова, 1993, 5–6]. Димәк, башта *ашамлык* сүзенең хәзерге татар әдәби телендә синонимик парлары белән ничек итеп кулланылуы күрсәтелә, рус теленә тәрҗемәсе бирелә, аннан соң шул ук сүзнең татар теленең төрле сөйләшләрдәге вариантлары китерелә, ашамлык төшенчәсен белдерә торган берәмлекләрнең саны/мәгънәсе күбәю аңлашыла, аларның гомумтөрки нигездән үк мәгълүм вазифалары ассызыклана. Тикшерү

барышында һәр сүзнең мәгънәсе, Сәгыйть Хәлфин сүзлегеннән башлап, икетелле, аңлатмалы, диалекталь сүзлекләрдә орфографик һәм лексик-семантик яктан ни рәвешле теркәлүе күзәтелә. Кайбер сүзләрнең тарихи яссылыкта ничек файдаланылуы аерым төрки телләрдән, иске татар телендәге истәлекләрдән, халык авыз иҗаты әсәрләреннән мисаллар китереп ныгытыла. Хосусый тематик төркемнәргә бүленеп өйрәнелә торган һәр сүз, шушы система, тәртип-ысул нигезендә тикшерелә. Шуның белән бергә, җирле сөйләшләрне өйрәнү фәненә багышланган хезмәтне өстәл артына утырып яза башлаганганчы, ерак юллар урап, халык арасына чыгып, һәр сүзне сөйләүче авызыннан бөртекләп тупларга, ягъни информантлар белән уртак тел таба белергә дә кирәк булуы мәгълүм. Бу төр эшчәнлек татар халкын бүлгәлиме?!

Авторның «Табигать концепты: үсемлекләр дөньясы» дигән монографиясе дә шушы ук метод-ысулга нигезләнә, әмма, алдагыларыннан аермалы буларак, татар телендә языла һәм Концепт дип исемләнә, димәк, әлеге мәсьәләне аңлату да сорала. Т.Х. Хәйретдинова китабының керешендә, бу катлаулы проблемага багышланган күп хезмәтләрне, Ф.К. Сәгъдиеваның «Концепт труд в лексике и фразеологии» дигән мәкаләсеннән [Сагдеева, 2004] башлап барлый, үз мөнәсәбәтен белдерә: «Табигать белән кешенең бер-берсе белән бәйләнеше халык тарихында, аның милли мәдәниятендә, халык авыз иҗатында, мифологиясендә чагылыш таба. Табигать үзенең күптөрлелеге, байлыгы, сере, үзенә хас авазлары, моңы белән һәр кешенең күңеленә, йөрәгенә якын...». Бер уңайдан тикшеренүнең максатын билгели: «Әлеге хезмәттә, Табигать концептына кергән үсемлекләр дөньясы белән бәйле кайбер лексик берәмлекләр турында сүз алып барылыр. Үсемлекләр дөньясына караган лексик берәмлекләрдә предметлыктан бигрәк, төшенчәлелек чагылыш таба. Үсемлек атамаларына тасвирлама бирү зарур. Аннан соң аның мәгънә һәм мәгънә төсмерләрен бирү күздә тотыла. Халык сөйләшләрендә теге яки бу үсемлек атамасын белдерә торган синонимнары, вариантлары китерелә. Аннан халык авыз иҗатында (мәкальләрдә, сынамышларда һ.б.) һәм борынгы язма чыганакларда, матур әдәбиятта кулланылышы күрсәтелә һәм мисаллар ярдәмендә халыкның мәдәнияте, менталитеты белән бәйләнеше күзаллана». Бу аңлатуда Т.Х. Хәйретдинованың үзенә хас язу стиле, ягъни катлаулы мәсьәләне һәркем аңларлык хәлгә җиткерә белү үзенчәлеге һәм галим буларак тыйнаклыгы ачык чагыла. Әлеге хезмәттә дә өйрәнүдәге система эзлеклелеге төгәл саклана: Керештә үсемлекләр дөньясының нинди төркемнәргә бүленеп тикшерелүе хакында киң мәгълүмат бирелә. Тикшерелү тарихы күзәтелгәндә, табигать темасына караган кайбер лексик берәмлекләрнең Концепт мәгънәсендә, кандидатлык диссертацияләре буларак яклануы, ботаникларның флора өлкәсенә караган фәнни хезмәтләре, сүзлекләре санала; үсемлек атамаларының лингвистик яктан рус һәм мари телендә, барлык төрки телләрдә, татар тел белемендә ничек

анализлануы, төрле сүзлекләрдә ни рәвешле теркәлүе, фольклор әсәрләрендә чагылыш табу мәсьәләләре җентекләп аңлатыла [Хәйретдинова, 2017, б. 3–14].

Беренче бүлектә «Татар телендә үсемлек атамаларына лексик-семантик характеристика» дигән проблема ун төркемгә бүлеп тикшерелә: 1) үсемлекләрдә гомуми төшенчә белдерә торган лексемалар (үсемлек, агач, үзәк, урман, әрәмә, җиләк-җимеш, үлән, печән, курпы, чәчәк һ.б.); 2) үсемлек анатомиясенә караган лексик берәмлекләр; 3) агач һәм куак атамалары; 4) җиләк-җимеш агачлары һәм куак атамалары; 5) җиләк һәм җимеш үсемлекләре атамалары; 6) Үлән атамалары: а) шифалы үләннәр, дару үләннәре атамалары; ә) ашарга яраклы үлән атамалары; б) чүп үләннәре атамалары; 7) декоратив үсемлекләр атамалары:а) бүлмә гөлләре, чәчәкләре; б) кыргый һәм бакча гөлләре, чәчәкләр атамалары; 8) бакча һәм яшелчә үсемлекләре атамалары; 9) ашлык атамалары; 10) техник культуралар атамалары [Хәйретдинова, 2017, б. 15–337]. Югарыда әйтеп үтелгәнчә, Үсемлек дигән хәзинә-байлык Т.Х. Хәйретдинованың алдагы хезмәтләрендә файдаланылган метод-ысулларга таянып тикшерелә.

Әмма бу китапта, автор үзе ассызыклаганча, «Үсемлекләр дөньясына караган лексик берәмлекләрдә предметлыктан бигрәк, төшенчәлелек чагылыш таба» (6 б.). Предметлык һәм төшенчәлелек мәсьәләсе телдә сүзләрнең мәгънәсен, мәгънә типларын өйрәнүгә багышланган «Татар әдәби теле. Семасиология» хезмәтендә махсус аңлатыла. Әгәр дә сүз чынбарлыкта булган предмет, күренеш, билге һ.б. атамасы булса, реаль номинатив, конкрет-объектлы мәгънә тибы барлыкка килә. Бу очракта, мәгънә эчтәлегендә аның логик-предметлык (денотатив) компоненты зуррак (киңрәк) урын ала. Әгәр дә сүз чынбарлыкта булмаган, адәм баласының уй-фикерләве нәтиҗәсендә барлыкка килгән төшенчә/ мөнәсәбәтнең атамасы булса, сүзнең мәгънә эчтәлегендә аның контекстуаль, уй-фикерләү, абстракт-субъектлы мәгънә тибы барлыкка килә. Бу очракта, аның мәгънә эчтәлегендә төшенчәлелек (сигнификатив) компоненты зуррак (киңрәк) урын ала. Хәзерге лингвистикада лексик берәмлекләрнең мәгънә белдерүе тикшерелгәндә, аларның статик халәттә (сүзлектә теркәлгән) һәм сөйләмдә вакытындагы дип, ике нигездә каралуы, мәгънәне билгеләгәндә төп метадологик җирлек була. Бу юнәлештә, бер индивидуаль мәгънәгә ия булган сүзмәгънәнең, аерым төркем сүзләргә хас булган предметлык, процесслык, билгелек һ.б. **гомумиләштерелгән** грамматик чараларның үзенчәлеге (сүзформа) һәм сүзләрнең үзара бәйләнеше (сүзтезмә) нигезендә үзара бәйләнеш-мөнәсәбәте барлыкка килә. Әлеге гомумиләштерү, ягъни уй-фикер эшчәнлеге, лексик берәмлекнең логик-предметлык (денотатив) өлешен тарайта, төшенчәлелек (сигнификатив) компонентын киңәйтә [Бәширова, 2010, б. 8–30]. «Үсемлекләр дөньясына караган лексик берәмлекләрдә предметлыктан бигрәк, төшенчәлелек чагылыш таба» дигәндә, сүзләрне кулланудагы менә шушы үзенчәлек истә тотыла, ягъни бер сүзнең тик торгандагы

төп мәгънәсе кешеләрнең сөйләмендә үзенең семантикасын төрлечә киңәйтә ала.

Бу үзенчәлек әлеге китапта борынгы һәм хәзерге поэзия әсәрләреннән сайлап алынган күпсанлы өзекләр белән ныгытыла; «коры» фәнни диалектологик тикшерү әдәби образлы яңгыраш ала, татар шагыйрьләренең үз күзаллавы мөмкинлеге белән конкрет (денотатив) мәгънәле үсемлек атамаларының мәгънә эчтәлегендәге төшенчәлелек (сигнификатив) компонентын ни дәрәҗәдә үстерә, сүзне сурәткә әверелдерә белү осталыгы да ассызыклана. *«Пешкән алмаларны күтәрергә / Инде түзәр хәле калмагач / Өз алмамны, зинһар, дип ялвара / Көзге ачы җилгә алмагач»,* – дигән теземдә Фәннүр Сафинның хискичерешләре, һәр укучының күңел кылларына кагылып, аның үзенә генә мәгълүм булган күзаллаулары, яңа мәгънәләре белән яңгырый башлый. Шундый мисалларның әзлекле файдаланылуын күрәбез: *Куангандыр былбыл нәкъ шушы / Тирәкне сайлап / Үзе белгән сөю җырын / Туйгынчы сайрап»* (Зөлфәт). Шул рәвешле «Татар поэзиясендә үсемлек атамаларының кулланылышы» дигән яңа монографиягә нигез салына. Шул ук вакытта кайсы үсемлекнең кайсы шагыйрьнең игътибарын күбрәк җәлеп итүе дә ачыклана.

Күпчелек шагыйрьләрнең томнары Тәнзилә Хәсән кызының эш өстәлендә булды: карале, тыңла әле, дип, өзекләрне яттан сөйли иде. Хезмәтнең икенче бүлегендә – «Үсемлек атамаларында сүзьясалыш ысуллары» (б. 338–348), өченче бүлегендә «Үсемлек атамаларында генетик катламнар» дигән четерекле мәсьәләләр җентекләп анализлана (б. 349–355). Йомгакта кешелек җәмгыяте үсешенең һәр чорында үсемлекләр дөньясы әһәмиятле роль уйный, телебездә үсемлек атамалары киң таралган лексик төркемне тәшкил итә, татар халык сөйләшләрендә теге яки бу үсемлекнең җирле атамасы белән бергә, әдәби телдәге исеме дә файдаланыла, дигән гомуми нәтиҗә ясала (б. 356–364). Фәнни әдәбият исемлеге теркәлә. Шулай итеп, үсемлекләр дөньясына караган сүз/терминнарында, татар халкының чынбарлыкны үзенчә күрүе, күзаллавы чагыла, уйлау-фикерләү һәм үзенчә әйтеп бирә белү осталыгы белән, аерым төшенчә-атамаларның Концепт буларак катлаулы үсеше, аерым сөйләшләрдә, язма әдәбиятта һәм фольклор әсәрләрендәге киң кулланылу мөмкинлеге анализлана һәм аңлатыла. Шулай итеп, затлы китап формалаша, басылып чыга, укучыларга тәкъдим ителә.

Тәнзилә Хәсән кызы Хәйретдинова, фәнни эшчәнлегендәге кебек, шәхси тормышында да бәхетле булды. Ул Биектау районы Урал авылында 1941 елның 10 октябрендә туа, Хәсән абзый белән Рәхилә апаның күп балалы гаиләсендә үсә, 1957 елда Мүлмә урта мәктәбен, 1966 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. 1966–1968 елларда Арча районы Яңасала мәктәбендә директор урынбасары вазифасын үти, 1968–1969 елларда КДПИда китапханәдә эшли, авылдашы, үзе кебек үк киң күңелле, уңган-булган Гадел белән яратышып гаилә коралар. 1969–2014 елларда ТӘһСИдә

фәнни хезмәткәр буларак хезмәт куя, ел саен диалектологик экспедицияләргә чыгып материал туплый, гыйльми эшчәнлек алып бара, «Говор златоустовских татар» дигән тема кандидатлык диссертациясе буларак яклана (Алма-Ата, 1980).

Т.Х. Хәйретдинованың хезмәтләре бүген дә актуальлеген югалтмый. Алар татар тел белеменең лексикология, диалектология кебек тармакларында алдагы фәнни тикшеренүләр өчен нигез булып торалар.

**Әдәбият**


Актуальные вопросы татарского языкознания: сб. ст. (к 110-летию Л. Заляя) / отв. ред. Д.Б. Рамазанова; АН РТ. ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. Вып. 4. Казань: Фикер, 2005. 168 с.

*Ахманова О.С.* Словарь лингвистических терминов: [Около 7 000 терминов]. 2-е изд., стер. М.: Сов. энциклопедия, 1969. 607 с.

*Бәширова И.Б.* Татар әдәби теле. Семасиология. Казан, 2010.

*Зәкиев М.З.* Төрки-татар этногенезы / ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘСИ. Казан: Фикер, 1998. 624 б.

*Сагдеева Ф.К.* Концепт «труд» в лексике и фразеологии // Инсани фәннәр: эзләнү һәм табышлар. Казан: Фикер, 2004. Б. 126–130.

Татар әдәби теле тарихы. Казан: ТӘһСИ, 1 т., 2015.

*Хәйретдинова Т.Х.* Табигать концепты: үсемлекләр дөньясы. Казан: ТӘһСИ, 2017. 384 б.

*Хайрутдинова Т.Х.* Названия пищи в татарском языке. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. 142 с.



***Бәширова Илида Басыйр кызы,***

*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 579

*Н.В. Феоктистова*

# ТАТАР МИКРОБИОЛОГЫ Р.Г. САЙМАНОВАНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

В 2012 году ушла из жизни выдающийся микробиолог, доцент Казанского университета Роза Габдрахмановна Сайманова, ученая с постоянным позитивным настроем и доброжелательным отношением к людям в любых обстоятельствах. Статья посвящается памяти этой уникальной личности, представительнице татарской интеллигенции. Автор освещает жизнь и научную деятельность Р.А. Саймановой, делится с воспоминаниями ее современников. В 1939 г., окончив школу с отличными отметками, Роза поступила на кафедру физиологии растений и микробиологии биологического факультета КГУ. Педагогический стаж Розы Абдрахмановны составляет 44 года. В 1964 г. Р.А. Сайманова защитила кандидатскую диссертацию «Дезоксирибонуклеазы бактерий и влияние некоторых условий на их образование и активность». Непосредственное участие Роза Абдрахмановна принимала в восстановлении в 1947–1948 гг. производства на Казанском уксусном заводе, в 1956–1963 гг. руководила работами по изучению грибной коррозии оптических приборов, выпускаемых Казанским оптико-механическим заводом. Большую роль она сыграла и в развитии научного направления «Сельскохозяйственная микробиология». Автор статьи представляет Розу Абдрахмановну как талантливого педагога и общественного деятеля, стремящегося передать любовь к жизни и избранной профессии не только своим ученикам, но и всем людям в ее окружении.

**Ключевые слова:** выдающийся микробиолог, педагог, татарская интеллигенция, научно-педагогическая деятельность.

In 2012 an outstanding microbiologist, associate professor of Kazan University Roza Gabdrakhmanovna Saymanova, a scientist with a constant positive attitude and a benevolent attitude towards people in any circumstances passed away. The article is dedicated to the memory of this unique personality, a representative of the Tatar intelligentsia. The author covers the life and scientific activities of R.A. Saimanova, shares with the memories of her contemporaries. In 1939 after graduating from school with excellent marks Rosa entered the Department of Plant Physiology and Microbiology, Faculty of Biology, KSU. Rosa Abdrakhmanovna's teaching experience is 44 years. In 1964 R.A. Saimanova presented her Ph.D. thesis «Deoxyribonuclease of bacteria and the influence of certain conditions on their formation and activity». Roza Abdrakhmanovna took direct part in the restoration in 1947–1948 of production at the Kazan vinegar plant, in 1956–1963 supervised work on the study of fungal corrosion of optical devices produced by the Kazan Optical and Mechanical Plant. She also played an important role in the development of the scientific direction «Agricultural Microbiology». The author of the article presents Rosa Abdrakhmanovna as a talented teacher and public figure who strives to convey the love of life and her chosen profession not only to her students, but also to all people in her environment.

**Keywords:** outstanding microbiologist, teacher, Tatar intelligentsia, scientific and pedagogical activity.

2012 елда күренекле татар зыялысы, тормышта һәрчак уңай кәеф-халәтен һәм кешеләргә хәерхаһлы мөнәсәбәтен саклый белгән уникаль шәхес, күренекле микробиолог, Казан университеты доценты Сайманова Роза Габдрахман кызы бакыйлыкка күчте.

Роза Сайманова (Хәбибуллина) 1921 елның 18 августында Вятка губернасы (хәзерге Киров өлкәсе) Малмыж шәһәрендә укытучылар гаиләсендә дөньяга килә. Казан шәһәрендә укыган эти-әниләре (әтисе Хәбибуллин Габдрахман Хәбибулла улы – 1914 елны реаль училище; әнисе Мансурова Рәкыя Фәйзрахман кызы, 1916 елны хосусый хатын-кызлар гимназиясен тәмамлаган) авылда укыталар, 1920 елда Халык мәгарифе бүлеге аларны Малмыж шәһәренә эшкә җибәрә. Габдрахман Хәбибулла улы яңа гына оешкан 7 еллык татар мәктәбенә директор итеп билгеләнә. Моннан тыш, ул биология һәм химия предметларыннан дәресләр бирә, әниләре татар теле һәм әдәбияты укыта.

1931 елда Хәбибуллиннар гаиләсе Казанга күченә. Кечкенә Роза 18 номерлы (10 еллык) татар мәктәбендә укуын дәвам итә. Әтисе, Казан университетының биология факультетында читтән торып укучы студент буларак, Казан кооператив техникумында химия укыта. Укытучылык эше аның гомерлек язмышына әверелә. Әнисе, бераз вакыт Казанның Ленин районы мәгариф бүлегендә инструктор булып эшләгәннән соң, сәнгатькә кереп китә һәм 20 ел буе Казан курчак театрында актриса булып эшли.

1939 елда мәктәпне гел бишле билгеләренә тәмамлап, Роза Казан университеты биология факультетының үсемлекләр физиологиясе һәм микробиология кафедрасына укырга керә. Микробиология аны кызыклы һәм перспективалы белгечлек буларак үзенә җәлеп итә.

Роза Хәбибуллинаның остазлары – дөньякүләм билгеле Н.И. Ливанов, В.И. Баранов, А.М. Алексеев кебек галимнәр. Яшь кыз аларның лекцияләренә һәм лаборатор дәресләргә яратып йөри.

1941 елның 12 июнендә биология факультетының икенче курс студентлары җәйге сессиянең соңгы имтиханын тапшыралар. Әмма каникулларга таралырга өлгермиләр, 1941 елның 22 июнендә Бөек Ватан сугышы башланып китә. Озак та үтми, Казан университеты каршындагы комсомол комитетында кыска вакытлы (2,5 айлык) сандружина курслары оеша, анда, нигездә, биологлар һәм химиклар шөгыльләнә. Әлеге курсларга Роза Хәбибуллина да кабул ителә. Аны медицина хезмәтенең кече сержанты дәрәҗәсендә Казанга Ленинград фронтыннан эвакуацияләнгән 1667 номерлы нейрохирургия госпиталенә беркетәләр, биредә ул 3 елга якын шәфкать туташы булып эшли. Бу госпитальдә башлары, умыртка баганасы яки кул-аяклары каты яраланган сугышчылар дәвалана, шуңа да тәүлекнең күп өлешен шәфкать туташлары госпиталь ятаклары янында дежур торып уздыра. Аның хезмәт сөючәнлеге, игътибарлылыгы, түземлелеге һәм иң авыр пациентларны да тернәкләндерә белү сәләте госпиталь табибларының игътибарыннан читтә калмый, алар Розага университет биофагыннан медицина институтына күчәргә тәкъдим итәләр.



Р.Г. Сайманова

1943 елның башында биология факультеты деканы профессор М.В. Марков сугыш башлану сәбәпле укуларын өзәргә мәҗбүр булган студентларны барлый башлый. Беренче сентябрь көнне дәресләргә 1941 елда икенче курсны тәмамлаган 90 студентның нибары 27 се генә килә. Күпләр фронтта ятып калган, кемнәрдер, сугыш башлануга, йөрәк кушуы буенча, Татарстанның төрле районнарына укытырга киткән һәм Казанга әйләнеп кайтмаган.

Университетка җыйналган студентлар арасында Роза Хәбибуллина да була. Дәресләргә йөрү белән бергә, ул госпитальдә дә эшләвен дәвам итә. Сугыш чоры авырлыкларына карамастан, Роза максатына туры бара.

1946 елда Роза Хәбибуллина «Әче-сөт бактерияләрендә бактериофаглар» дигән темага диплом эше яклый; сәләтле һәм гаять җаваплы студент кызны профессор М.В. Марков күреп ала. Нәкъ менә шушы галим Розаны Казан университетының үсемлекләр физиологиясе һәм микробиология кафедрасына өлкән лаборант итеп эшкә алырга тәкъдим итә.

Роза Хәбибуллинаның педагоглык стажы 44 ел. 1949 елдан ул – ассистент, 1964 елдан – үсемлекләр физиологиясе һәм микробиология кафедрасы доценты. 1940 еллар ахырыннан 1960 еллар уртасына кадәр биология факультетында микробиологиягә караган дисциплиналарны ике белгеч – М.И. Беляева һәм Р.Г. Сайманова укыта. Роза Габдрахман кызы микробиология, туфрак микробиологиясе, санитар-азык микробиологиясе буенча лекцияләр укый, төп микробиология дисциплиналарыннан гамәли курсларны алып бара. Хәзерге вакытка кадәр кафедрада укып чыккан белгечләр аның лаборатор дәресләрдә студентларны сәнәгатьтә, биохимия белән бәйле җитештерү өлкәләрендә кулланыла торган микробиологик процесслар, бигрәк тә әчүнең төрле төрләре белән таныштыра торган зур практикумын искә төшерәләр.

Университетта Роза Габдрахман кызының турыдан-туры катнашлыгында йөзләгән югары квалификацияле микробиологлар әзерләнә. 1964 елда Р.Г. Сайманова «Бактерияләрдәге дезоксирибонуклеазлар һәм аларның барлыкка килүенә, активлыгына тәэсир итә торган кайбер шартлар» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый.

Р.Г. Сайманова (Хәбибуллина)– группаларның иң яхшы кураторларыннан, 33 ел дәвамында биология-туфрак факультеты Гыйльми Советының алыштыргысыз Гыйльми сәркатибе. Күп еллар дәвамында Роза Габдрахман кызы микробиология кафедрасының уку-укыту бүлеге мөдире вазифасын да башкара. Озак вакытлар М.И. Беляева белән бергә эшләп, Роза Габдрахман кызы аның фикердәше генә түгел, дустына әверелә. Маргарита Ильинична белән бергә ул суны әчетә торган

бактерияләрне өйрәнә, микроорганизмнарның саф культуралары музеен булдыра, микроблы нуклеодеполимеразларны тикшерә.

Роза Габдрахман кызы 1947–1948 елларда Казан уксус заводында җитештерү эшен тергезүдә катнаша, 1956–1963 елларда Казан оптика-механика заводында җитештерелә торган оптик приборлардагы гөмбәчек коррозиясен өйрәнү эшенә җитәкчелек итә. «Авыл хуҗалыгы микробиологиясе» фәнни юнәлеше үсешендә дә аның роле зур.

Р.Г. Сайманова (Хәбибуллина) микробиология лабораториясенең «йөзен» билгеләүчеләрнең берсе буларак бәяләнергә хаклы. 1953–1958 елларга туры килгән студентлык чарын биология фәннәре докторы, әйдәп баручы гыйльми хезмәткәр Ф.Г. Куприянова-Ашина болай дип искә төшерә: *«Без – Инна Лещинская һәм мин – микробиология лабораториясендә беренче курстан шөгыльләнә башладык. Дәресләрдән соң киләбез дә төнгә кадәр шунда утырабыз. Лабораториягә кайчан кермә, анда һәрвакыт иҗади һәм хәерхаһлы атмосфера тудыра алган Маргарита Ильиничнаны һәм Роза Габдрахмановнаны очратасың. Роза Габдрахмановна безне микробиолог хезмәтенең асылына һәм барлык нечкәлекләренә өйрәтте. Төгәллеккә, пөхтәлеккә, тәҗрибәләр уздырганда җентекле карарга ул күнектерде. Соңрак, җитди рәвештә фән белән шөгыльләнә башлагач, бу сыйфатлар безгә нык ярдәм итте»*. Р.Г. Сайманова эшчәнлеге замандашлары тарафыннан галим буларак та, кеше буларак та әнә шулай югары бәяләнә. Моннан тыш Роза Габдрахман кызы үзенең педагоглык «серләре» белән болай дип бүлешә торган була: *«Гамәли дәресләрдә мин һәрчак микроскоп ярдәмендә препаратлар тикшерүче студентларның күзләренә карыйм. Микроорганизмнарны, бигрәк тә алар тере һәм буялмаган булганда, күзәтү шактый авыр. Кешенең чыннан да иң кирәклесен күрүен яки болай гына сөйләвен ничек итеп аерырга соң? Әгәр микроскопка текәлгән күзләрдә шатлык чаткысы ялтыраса – димәк, күреп алган!»*.

Микробиология кафедрасы инженеры Н.К. Мочалова исә болай дип искә ала: *«1977 елны Казан университетын тәмамлагач, мине микробиология кафедрасында өлкән лаборант итеп эшкә калдырдылар. Беренче көннән үк Роза Габдрахмановна минем остазыма, укытучыма һәм, гомумән, бик якын кешемә әйләнде. Ул гаять зур тәҗрибәгә ия булып, микробиологиянең төрле өлкәләреннән тирән белемле иде. Роза Габдрахмановна мине үз вазифаларымны намус белән һәм төгәл башкарырга өйрәтте, нәрсәдер аңлашылмаганда, һәрчак ярдәмгә килә иде.*

*Мине аның гамәли дәресләрне ничек җентекләп һәм җитди әзерләве гаҗәпләндерә иде. Башта ул бик төгәл һәм аңлашылырлык итеп сөйли, ә инде студентлар мөстәкыйль эшкә керешкәч, һәрберсе янына килә һәм тагын бер кат аңлата-күрсәтә, студентларның эшне ничек башкаруын күзәтеп тора. Шул рәвешле генә чын микробиологлар тәрбияләргә мөмкин, дип саный иде ул. Ул бер минутка да студентларның үзләрен генә калдырмый, ә бит кайвакыт гамәли дәресләр көненә 3–4 пар булып баралар. Роза Габдрахмановна үзе*

*гамәли дәресләргә җаваплы якын килә һәм башкалардан да шуны ук таләп итә иде. Һәр студент барлык кирәк-ярак белән тәэмин ителгән булсын, берәрсенә нидер җитми калса – бу инде гадәттән тыш хәлгә әйләнә. Җитешмәгән нәрсәләрне эзләп, мин алдан ук башка кафедралар буйлап йөгерәм, дәрес башлануга тулы әзерлекне тәэмин итәргә тырыша идем.*

*Роза Габдрахмановнаның эшкә сәләте таң калдыра иде. Уку-укыту белән шөгыльләнүе өстенә, ул әле кафедраның уку планнары белән утырырга вакыт таба, озак еллар факультет Гыйльми советының сәркатибе булды».*

Роза Габдрахман кызы – үз укучыларында сайлаган һөнәрләренә мәхәббәт хисе уятуга зур игътибар биргән талантлы педагог. Аның лекцияләре төгәллеге, логик төзеклеге белән аерылып тора һәм бер генә дәреслектә дә булмаган мисаллар белән баетылган була. Гамәли дәресләре барлык ваклыкларына кадәр уйланган, үзе һәрбер студент төшенерлек итеп аңлата белә. Шул ук вакытта Роза Габдрахман кызы – һәрчак ачык һәм яхшы күңелле, студентларга, хезмәттәшләренә карата да чиктән тыш түзем, сабыр, ярдәмчел кеше иде. Аның архивында сугыштан соңгы еллардан башлап биология-туфрак факультеты һәм микробиология кафедрасы чыгарылышларының фоторәсемнәре кадерләп саклана.

Роза Габдрахман кызы 69 яшендә укыту эшеннән китә – моңа сәламәтлеге сәбәпче була, ләкин ул микробиология кафедрасында консультант һәм факультет Гыйльми советы сәркатибе булып эшләвен дәвам итә. 1998 елда лаеклы ялга китә, әмма университет тормышыннан аерылмый, барлык вакыйгаларда катнаша, укучылары һәм элеккеге коллегалары белән аралашып яши.

1943 елда Р.Г. Сайманова ТАССР Югары Советы Президиумының «Яралыларны тернәкләндерү буенча иң югары күрсәткечләргә ирешкән өчен» Мактау грамотасы белән бүләкләнә, ә 1945 елны аңа «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакяр хезмәт өчен» медале тапшырыла. Аның бүләкләре арасында – «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 50 ел» һәм «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 60 ел» юбилей медальләре дә бар.

Роза Габдрахман кызының югары белем бирү өлкәсендәге хезмәтләре «Фидакяр хезмәт өчен, В.И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән» (1970) юбилей медале, СССР Югары һәм урта махсус белем министрлыгының «Югары квалификацияле белгечләр әзерләү, фәнни тикшеренүләрне үстерүдәге күпьеллык нәтиҗәле хезмәт өчен, Казан дәүләт университетының 175 еллыгы уңае белән» (1979) Мактау грамотасы, «Хезмәт ветераны» (1985) медале, СССР Югары һәм урта махсус белем министрлыгының «Хезмәттәге казанышлар өчен» (1990) күкрәк билгесе белән дә билгеләнгән.

***Феоктистова Наталья Владимировна,***
*биология фәннәре кандидаты*

## О.Н. ГАЛИМОВАНЫҢ «ТАТАРЧА-РУСЧА-ЛАТИНЧА АҢЛАТМАЛЫ БАЛЫК АТАМАЛАРЫ СҮЗЛЕГЕ» (фәнни редактор: филология фәннәре докторы А.Ә. Тимерханов; бәяләүчеләр: филология фәннәре кандидаты И.И. Сабитова, филология фәннәре кандидаты М.К. Юматова. – Казан: ТӘһСИ, 2019. – 204 б.) ТУРЫНДА

Терминологик сүзлекләр татар лексикографиясе системасында аерым урын алып тора. Мәгълүм булганча, татар телендә терминологик сүзлекләр төзүнең күпьеллык тарихы һәм традицияләре бар. К. Насыйриның XIX гасыр ахырында дөнья күргән «Истиляхате җәгърәфия» сүзлеге (1890) – бу өлкәдә беренче тәҗрибә. Бүгенге көндә төрле фәннәргә караган күп кенә, шул исәптән биология терминнары сүзлекләре дә нәшер ителде. Бу хезмәтләрдә әлеге фәннең төп тармакларына – ботаника, зоология, анатомия, физиология, цитология, биотехнологиягә караган атамалар туплап бирелгән. Алар төрле принципларга нигезләнеп төзелгәннәр. Кайберләре русча терминга туры килерлек татарча сүз табу белән чикләнсә, икенчеләре русча терминнарга туры килгән татарча эквивалент бирү белән бергә, терминның мәгънәсен, эчтәлеген дә ачкан.

Биология терминнары бүгенге көндә, кайбер тармакларны исәпкә алмаганда, инде формалашкан төгәл системаны хасил итсә дә, аерым тематик төркемнәрдә төгәлсезлекләр әле дә очрый. Шуңа да тармак атамаларын камилләштерүдә, системага салуда терминологик сүзлекләрнең роле гаять зур.

Күптән түгел басылып чыккан «Татарча-русча аңлатмалы балык атамалары сүзлеге» – О. Галимованың күп еллар буе дәвам иткән фәнни тикшеренүләре нәтиҗәсе – балыкчылык лексикасындагы хата-җитешсезлекләрне мөмкин кадәр киметү, дөресләү максаты белән төзелгән сүзлек.

Автор тәкъдим ителгән кулланмада фәнгә билгеле ихтионимнардан Татарстан һәм Россия сулыкларында яшәүче балыкларның атамаларын гына биреп калмаган. Биредә аларның мәктәп дәреслекләрендә, фәнни-популяр әдәбиятта очраганнары да урын алган. Шулай ук ихтиологик, аквариумчылар әдәбиятларында, балыкчылар, балыкчы спортчылар форумнарында кулланылган океан, диңгез балыкларының атамалары да чагылыш тапкан.

О. Галимова балыкчылык атамаларын өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтендәге бай лексик материалга гына түгел, татар теленең аңлатмалы, диалекталь, телара, биология, авыл хуҗалыгы буенча атамалар сүзлекләренә дә таянган. Бер үк вакытта белешмәлекнең яңа ихтионимнар (экзотик балыкларның татарча атамалары) белән дә баетылуы аның кыйммәтен тагын да арттыра. Әлеге бай материал

җентекләп тикшерелеп теркәлгән, системага салынган. Сүзлек 168 ояга тупланган 1459 ихтионимны (шул исәптән 166 диалектализмны) һәм 485 классификация атамасын (ыруг, семьялык, отряд, классларны) үз эченә алган. Киң таралган күпкомпонентлы атамаларны җыеп, мәгълүматны бербөтен итеп бирү максатыннан, автор аларны алфавит тәртибендә оялап төзегән. Башта төп атама – балык (төр яки астөр) атамасы бирелгән. Беркомпонентлы төр атамасы булмаганда, берничә компонентлы терминнарга төп атама итеп ыруг яки семьялык атамасы алынган. Төп атамадан соң, алфавитка туры китереп, әлеге атама белән бәйле башка ихтионимнар, класс, отряд, семьялык, ыруг атамалары китерелгән. Мәсәлән:

**җилембалык** УКЛЕЙ, УКЛЕЙКА *Alburnus alburnus* Карп балыклар семьялыгыннан; Европа сулыкларында киң таралган, сырты соргылт күк, ян-яклары һәм корсагы көмешсу төстәге балык; балыкчылык хуҗалыгында әһәмияте зур түгел; *диал.* **йока сабак, йука чабак**
**җилембалыклар** УКЛЕЙКИ *Alburnus* Карп балыклар семьялыгыннан, төче су балыклары ыругы
… һ. б.

Биологик классификациядә төрле семьялыкка караган балыкларның атамалары сүзлектә, төп атамага карап, бер ояга урнаштырылган: *тәрәч* һәм *тешле тәрәч,* шулай ук *чуртан, Америка чуртаны, Амур чуртаны* һәм *диңгез чуртаны, макрель чуртаннар, скумбрия чуртаннар* атамалары бер ояда бирелгән.

Оядагы һәр термин яңа юлдан язылып, башта калын хәрефләр белән татарча ихтионим, аннан соң аның русча, латинча вариантлары китерелгән. Татар диалектларында да табылган очракта, балык атамалары *диал.* (диалектизм) тамгасы белән аерып күрсәтелгән:

**(гади) алабуга** ОКУНЬ (ОБЫКНОВЕННЫЙ) *Perca fluviatilis* Алабугалар ыругыннан; Европа, Төньяк Азия төче суларында иң киң таралган, койрыгының асты һәм корсак йөзгечләре кызыл төсле, киң яшькелт гәүдәсе биш-тугыз полосалы (шуңа ала булып күренә) ерткыч балык; *диал.* **әлүкін, алабога, алабыга, аламага**, **аламуга, бәймәт**
… һ. б.

Диалекталь атамаларны шул рәвешчә төп сүз вокабуласында бирү, беренчедән, сүзлек белән эшләүне җиңеләйтсә, икенчедән, тел байлыгын ачып бирүгә хезмәт итә.

Биологик систематикада гомумкабул ителгән латин атамаларын күрсәтү ихтионимнарны төгәлләштерү, системага салу максатына хезмәт итә, чөнки төрле чыганакларда бер үк балыкның төрле исем астында теркәлү очраклары күзәтелә.

Хезмәтнең әһәмияте шунда: монда телдә активрак кулланылган рус ихтионимнарының төрле чыганаклардан табып алынган татарча

эквивалентлары бирелгән. Мәсәлән, *бөкрәч – горбуша, сәврүк – севрюга, чуклы балык – султанка.*

Сүзлекнең отышлы ягы – атамаларга тулы һәм төгәл аңлатма бирү. Аңлатмаларда балык турында тулы мәгълүмат (аларның семьялыгы, яшәү ареалы, төсе, зурлыгы) китерелгән. Кайбер сүзлек мәкаләләрендә, өстәмә мәгълүмат буларак, теге яки бу төр балыкларның промыселда әһәмияте, аквариумда үстерелү, үрчетү мөмкинлеге, акклиматизацияләнү, саклану статусы күрсәтелгән.

Биологик сүзлекләрдә классификация атамаларын биргәндә төгәлсезлекләр, ялгышлар шактый очрый. Моның, әлбәттә, объектив сәбәпләре бар. О. Галимова исә, әлеге хаталарны мөмкин кадәр төзәтеп, ыруглар, семьялыклар, отрядлар, классларны (аскласс, өскласс) үзләреннән зуррак таксономик категорияләр аша аңлаткан. Атамаларга шул рәвешчә аңлатма бирү, бер яктан, хезмәтне энциклопедияләргә якынайтса, икенче яктан, зур гына мәгълүматны киң катлау укучыга кыска итеп җиткерергә ярдәм итәчәк. Бу, үз чиратында, хезмәтнең әһәмиятен тагын да арттыра.

Терминология бер өлкәгә караган атамаларда бермәгънәлелеккә ирешергә омтыла. Шуңа күрә, авторның сүзлектә классификация терминнарына зур игътибар бирүе, хезмәтнең икенче бер отышлы ягы булып тора.

Күпмәгънәле классификация терминнарында башта зуррак таксономик категорияне белдергән атамага, аннан ваграгына аңлатма китерелгән:

> **диңгез фәрештәләре** МОРСКИЕ АНГЕЛЫ *Squatinidae* 1) Скватинасыманнар отрядыннан, Атлантик, Тын океаннарның яр буе районнарында яшәүче балыклар семьялыгы; 2) *Squatina* Шул семьялыктан киң гәүдәле, зур канатлы, скатларга охшаш акулалар ыругы; диңгез фәрештәсе, кара фәрештә (*Squatina nebulosa*), зур күзле диңгез фәрештәсе һ.б. ны берләштерә.

Диалекталь атамаларны, татар телендәге төп орнитонимнарны аерып бирү дә сүзлек белән эшләүне җиңеләйтә, тел байлыгын ачып бирүгә хезмәт итә:

> **эт балыгы** ВЬЮН, ПИСКУН *Misgurnus fossilis* Эт балыклары семьялыгыннан; Үзәк һәм Көнчыгыш Европа сулыкларында яшәүче, сары күзле, сырты саргылт көрән, кара таплы, корсагы сары, ян-яклары кара полосалы, 25 см га кадәр озынлыктагы төче су балыгы; *диал.* **арыш балыгы, җылан балыгы, җылан балык, җылан этләйе, җылтай, җырнай, йылан балыгы, йылан балык, майма балык, мыжый, этекәч, этем, этләч балыгы, этбалык, этли, этли балык, этлүч, этмәй, этәнәй, ялтыр балык**

Ихтионимлы мәкаль-әйтемнәр сүзлеккә туплаган мәгълүматны милли мәдәни компонент белән баета. Алфавит тәртибендә бирелгән русча ихтионимнарның исемлеге (терминнар күрсәткече)

кулланучыларга кирәкле атаманың рус телендәге эквивалентын да табуны җиңеләйтә һәм сүзлекнең әһәмиятен арттыра.

О. Галимованың «Татарча-русча аңлатмалы балык атамалары сүзлеге», һичшиксез, уңай бәя алуга лаек.

Татар теленең үзенчәлекле лексик байлыгын туплаган, аңлатмаларында балыклар турында бай мәгълүмат булган әлеге хезмәт киң катлау укучыларга, биологлар, ихтиологлар, табигатьне саклаучылар, сүзлекчеләр, тәрҗемәчеләр, радио һәм телевидение, матбугат хезмәткәрләре, укытучылар өчен файдалы белешмәлек булып хезмәт итәчәк.

***Сабитова Илһамия Исламетдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 030

***Л.Т. Нигъмәтҗанова***

# ТАТАРСТАНДА ФИЗКУЛЬТУРА-СПОРТ ХӘРӘКӘТЕН ӨЙРӘНҮ ЧЫГАНАГЫ БУЛАРАК «ТАТАРСТАНГА – 100 ЕЛ: РӘСЕМЛЕ ЭНЦИКЛОПЕДИК ЯЗМАЛАР» КИТАБЫ

В статье рассматривается возникновение и процесс развития спортивного движения в Республике Татарстан, описанные в книге «Татарстану – 100 лет: иллюстрированные энциклопедические очерки»; освещена история ведущих спортивных клубов республики. В этом издании наиболее полно и достоверно представлена история развития спорта на территории Республики Татарстан, начиная с периода становления ТАССР и заканчивая современным положением в области спорта и физического воспитания подрастающего поколения. В книге представлен богатый фактический материал, размещено множество иллюстраций, относящихся к рассматриваемому периоду. На страницах очерков раскрываются важнейшие вехи истории Татарстана.

**Ключевые слова:** спортивное движение, физкультурное общество, массовый спорт, здоровый образ жизни, энциклопедические очерки.

The article discusses the emergence and development of the sports movement in the Republic of Tatarstan, described in the book «Tatarstan – 100 years: illustrated encyclopedic essays»; highlights the history of the leading sports clubs of the Republic. In this publication the history of the development of sports on the territory of the Republic of Tatarstan is presented most fully and reliably from the period of the formation of the Tatarstan Autonomous Soviet Socialist Republic to the current situation in sport and physical education of the younger generation. The book contains rich factual material, contains many illustrations related to the period under review. The pages of essays reveal the most important milestones in the history of Tatarstan.

**Keywords:** sports movement, physical culture society, mass sports, healthy lifestyle, encyclopedic essays.

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгына Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты коллективы 1920 елдан 2020 елга кадәр республиканың иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади һәм мәдәни тормышын чагылдырган рәсемле энциклопедик язмалар әзерләде. «Татарстанга – 100 ел»: рәсемле энциклопедик язмалар» китабында [Татарстанга – 100 ел, 2019] укучыга Татарстан тарихы, дәүләт төзелешенең мөһим сәхифәләре, сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф, мәдәният һәм массакүләм мәгълүмат чаралары, сәламәтлек саклау һәм спорт үсешенең төп этаплары сурәтләнгән бай фактик һәм иллюстратив материал тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты коллективы тарафыннан әзерләнгән «Татарстанга – 100 ел» рәсемле энциклопедик язмалар

1990 елларда ук Татарстан Фәннәр академиясенең беренче президенты М.Х. Хәсәнов җитәкчелегендә эшләнә башлаган энциклопедик басмалар сериясен дәвам итә.

Китап Татарстан Республикасының 100 еллыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 28 декабрендәге «Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү чаралары планын раслау турында» 1020 нче карары нигезендә нәшер ителә.

Язмаларда укучы 1920 елдан 2020 елга кадәр Татарстан тарихы, дәүләт төзелеше, республиканың иҗтимагый-сәяси, икътисади тормышы, фән, мәгариф һәм этномәдәни үсешенең төп этаплары турында мәгълүмат таба ала.

Китапның кереш өлешендә Татарстанның дәүләтчелек тарихы, 1920 елда Татарстан АССР төзелү, республика үсешендәге сәяси, социаль-икътисади һәм этномәдәни процесслар турында материал тупланган.

Китап кеше тормышының төрле өлкәләренә багышланган тугыз өлештән тора. *Беренче* өлешендә Татарстан Республикасы сәяси тарихының мөһим сәхифәләре, республиканың борынгы кабиләләрдән алып бүгенге көнгә кадәрге күп гасырлык тарихы яктыртыла. *Икенче* өлешендә дәүләт хакимияте һәм идарә органнары, Татарстанда дәүләт хакимияте югары органнары системасы формалашу, бүләкләр, исемнәр һәм премияләр турында тәфсилләп бәян ителә. *Өченче* өлеше Татарстанның административ-территориаль бүленешенә багышлана, республика районнары составына кергән барлык торак пунктлар тасвирлана. Татарстан – Россия Федерациясенең күпмилләтле төбәкләреннән берсе. Аның территориясендә үз гореф-гадәтләре һәм дине булган 170 тән артык халык вәкиле яши. Авторлар коллективы Татарстанның этномәдәни үсешенә аерым игътибар бирәләр, китап битләрендә республикада яшәүче халыклар, аларның дине һәм бәйрәмнәре белән тулырак танышып була. Аларның таралу тарихы, мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре *дүртенче* өлештә җентекләп бәян ителә. Татарстан Республикасы – мәгариф һәм фән югары үсешкә ирешкән төбәк. Биредә гомуми белем, һөнәри һәм югары уку йортлары челтәре үсеш алган. Күп гасырлык халык мәгарифе турында *бишенче* өлешендә бәян ителә. *Алтынчы* өлеше Татарстан Республикасы икътисадына, сәнәгатенә һәм авыл хуҗалыгына багышланган. Татарстанның бай мәдәни мирасы һәм сәнгате турында китапның *җиденче* өлешендә бәян ителә. *Сигезенче* өлештә Татарстан Республикасының барлык массакүләм мәгълүмат чаралары тәкъдим ителгән, китап басу эше барлыкка килү, шулай ук аның хәзерге торышы тасвирланган. Китапның *тугызынчы* өлешендә сәламәтлек саклау һәм спорт үсешенең төп этаплары яктыртылган.

Шулай итеп, әлеге китапта чыганакларга таянып һәм тарихи нигездә киң хронологик кысаларда (1920–2020 еллар) Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче төрле халыкларның тарихы,

мәдәнияте, гореф-гадәтләре, диннәре һәм хәзерге халәте буенча статистик һәм динамик күрсәткечләр китерелә. Архив документларына нигезләнеп, республиканың тарихи һәм икътисади үсеше контекстында татарларның бай тарихы һәм мәдәнияте торгызыла һәм өйрәнелә.

Әлеге язмалар институт тарафыннан 1990 елларда ук эшләнә башлаган энциклопедик басмалар сериясен дәвам итә [Татарский энциклопедический словарь, 1999; Татарская энциклопедия, 2002–2014; Республика Татарстан, 2010; Татарстан, 2013]. «Спорт һәм спорт объектлары» бүлегенең «Сәламәтлек саклау һәм спорт» өлешендә физкультура-спорт хәрәкәтенең барлыкка килүе һәм үсеше тасвирлана, бу исә Казан шәһәрендә XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында гамәлгә керә башлаган ирекле спорт җәмгыятьләре һәм берләшмәләре оешу белән бәйле. 1917 елгы инкыйлабтан соң спорт җәмгыятьләре оештыру процессы активлаша, алар Казанда гына түгел, ә республика районнарында да барлыкка килә. Республикадагы спорт хәрәкәтен 1919 елда оешкан Казан губерна хәрби комиссариаты һәм Казан губерна спорт берлеге каршындагы физик тәрбия һәм спорт бүлеге җитәкли. 1921 елда Казанда оештырылган Бөтентатар спорт берлеге барлык спорт җәмгыятьләрен, секцияләрне һәм түгәрәкләрне берләштерә. 1920–1930 елларда ук күпсанлы физкультура җәмгыятьләре («Татпечать», «Железнодорожник», «Флорида», Үзәк физик тәрбия йорты, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте, «Спартак» һ.б.) оештырыла, аларда җиңел һәм авыр атлетика, йөзү, бокс, көрәш, шахмат, шашка, фехтование һ.б. секцияләр эшли.

Республиканың аерым спортчылары һәм җыелма командалары илнең зур ярышларында призлар яулыйлар. Бу елларда ТАССР Сәламәтлек саклау һәм Мәгариф Халык комиссариатлары каршында оештырылган физик тәрбия бүлекләрендә беренче һәм икенче баскыч мәктәпләрдә физкультура дәресләре программалары эшләнә башлый, бу исә Татарстанда массачыл физкультура һәм спорт хәрәкәтенең үсешенә китерә.

1930 еллар башында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) физкультура комплексы һәм Бердәм Бөтенсоюз спорт классификациясе кертелү физкультура хәрәкәтенең актив үсешенә китерә, бу исә оештыру һәм җитәкчелек итүнең гадәти формаларын үзгәртүгә сәбәп була. Нәтиҗәдә, 1935 елда бөтен ил буенча үз уставлары, эмблемалары, әгъзалык билгеләре һәм спорт формалары булган ирекле спорт җәмгыятьләре (ДСО) барлыкка килә. Авыллардагы физкультура хәрәкәтендә дә шул ук хәл күзәтелә: бу чорда ул зур тизлек белән үсә башлый. Спорт оешмаларын квалификацияле белгечләр белән Казан физик тәрбия техникумы һәм Казан педагогика училищесенең физик тәрбия бүлеге тәэмин итә. Спортның техник төрләре үсешенә 1927 елда оештырылган Оборонага, авиация һәм химия төзелешенә ярдәм ирекле җәмгыяте (ОСОАВИАХИМ, хәзер «Татарстан Республикасы армия, авиация һәм флотка ярдәм

ирекле җәмгыяте» (ДОСААФ) төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе) зур өлеш кертә.

Бөек Ватан сугышы елларында ТАССР физик тәрбия һәм спорт оешмаларының эшчәнлеге Кызыл Армия резервларын әзерләү һәм яраланган хәрбиләрнең сәламәтлеген кайтару бурычларын хәл итүгә юнәлтелә. Күпсанлы хәрби-өйрәнү пунктлары җитәкчеләре һәм инструкторлары, кул көрәше, чаңгычылар, дәвалау физкультурасы инструкторлары әзерләнә.

Сугыштан соңгы елларда «Смена» һәм «Хезмәт резервлары» балалар-яшүсмерләр ирекле спорт җәмгыятьләре булдырыла, физик тәрбия һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр саны шактый арта. ТАССР спорт командалары һәм аерым спортчылар төрле спорт ярышларында зур уңышларга ирешәләр.

1980 елларда республикада спорт хәрәкәте яңа уңышлар яулый. 1980 еллар ахырында Татарстан илнең автономияле республикалары арасында беренче урынны били һәм союздаш республикалар арасында Эстония белән сигезенче урынны бүлешә. Үзгәртеп кору һәм аннан соңгы елларда илдәге спорт хәрәкәте үсеше тиешле дәрәҗәдә финансланмауга карамастан, 1990 еллар башына Татарстанда 1901 СССР спорт остасы, 68 халыкара класслы спорт остасы, 14 СССРның атказанган спорт остасы әзерләнә; СССРның атказанган тренеры исеменә – 8, РСФСРның атказанган тренеры исеменә 47 кеше лаек була.

XXI гасыр башында физик тәрбия һәм спорт үсеше республика һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру, шулай ук Татарстанда спорт төрләре буенча бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышлары: тимераякта фигуралы шуу, җиңел атлетика буенча Россия чемпионатлары, 2013 елгы Бөтендөнья җәйге Универсиадасы, спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты, футбол буенча дөнья чемпионаты матчлары, авиаузышлар буенча дөнья чемпионаты этабы һ.б. уздыру физик тәрбия һәм спорт үсешен активлаштыручы факторларга әвереләләр. Күпсанлы спорт объектлары төзелә башлый: «Баскет-холл», «Татнефть Арена» боз спорт сарае, «Казан Арена» универсаль футбол стадионы (хәзер «Ак Барс Арена»), Спортның су төрләре сарае, Чирәмдәге хоккей үзәге, «Казан» халыкара ат спорты комплексы, «КАИ Олимп» мәдәни-спорт комплексы, «Ак Барс» көрәш сарае, Казан теннис академиясе һ.б. ТР Спорт министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2019 ел башында республикада 288,3 мең кеше сыйдырышлы 11 013 спорт корылмасы эшли. Авыл җирлегендә физкультура-спорт хәрәкәтен үстерүгә зур игътибар бирелә.

2015 елда Казанда балалар һәм яшүсмерләр өчен спорт-адаптив мәктәбен булдыру адаптив физик тәрбия һәм спортны үстерүгә көчле этәргеч була. Хәзерге вакытта мәктәптә чукраклар (ирекле көрәш, керлинг, йөзү, җиңел атлетика) һәм сукырлар (йөзү, җиңел атлетика), терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затлар (академик ишү, бочче, йөзү, чаңгы ярышлары, җиңел атлетика), интеллектуаль

тайпылышлары булган затлар өчен (җиңел атлетика, өстәл теннисы, йөзү) спорт бүлекләре эшли.

Татарстан спортчыларының күпсанлы спорт төрләрендәге югары күрсәткечләре һәм казанышлары Татарстан – Россия Федерациясенең спорт төбәкләреннән берсе, дип сөйләргә мөмкинлек бирә.

«Әйдәп баручы спорт клублары» өлешендә предприятиеләрдә, уку йортларында беренче җәмәгать физкультура-спорт оешмалары барлыкка килү тарихы тасвирлана. ВКП (б) Үзәк Комитетының 1948 елның 27 декабрендәге карары (спортсменнарга стипендия түләүне күздә тота) чыкканнан соң, зур спортның һөнәргә әйләнүе активлаша. Бу исә спорт белән профессиональ дәрәҗәдә шөгыльләнергә теләүчеләр санын арттыруга этәргеч була. Күп еллар элек булдырылган физик тәрбия коллективлары безнең көннәрдә спорт клублары статусын алалар: «Рубин» (1962 ел), М. Урицкий исемендәге (1963 ел), Я. Юдин исемендәге (1963 ел), В.Воровский исемендәге (1965 ел), «КАМАЗ» (1975 ел),«Электрон» (1987 ел) һ.б. Биредә XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында Татарстан Республикасында оешкан барлык спорт клублары турында тулы мәгълүмат бирелә.

«Халыкара ярышлар» өлешендә соңгы елларда Татарстан Республикасы территориясендә узган зур һәм әһәмиятле ярышлар һәм спорт чаралары, шул исәптән 2013 елгы Бөтендөнья җәйге Универсиадасы, 2015 елгы спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты, 2017 елгы Конфедерацияләр кубогы, 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионаты матчлары турында сөйләнә.

«Спорт объектлары» өлешендә республикада, 1927 елгы «Динамо» физик культура һәм спорт җәмгыяте стадионы һәм ату тиры, Татарстан профсоюзлары советы стадионы һәм су станциясе төзелү тарихыннан башлап, заманча стадионнар («Ак Барс Арена»), спорт үзәкләре (Гимнастика үзәге), йөзү бассейннары (Спортның су төрләре сарае), яссы мәйданлы корылмалар («Казан» халыкара атспорты комплексы), ясалма бозлы ябык спорт объектлары («Татнефть Арена») төзелү тарихына кадәр яктыртыла.

«Татарстанга – 100 ел» китабында республика территориясендәге физик тәрбия һәм спорт җәмгыятьләренең актив һәм бөтен җирдә таралыш алганынраслаучы архив фоторәсемнәре һәм документлар урнаштырылган. Мәсәлән, 1928 елда 1 нче татар укчы полкының футбол командасы төшерелгән фоторәсем. Рәсемнәр сыйфатында Татарстан өчен генә түгел, ә, гомумән, Россия Федерациясе өчен дә әһәмияте булган заманча спорт корылмаларын; Казанда һәм башка шәһәрләрдә узган спорт чараларын; Татарстан Республикасындагы әйдәп баручы спорт клублары һәм командаларын, шулай ук шәхси зачеттагы казанышларны чагылдырган фотосурәтләр файдаланылган.

Шулай итеп, «Татарстанга – 100 ел» китабында ТАССР төзелү чорыннан башлап, бүгенге көнгә кадәр Татарстан Республикасы

территориясендә спорт һәм спорт хәрәкәте үсеше тарихы киң һәм төгәл яктыртылган, дип әйтеп була.

**Әдәбият**

Татарстану – 100 лет: иллюстрированные энциклопедические очерки. Казань: ОСП «Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ», 2019. 600 с.

Татарский энциклопедический словарь. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1999. 703с.

Татарская энциклопедия. В 6 т. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2002–2014.

Республика Татарстан. Природа, история, экономика, культура, наука. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2010. 194 с.

Татарстан: Иллюстрированная энциклопедия. Казань: ГУ «Институт Татарской энциклопедии АН РТ», 2013. 816 с.

***Нигъмәтҗанова Лилия Тәлгать кызы,***
*ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты*
*өлкән фәнни хезмәткәре.*

**2021 елның 1 октябрендә** Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Саха (Якутия) Фәннәр академиясе вәкилләре белән очрашу узды. Очрашу Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе оешуга 30 ел һәм Татарстан Республикасында академик фәнгә нигез салынуга 100 ел тулу уңаеннан үткәрелгән чаралар кысасында тормышка ашырылды. Чара барышында ТӘһСИ директоры, филология фәннәре докторы К.М. Миңнуллин кунакларны – Саха (Якутия) Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты, физика-математика фәннәре докторы С. Попов һәм М.К. Аммосов исемендәге Төньяк-Көнчыгыш федераль университеты проректоры, педагогика фәннәре докторы А. Голиковны Институт эшчәнлеге белән таныштырды, галимнәр тарафыннан үткәрелә торган фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр, татар филологиясе һәм сәнгате өчен фәнни кадрлар әзерләү, тел өйрәнү проектларын цифрлаштыру һ.б. турында сөйләде. Кунаклар Институтның милли мәгариф, тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать өлкәсендәге, шулай ук Язма һәм музыкаль мирас үзәге эшчәнлеге белән таныштылар.

**2021 елның 18–20 октябрендә** Новосибирск шәһәрендә фольклорчыларның II Себер форумы уздырылды. Форум Россия Фәннәр академиясенең Себер бүлеге тарафыннан оештырылган иде, ул быел «Памятники фольклора народов Сибири и Дальнего Востока» сериясенә нигез салган галим А.Б. Соктоевның 90 еллык юбилеена багышлап үткәрелде. Өч көнгә сузылган әлеге чарага Россиянең төрле төбәкләреннән, чит илләрдән 200 гә якын галим җәлеп ителде. Форум кысаларында алар лекция һәм докладлар белән чыгыш ясадылар. Татарстан галимнәре дә Россиякүләм бу чарада катнашып, докладлар белән чыктылар. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Л.Х. Мөхәммәтҗанова, Институтның гыйльми сәркатибе, бүлекнең өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Л.Х. Дәүләтшина, шулай ук халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Р.Ф. Сафиуллинаның татар фольклористикасының актуаль мәсьәләләренә багышланган чыгышлары Форумның онлайн-катнашучыларында зур кызыксыну уятты. Форумда катнашучыларның лекция һәм доклад тезислары форум материаллары җыентыгында дөнья күрде.

**2021 елның 12 ноябрендә** «Татар-информ» агентлыгында татар диалектологиясе мәсьәләләренә багышланган матбугат конференциясе узды. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында оештырылган очрашуда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре татар диалектлары хакында сөйләделәр, әлеге мәсьәләдә актуаль сорауларга җавап бирделәр. Матбугат конференциясендә Институт директоры, филология фәннәре докторы, профессор К.М. Миңнуллин,

аның фән эшләре буенча урынбасары, филология фәннәре кандидаты О.Р. Хисамов, гамәли лингвистика бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Э.Х. Кадыйрова, лексикология һәм диалектология бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты А.Җ. Хөсәинова катнашты. Белгечләр татар теленең диалектлары, аларны өйрәнү тарихы һәм бүгенге татар диалектологиясенә нигез салган күренекле галимнәрнең фундаменталь тикшеренүләре, шулай ук институт хезмәткәрләренең татарлар күпләп яшәгән төбәкләргә комплекслы фәнни экспедицияләре турында сөйләделәр, ТӘһСИнең татар теле диалектларына һәм сөйләшләренә багышланган яңа басмалары белән таныштырдылар.

**2021 елның 16–21 ноябрендә** Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында Казан лингвистика мәктәбенә нигез салучы И.А. Бодуэн де Куртенэның тууына –175 ел, Казан университетында эшли башлавына 145 ел тулуга багышланган «Дөнья лингвистикасы сораулары һәм трендлары» Казан халыкара лингвистик саммиты үткәрелде.

Саммитны Россия Фән һәм югары белем министрлыгы, Даими халыкара лингвистлар комитеты, Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институты, лингвистик тикшеренүләр институты, Казан федераль университеты оештырды. Әлеге чара КФУ базасында икенче тапкыр Халыкара лингвистлар конгрессына (ICL) әзерләнүнең аерым бер этабы буларак үтте. Саммит кысаларында биш пленар утырыш булды.

Kazan International Linguistic Summit 2020 (KILS) чараларында Россия, АКШ, Бөекбритания, Австралия, Италия, Германия, Нидерланд, Испания, Австрия, Норвегия, Кытай, Төркия, Иран, Үзбәкстан, Кыргызстан, Казакъстан, Молдова, Украина, Беларусь илләреннән биш йөздән артык галим катнашты. Галимнәр палеославистика, традицион лингвистика һәм аның цифрлы, клиник трансформациясе, нейролингвистика, когнитив лингвистика, компьютер һәм корпус лингвистикасы, тел белеменең башка мәсьәләләре турында фикер алышты.

**2021 елның 17–18 ноябрендә** Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Туган телләрне саклау һәм үстерү: проблемалар һәм перспективалар» дип аталган XI халыкара фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Әлеге чара «Телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» VIII Халыкара фәнни-гамәли саммит кысаларында оештырылды.

Конференция Россия Федерациясе төбәкләре, якын һәм ерак чит илләрдән килгән галимнәр арасында мәгълүмат алмашу һәм фәнни тикшеренү нәтиҗәләре белән уртаклашу максатын куйган иде. Чарада Казакъстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Татарстан, Башкортстан, Кырым республикаларыннан, Россия төбәкләре вузларыннан галимнәр, аспирантлар, магистрантлар, студентлар, киң җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

Конференциянең секция утырышында күп милләтләр яшәгән дәүләттә телләрнең кулланылышы, ике һәм күптелле мохиттә туган телләр мәсьәләсе, тел һәм әдәбият-

ларны тикшерүнең фундаменталь һәм гамәли аспектлары, шулай ук лингвокультурология һәм мәдәниятара багланышлар, төрки телләрнең тарихи һәм хәзерге лексикографиясе һ.б. мәьәләләр каралды.

**2021 елның 16 ноябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Татар халкы тарихында Алтын Урда чагылышы» дигән темага түгәрәк өстәл узды. Чарада Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, Казан федераль университеты, Болгар ислам академиясе галимнәре катнашты. Түгәрәк өстәлдә Алтын Урда чорындагы идарә, төрки халыкларда финанс һәм салым системалары дәвам итү, гаскәр, шәһәр цивилизациясе, мәдәният, язма татар теле үсеше һәм башка мәсьәләләр күтәрелде.

**2021 елның 19 ноябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында күренекле галим, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Максудовның тууына 130 ел тулуга багышланган «XX гасыр башы татар зыялыларының язмышы» дигән темага түгәрәк өстәл оештырылды. Чарада XX гасырның беренче чиреге татар зыялыларының эшчәнлеге һәм язмышлары турында сүз барды.

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты каршында оештырылган Академүзәкнең беренче рәисе, математик, дәреслекләр авторы, танылган җәмәгать эшлеклесе Гаяз Гыйсаметдин улы Максудовның тормыш һәм хезмәт юлы, татар милләте алдындагы казанышлары, Академик үзәкнең эшчәнлеге, анда эшләгән татарлар хакында аерым чыгышлар яңгырады. Шулай ук әлеге чорның башка зыялылары – Сәетгәрәй Әхмәров, Якуб Богданович, Нәсыйх Мөхетдинов, Хәлил Әбүлхан, Габдрахман Ильяси, Шәйхгаттар Иманаев, Шакир Мөхәммәдьяров, Габдулла Биги, Габдулла Гыйсмәти, Хәбибрахман Зәбири, Хәлим Искәндәров, Хәбиб Зәйни һ.б.ларның эшчәнлекләре һәм аянычлы язмышлары, аларның татар халкы тарихында тоткан урыннары турында да фикер алышу оештырылды.

**2021 елның 2–3 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме: теория, методология, практика» Халыкара фәнни-гамәли семинары узды. Ике көн дәвам иткән чарада Россия, якын һәм ерак чит илләрдән (Казакъстан, Кыргызстан, АКШ, Бөекбритания, Литва, Финляндия, Голландия) галимнәр татар белеменең актуаль мәсьәләләре турында фикер алышты. Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатының Гыйльми үзәге оешуга 100 ел тулуга багышланган әлеге семинарда пленар утырыш, түгәрәк өстәлләр, Россия галимнәренең лекцияләре, секция утырышлары киң колач белән барды, шулай ук татар беленең киләчәге – яшь галимнәр дә үз проектларын тәкъдим итте.

Пленар утырышны филология фәннәре докторы, профессор, ТӘһСИ директоры К.М. Миңнуллин ачып җибәрде, әлеге фәнни чара бу өлкәдә алга таба тикшеренүләргә этәргеч бирер, татар галимнәрен берләштерүче даими эшләүче дискуссия мәйданчыгын булдыру өчен алшартлар тудырыр, дигән ышаныч белдерде.

Фәннәр академиясе президенты, профессор, академик М.Х. Саләхов быел 30 еллыгын билгеләп үткән ТР Фәннәр академиясенең тарихына һәм эшчәнлегенә тукталды, татар белеменең фән буларак – Гыйльми үзәк, аннары – Татар теле, әдәбияты һәм тарихы фәнни-тикшеренү институты, Фәннәр академиясе кысаларында формалашуын ассызыклады. Пленар утырышта социология фәннәре докторы, доцент, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының этнологик тикшеренүләр бүлеге мөдире Г. Габдрахманова, Джордж Вашингтон Университетының сәяси фәннәр кафедрасы докторы Лентон Адам Чарльз, тарих фәннәре докторы, Әл-Фәраби исемендәге Казакъстан милли университеты профессоры Г. Солтангалиева, тарих фәннәре докторы, Кыргыз милли университеты профессоры Ә. Бикбулатова чыгыш ясады. Утырышта шулай ук гуманитар фәннәр докторы, Вильнюс университеты доценты Г. Мишкинене, филология фәннәре докторы, Россия Халыклар дуслыгы университеты профессоры У. Бахтикирееваның, Финляндиянең Ислам җәмгыяте имамы Р. Беляевның, филология фәннәре докторы, Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты профессоры Ә. Сибгатуллинаның чыгышлары яңгырады.

**2021 елның 10 декабрендә** Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, «Мәдәниятләр диалогы» проекты нәтиҗәсе буларак, фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Конференциядә мәктәпкәчә һәм урта белем, урта һөнәри, өстәмә, югары белем бирү оешмалары вәкилләре, галимнәр һәм студентлар катнашты. 2015 елдан бирле гамәлгә ашырылып килгән әлеге проект агымдагы елда мәдәниятләр төрлелеге шартларында шәхесара һәм мәдәниятара мөнәсәбәтләрне төзүгә яңача караш мәсьәләләренә багышланган иде.

Конференциянең пленар өлеше Татар дәүләт драма театрында узды. Шулай ук чара кысаларында дүрт юнәлештәге секция эше оештырылды, төрле мастер-класслар үткәрелде, күргәзмәләр тәкъдим ителде.

**2021 елның 13 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Ике һәм күптеллелек шартларында дәүләт һәм региональ телләрне куллануның хокукый нигезләре (федераль дәүләтләрдә тел сәясәтен тормышка ашыруның дөньякүләм тәҗрибәсе)» дигән темага Халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Әлеге чараның төп оештыручысы – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. Конференциядә катнашу өчен 80 гә якын фәнни доклад кабул ителгән иде, чарада Казакъстан Республикасы, Кыргызстан Республикасы һәм Мәскәү, Улан-Удэ, Элиста, Уфа, Чабаксар, Саранск, Йошкар-Ола, Ижау, Эстәрлетамак, Якутск, Черкесск, Казан, Яр Чаллы, Әлмәт һ.б. шәһәрләрдән галимнәр катнашты. Шулай ук конференциягә Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, фәнни оешмалар, белем бирү

оешмалары, вакытлы матбугат вәкилләре дә чакырылды.

**2021 елның 14–17 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан ел саен үткәрелә торган «Татар гыйлеме» халыкара яшьләр фәнни мәктәбе эше оештырылды. 2021 елның 14 декабрендә үткәрелгән пленар утырышта Кыргызстан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Новосибирск, Уфа, Марий Эл, Чувашия, Мордовия, Удмуртия галимнәре, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, республиканың фәнни оешмалары хезмәткәрләре һ. б. катнашты.

Фәнни мәктәп чараларында Россия һәм якын чит илләрдән тел белеме, әдәбият белеме, сәнгать белеме, фольклористика өлкәсендә әйдәп баручы галимнәр лекция, докладлар белән чыгыш ясадылар. Лекторлар арасында филология фәннәре докторы, профессор, РФА мөхбир әгъзасы А.В. Дыбо, филология фәннәре докторы, Россия Фәннәр академиясенең Себер бүлеге филология институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Ж.М. Юша, Кыргызстан Республикасының атказанган мәдәният эшлеклесе, филология фәннәре докторы, профессор Т.А. Бакчиев, Н.П. Огарев исемендәге Мордва дәүләт университетының фин-угор филологиясе кафедрасы профессоры, филология фәннәре докторы Т.И. Зайцева, З. Исмәгыйлев исемендәге Уфа дәүләт сәнгать институты доценты, сәнгать фәннәре кандидаты М.Л. Әхмәдуллин һ.б. бар иде.

**2021 елның 15 декабрендә** «Татарстан халыклары мәдәнияте калейдоскобы» проектын тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча төбәкара түгәрәк өстәл үткәрелде. Проект 2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын үткәрү буенча төп чараларның республика планы нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Чуваш дәүләт гуманитар фәннәр институты, В.М. Васильев исемендәге Мордовия Республикасы Хөкүмәте каршындагы гуманитар фәннәр фәнни-тикшеренү институты, Мари Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты белән берлектә гамәлгә ашырылды. Түгәрәк өстәл эшендә проектта катнашучы фәнни оешма вәкилләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль органнар, фәнни һәм белем бирү учреждениеләре, Татарстан Республикасының иҗтимагый оешма хезмәткәрләре катнашты. Чарада «Татарстан халыклары мәдәнияте калейдоскобы» коллектив хезмәте тәкъдим ителде.

**2021 елның 16–17 декабрендә** А.С. Пушкин исемендәге Мәдәният үзәгендә татар сәнгатен өйрәнү белеменә нигез салучы Ф.Х. Вәлиевнең (1921–1984) тууына 100 ел тулуга багышланган «Күп милләтле тукучылык сәнгате» Халыкара симпозиумы узды. Симпозиумны оештыручылар – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты.

Чара Казанда 2009 елдан бирле үткәрелеп килгән «Төрки дөнья

сәнгате» фәнни-гамәли форумы циклының дәвамы булып тора. Симпозиумда Россия халыклары һәм төрки дөнья илләренең һөнәрчелек сәнгате тарихына, хәзерге торышына, техника һәм технологияләренә кагылышлы теоретик һәм гамәли мәсьәләләр турында фикер алышу оештырылды. Чарада Россиянең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән күпсанлы белгечләр катнашты.

**2021 елның 16 декабрендә** «Россия Федерациясендә телләр сәясәте» форумы кысаларында Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык оештырган «Ключевое слово» V Бөтенроссия иҗтимагый премиясенә конкурс җиңүчеләрен игълан итү тантанасы узды. Алты номинация буенча үткәрелә торган әлеге конкурс – Россия Федерациясендә телләр төрлелеген саклауга, Россия Федерациясе халыкларының телләрен саклау һәм үстерү белән кызыксынуны арттыруны тәэмин итә торган шартлар һәм мөмкинлекләр булдыруга юнәлтелгән проектларның берсе. 2021 елда премиягә Россия Федерациясенең 62 субъектыннан барлыгы 340 проект дәгъва кылган.

Конкурста Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан әзерләнгән «Габдулла Тукай: тормышы һәм иҗаты (Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар)» өчтомлык хезмәте «Иң яхшы фәнни проект» номинациясендә җиңү яулады.

Хезмәт өч китаптан гыйбарәт: беренчесендә шагыйрьнең Казан артында узган балалык еллары (1886–1904 елның ахыры), Уральск белән бәйле канат ныгыту дәвере (1894 елның ахырыннан – 1907 елның ахырына кадәр) турында сүз алып барыла; икенче һәм өченче китаплар шагыйрьнең Казан чоры тормышына (1907 елның ахыры – 1913 елның апреле) багышлана.

Хезмәт 2021 елның 24 декабрендә Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә презентацияләнде.

**2021 елның 16 декабрендә** Татарстан Халыклары Дуслыгы йортында «Туган телләр – Татарстанның киләчәге» конференциясе узды. Әлеге чара Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы планы кысаларында «Татарстан – Яңа гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәте тарафыннан оештырылды.

Конференциядә Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К.М. Миңнуллин институтта гамәлгә ашырыла торган электрон проектлар турында чыгыш ясады.

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

– авторның фамилиясе, инициаллары
– мәкалә исеме (татар һәм рус телендә)
– аннотация (рус һәм инглиз телендә)
– төп сүзләр (рус һәм инглиз телендә)
– сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12, 1 нче кат, 10 нчы бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Укышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек*
*итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2021. № 4

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 28.12.2021. Басылды: 12.01.2022.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 12. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшриятында басылды
(нәшрият адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал бушлай таратыла